View metadata, citation and similar papers at core.ac.uk
brought to you by CORE
provided by Kazan Federal University Digital Repository

**КАЗАНСКИЙ ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ**

**ИНСТИТУТ ФИЛОЛОГИИ И МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ**

***кафедра татарской литературы и методики преподавания***

**Н.М. Юсупова, Г.Р. Гайнуллина**

# История современной татарской литературы (7 семестр)

## Конспект лекций

**Казань – 2014**

**Направление подготовки:**031001.65 «Филология» (специальность «Татарский язык и литература»)

**Учебный план:**031001.65 «Филология» («Татарский язык и литература»)(очное, 2010); 031001.65 «Филология» («Татарский язык и литература, английский язык»)(очное, 2010)

**Дисциплина:**«Литературоведение: История современной татарской литературы (7 семестр)» (специалитет, 4 курс, очное обучение)

**Количество часов:**количество часов – **110**, (в том числе лекции – **36**, практические занятия – **18,** самостоятельная работа – **56)**, форма контроля – зачет.

**Аннотация:** главной целью курса является ознакомление литературным процессомвоенных и послевоенных лет в его взаимосвязи с развитием культуры, спецификой интерпретации литературного текста. Задачи курса предусматривают прежде всего погружение в теоретические проблемы курса и особенности творчества отдельных писателей военных и послевоенных лет. Наибольшее внимание уделяется выделению художественного значения литературного произведения в связи с ситуацией в общественной жизни и культурой эпохи, определению художественного своеобразие произведений и творчества писателей в целом.

**Темы:** 1. Основные тенденции развития татарской поэзии и драматургии в годы Великой Отечественной войны; 2. Творчество Мусы Джалиля в контексте татарской поэзии военных лет; 3. Творчество Хасана Туфана в контексте татарской поэзии 1940-80-х гг.; 4. Основные тенденции развития татарской прозы в годы Великой Отечественной войны; 5. Творчество Амирхана Еники в контексте татарской прозы 1940-2000-х гг.; 6. Татарская проза послевоенных лет; 7. Жанр документальной повести в татарской прозе послевоенных лет; 8. Критический пласт в татарских повестях 1960-х гг.; 9. Неореализм в татарской прозе послевоенных лет; 10. Публицистический пласт в татарских повестях 1960-х гг.; 11. Основные тенденции развития татарской поэзии послевоенных лет; 12. Основные тенденции развития татарской драматургии послевоенных лет.

**Ключевые слова:** татарская литература, литературный процесс, стилевые тенденции, литературные направления и течения, творчество.

**Дата начала использования:** 1 сентября 2014 г.

**Авторы:Юсупова Нурфия Марсовна**, кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской литературы и методики преподавания КФУ, тел.:(843) 2-21-33-51, email: Faikovich@mail.ru, Nurfija.Jusupova@ kpfu.ru; **Гайнуллина Гульфия Расилевна**, кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской литературы и методики преподавания КФУ, тел.:(843) 2-21-33-51, email: gulfiarasilevna@mail.ru, GGaynyllina@ kpfu.ru.

**URL электронного курса в MOODLE**: http://tulpar.kfu.ru/course/view.php?id=777

**Доступность:** записанные на курс пользователи

**Язык интерфейса:** татарский

**Эчтәлек**

Тема 1. Бөек Ватан сугышы елларында татар поэзиясе һәм драматургиясе үсеше...................................……………………………………….........................4

Тема 2. Сугыш чоры татар поэзиясе контекстында М.Җәлил иҗаты (1906 – 1944)..………………………….......................................................................12

Тема 3. XX гасырның икенче яртысы татар поэзиясе контекстында Хәсән Туфан иҗаты (1900 – 1981)…………….............................................................33

Тема 4. Бөек Ватан сугышы еллары (1941-1945) татар прозасы (гомуми күзәтү)..................................................................................................................45

Тема 5. Сугыш чоры хикәяләрендә фәлсәфи катлам. Ә.Еникинең сугыш чоры хикәяләре. "Бала", "Бер генә сәгатькә" хикәяләре......................51

Тема 6. Сугыштан соңгы елларда (1945- 1964) татар прозасы. ……… 68

Тема 7. Сугыштан соңгы татар прозасында документаль повесть жанры................................................................................................78

Тема 8. Сугыштан соңгы повестьларда тәнкыйди катлам....................82

Тема 9-10. Сугыштан соңгы татар прозасында повесть жанрының яңартылган реализмга сукмак салуы. Публицистик катлам.........................109

Тема 11. Сугыштан соңгы елларда татар поэзиясе үсеше…………..116

Тема 12. Сугыштан соңгы елларда татар драматургиясенең төп үсеш тенденцияләре…………………………………………………………121

Фәнни хезмәтләр, уку-укыту әсбаплары, методик кулланмалар һәм информацион чыганаклар..........................................................................

Терминологик сүзлекчә........................................................................

## Тема 1. Бөек Ватан сугышы елларында татар поэзиясе һәм драматургиясе үсеше

**Лекция 1**

**Аннотация.**1940-50 нче еллар татар әдәбиятының үзенчәлеге, төп өйрәнү предметы һәм бурычлары билгеләнә. Курсның методологик һәм нәзари нигезләре төгәлләштерелә.

**Ачкыч сүзләр:**поэзия, методология, реализм, романтизм, тенденция.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. Курсның өйрәнү предметы һәм бурычлары.
2. Башка предметлар белән бәйләнеше.
3. Чор әдәбиятына карата тәнкыйди фикерләр төрлелеге.

1940-50 нче еллар татар әдәбияты, аның үзенчәлеге, төп өйрәнү предметы һәм бурычлары. Курсның методологик һәм нәзари нигезләре. Аның әдәбият теориясе, фәлсәфә, әдәби тәнкыйть һ.б. арадаш фәннәр белән бәйләнеше.

Татар сүз сәнгате тарихында аерым баскыч буларак 1940-50 нче еллар әдәбияты, аның чикләре мәсьәләсе. Бу хакта әдәби-тәнкыйди фикердә карашлар төрлелеге, бәхәсләр. Әдәбиятның иҗтимагый тормыштагы вазифасына мөнәсәбәт үзгәрү, сүз сәнгате буларак танылуы.

Әдәбиятның яңарышы белән бәйле төстә нәзари фикердәге үсеш-үзгәреш. Сәнгатьчә фикерләү һәм сурәтләүдәге яңа алым, формаларның тууы, әдәбият белемендә бу турыдагы бәхәсләр.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. 1940-50 нче еллар татар әдәбиятының төп өйрәнү предметы һәм бурычлары нидән гыйбарәт?

2. Курсның методологик һәм нәзари нигезләрен төгәлләштерегез.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

2. Галиуллин Т. Шигърият баскычлары / Т.Галиуллин. – Казан: Мәгариф, 2002. – 229 б.

3. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.5: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. - 543 б.

**Лекция 2**

**Аннотация.**Лекциядә сугыш еллары татар поэзиясе һәм драматургиясенең үсеш-үзгәреш юллары билгеләнә, әдәби процесска хас төп үзенчәлекләр аерып алына.

**Ачкыч сүзләр:**поэзия, тенденция, поэтик алым, реализм, романтизм, мотив, миф.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. Сугыш чоры татар поэзиясендә иҗат юнәлешләре.
2. Сугыш чоры татар поэзиясендә идея бирелеше һәм пафос үзенчәлеге.
3. Сугыш чоры татар поэзиясендә фәлсәфә үзгәреше.

4. Сугыш чоры татар поэзиясендә дөнья сурәте үзгәреше.

5. Сугыш чоры татар поэзиясендә мифлаштыру күренешенең дәвам ителеше һәм мифологик мотивлар төрлелеге

6. Сугыш чоры татар поэзиясендә тематик һәм жанрлар төрлелеге.

7. Сугыш чоры татар драматургиясенең үсеш тенденцияләре.

Сугыш елларында поэзия иң актив әдәби төрләрнең берсен тәшкил итә, драма әсәрләре аз иҗат ителә. Иҗат психологиясен өйрәнүче галимнәр әдәбият тарихында тормыш-яшәешнең хәлиткеч чорларында, борылыш моментларында, күчеш вакытларында нәкъ менә поэзиянең алга чыгуын билгели. Бу чор татар әдәбиятына хас төп үзенчәлекләр:

1) ***Иҗат юнәлешләренең синтезы***. Утызынчы еллардан (1934 нче елдан) реализм иҗат юнәлеше, социалистик реализм иҗат агымы төп агымнарның берсе итеп билгеләнә, әдәбият шушы кысаларда үсә-үзгәрә башлый. Сугыш елларында реализм һәм романтизм бер-берсенә керешеп китә.

2) ***Пафос үзгәреше.*** Бу чор татар поэзиясендә иң төп пафос булып героик (Ф.Кәрим “Үлем уены”, М.Җәлил “Җырларым” һ.б.), трагик (Ф.Кәрим “Гөлсем”, М.Җәлил “Вәхшәт”) пафослар билгеләнә.

3) ***Фәлсәфә үзгәреше.*** Яшәү һәм үлем фәлсәфәсе үзәктә тора. Ул Яшәү – үлем – үлемсезлек формуласы аша бирелә, яшәү ил өчен көрәш, Ватан өчен үлем ил халкы күңелендә мәңге яшәү белән тәңгәлләштерелә... Бу төр фәлсәфә поэзия белән янәшдә драматургиядә дә урын ала.

4) ***Идея үзгәреше***. Утызынчы еллар татар әдәбиятында сыйнфый көрәш идеясе үзәктә торса, сугыш елларында ул патриотизм һәм дошманга каршы нәфрәт идеясе белән алмашына. Поэзиядә конфликт үзгәрә (“без / алар” конфликты “без, алар / дошман” конфликтына алмашына.

5) ***Поэзиядә дөнья сурәте.*** Шигъри әсәрдә авторның дөньяга карашы, фәлсәфәсе, уйланулары, мөнәсәбәте чагылыш таба. Күп очракларда дөнья моделе, картинасы бинар оппозицияләр ярдәмендә хасил була. Дөнья сурәтен

тергезү бинар оппозицияләргә нигезләнә: яшәү / үлем, бәхет / бәхетсезлек, уң / сул, яхшы / яман, якын / ерак, үткән / киләчәк һ.б.

Бу чор татар поэзиясендә иң төп бинар оппозиция булып **яшәү / үлем** оппозициясе тора. Моннан тыш **без / дошман** (М.Җәлил "Окоптан хат", "Тупчы анты" һ.б.), **туган җир / чит җир** (Ф.Кәрим "Шомырт куагы", "Бездә яздыр", М.Җәлил "Алман илендә" һ.б.), **сугыш / тынычлык** (Ә.Ерикәй "Караңгыда гына сугыш тынды", М.Җәлил "Чулпанга" һ.б.) бинар оппозицияләре актив.

6) шуңа бәйле ***мотивлар төрлелеге***. Архетипик образлар һәм мифологик мотивлар көчле. Сугыш чорында идеологик мотивлардан җиңүгә ышаныч, илне көрәшкә өндәү, дошманга нәфрәт һәм илне саклау хакында ант бирү мотивлары әйдәп бара (М.Җәлил «Әйдә, җырым», «Дошманга каршы», 1941; «Соңгы көрәшкә», 1941; «Тупчы анты» һ.б.). М.Җәлинең "Окоп поэзиясендә" яңа мотив буларак рус поэзиясендә киң урын алган илнең җимерелүе мотивы урын ала, бу үзенчәлек аның «Госпитальдән», «Европада яз» кебек шигырьләрендә дә чагылыш таба. Мәсәлән, Ф.Кәрим иҗатына мөрәҗәгать итсәк, шагыйрьнең "окоп поэзиясе" лирикасында идеологик мотивлардан ил азатлыгы өчен көрәш, җиңүгә ышаныч, дошманга нәфрәт һәм илне саклау хакында ант бирү мотивлары әйдәп бара. Ф.Кәрим әлеге мотивларны укучыга җиткерү барышында мин / дошман, сугыш / тынычлык, туган җир / чит җир кебек оппозицион вариантларга мөрәҗәгать итә, иң төп бинар оппозиция булып яшәү / үлемоппозициясе тора һәм аның төрле модификацияләре тудырыла: үлем / үлемсезлек, трагик / героик. Яшәү һәм үлем төшенчәләре сугыш чоры шигъриятенең буеннан-буена сурәтләнә, яшәү һәм үлемне аңлату вариантлары тасвирлау объектына әверелә. Совет мифының иң динамик, үзгәрүчән образы – герой архетипик образы Ф.Кәрим лирикасында герой-сугышчы кебек тәкъдим ителә. Әлеге үзенчәлекләрне аерым шигырьләр мисалында төгәлләштерик.

Илне саклау хакында ант бирү мотивы "Ант" (1942), "Ватаным өчен" (1942), "Диңгез ярында" (1942), "Исә җил" (1942), "Хәнҗәр" (1943) кебек шигырьләрнең үзәгендә ята. Моңа кадәр Туган илгә тугрылыгын раслаган ант һәм ышаныч образлары шагыйрь шәхесе белән Туган ил арасындагы

мөнәсәбәтне ачуда төп чарага әверелә. Мәсәлән, структур яктан мин / дошман оппозициясенә корылган “Ант” (1942) шигырендә ил фаҗигасе, гаилә фаҗигасе һәм бала фаҗигасе герой-сугышчының әрнү хисенә сәбәп булып әверелә, антның эчтәлеген тәшкил итә. Ант исә, бердән, шагыйрьнең илгә тугрылыгын, намусын раслау, икенчедән, үлемен аклау чарасына әверелә:

*Шушы балам өчен, синең өчен,*
*Нәселем өчен, Туган ил өчен,*
*Мылтык тотып баскан җиремнән*
*Бер адым да артка чигенмәм.*

Дошманга нәфрәт мотивы “Бездә яздыр” (1942), “Кемне кызганыйм” (1944), “Сугыштагы татар егетләренә” (1944), “Оясында” (1945) шигырьләрен әйдәп бара. шигырендә автор үзгә оппозициягә мөрәҗәгать итә. Тынычлык / сугыш оппозициясенә корылган шигырьдә Ф.Кәрим ике дөньяны – фашистлар кулындагы һәм илнең тыныч җирләрен каршы куеп сурәтли. Сугыш һәм матурлыкның каршы куелуы, гомумән, Ф.Кәрим яратып кулланган алымнарның берсе булып тора. Хат-монолог формасында иҗат ителгән шигырьдә яз образы өмет, яңару, якты киләчәк символына әверелә:

*Яшен уты белән күккә язып әйтәм:*
*Язы юкның яшәү хакы юк!*

Шигырь тукымасында үз-үзе белән каршылыкка кергән яз образы аша Ф.Кәрим гомумиләштерелгән фикерен, фәлсәфәсен җиткерә: фашизм кешелекне генә түгел, табигатьнең матурлыгын, асылын да юкка чыгара.

“Юл” (1942), “Разведкада” (1942), “Мин – гуманист” (1942) кебек шигырьләрне ил азатлыгы өчен көрәш мотивы бер бәйләмгә туплый. Мәсәлән, “Юл” (1942) шигырендә юл совет солдатының сугышка бару юлы, җиңүгә бару юлы булып тәгәлләшә. Лирик герой өчен ил азатлыгы өчен көрәш хакыйкать дәрәҗәсендә кабул ителә һәм шул яссылыкта ул солдатның хакыйкатькә бару юлы буларак та кабул ителә. “Кайгырма син” (1943), “Җиңү җыры” (1944) шигырьләре исә җиңүгә ышаныч мотивы тирәсенә туплана.

Идеологик мотивлар белән янәшәдә шагыйрь иҗатында яшәү һәм үлем

фәлсәфәсенең идеологик эчтәлектә активлашуы күзәтелә, үлем-үлемсезлек төшенчәләре — яшәүһәм үлем фәлсәфәсенең төп терәгенә әверелә. Ф.Кәримнең “Сөйләр сүзләр...” (1942), “Теләк” (1942), “Алга бара идек” (1942), “Окоп җыры” (1942), “Борчылу” (1944) шигырьләрендә яшәүнең төп максаты хакыйкать белән тәңгәлләшә, ә хакыйкать туган илне дошманнардан саклау рухы һәм шуның гамәлгә ашуы белән бәйләп куела, үлемгә фәлсәфи якын килгән әдип моңа кадәр бетү, югалу мәгънәләрендә килгән үлемне мәңгелеккә илтүче чара дип кабул итә; Ватан азатлыгы өчен үлем үлемсезлеккә, үлгәннән соң яшәүгә (азатлыгы өчен үлгәннәрне Туган ил бервакытта да онытмас, халык йөрәгендә мәңге яшәр гыйбарәсе шуңа тоташа) юл алу буларак кабул ителә, нәкъ менә шул яссылыкта үлем яшәү белән тигезләшә:

*Үлем турында уйлама,*
*Илең турында уйла,*
*Илең турында уйласаң,*
*Гомерең озын була.*
*(Ф.Кәрим «Сөйләр сүзләр бик күп алар... »)*

Шул рәвешле халыкны батырларча сугышырга өндәгән, әдәбиятны шул максатка буйсындырган идеология көрәшеп үлүне укучы күңеленә бердәнбер дөрес юл, хакыйкать дип сеңдерә.

Шагыйрьнең сугыш чоры лирикасында фаҗигалелек мотивы да урын ала. “Сибәли дә сибәли” (1942), “Иптәш” (1942), “Газиз әнкәй” (1943), “Ак күбәләк” (1944) кебек шигырьләрдә лирик геройның гаиләсеннән аерылу сәбәпле туган яки иптәшләрен, сугышчы дусларын югалту ачысы белән сугарылган шәхси фаҗигасе сурәтләнә, алар фашизмга нәфрәт хисе белән тулыландырылып, аларның вәхшилеген фаш итү, йөрәк әрнүен, җан суынуын ачып бирү эчтәлеге белән байый. Мәсәлән, “Сибәли дә сибәли” (1942) шигырендә якын иптәшен югалту хәсрәтеннән газапланучы лирик герой алга чыга. Көзгеле композициягә корылган шигырь тукымасында сибәли дә сибәли рефренының кабатлануы, сынландыру алымы, трагик пафос, кабатлау композицион алымы, үзенчәлекле метафора-эпитетлар – барысы да сугышчы-лирик геройның хис-кичереш

дәрәҗәсен көчәйтү, фаҗигалелек мотивын тирәнәйтү чарасына әверелә:

*Кайгыдан каралып торган*
* Япь-яшь нарат төбенә*
* Япь-яшь иптәшне күмгәнне*
*Күрә бары төн генә.*
* Япь-яшь иптәшне күмәбез,*
*Беркем берни сөйләми,*
*Көзге төндә яңгыр гына*
*Сибәли дә сибәли.*

7) ***Архетипик образлар бирелеше.***

Советчыл мифның үзәгендә архетипик образның төрле модификацияләре тудырыла. Совет мифының иң динамик, үзгәрүчән образы – герой архетипик образы төрле модификацияләрдә тәкъдим ителә: социалистик хезмәт герое, герой-сугышчы, герой-корбан һәм герой-сәяси эшлекле.

8) ***Тематик төрлелек***. Иң төп тема булып *сугыш темасы* тора. Ул төрле тематик яссылыкларда сурәтләнә:

а) дошманга нәфрәт тәрбияләүгә йөз тоткан әсәрләр (Ә.Исхак “Кангакан”, М.Җәлил “Тупчы анты”, К.Нәҗми “Фашизмга үлем” һ.б.)

б) солдатны сугышка озату белән бәйле сагыш хисен, хушлашу тудырган фаҗигане сурәтләгән әсәрләр (К.Нәҗми “Озату”)

в) хакыйкатьне тапкан солдат кичерешләрен сурәтләгән әсәрләр (Ә.Ерикәй “Караңгыда гына сугыш тынды”, Ф.Кәрим “Сөйләр сүзләр бик күп алар” һ.б.)

Моннан тыш ***туган ил*** темасы (Ш.Мөдәррис “Эх, шул килеш” һ.б.).

***Мәхәббәт темасы*** (М.Җәлил “Күлмәк”, “Томаулы гыйшык”, Ф.Еәрим “Шомырт куагы” һ.б.).

9) ***Жанрлар төрлелеге***. Иң төп жанр – лирик шигырь. Лирикада гражданлык лирикасы, күңел лирикасы жанрлары актив. Лиро-эпик төрара форма да үсеш ала**.** Балладалар иҗат ителә (М.Җәлил “Ана бәйрәме”, “Күлмәк”, Ф.Кәрим “Шомырт куагы”, С.Хәким “Колын”, Ә.Исхак “ялгыз нарат”, “Ике

сугышчы” һ.б.). Бу жанрның активлашуы героик-романтик сюжетлар сурәтләү теләгенә тоташа, көрәшченең чиксез батырлыгын сурәтләүгә юнәлтелә.

Поэма жанрына да еш мөрәҗәгать ителә.Эпик поэмалар (Ф.Кәрим “Гөлсем”, “Үлем уены”, Н.Арслановның “Мәхәббәт”, С.Батталның “Берлинга һөҗүм”, Ш.Мөдәрриснең “Тупчы Ваһап” һ.б.) һәм лирик поэмалар (Ф.Кәрим “Кыңгыраулы яшел гармун”, “Идел егете”, С.Баттал “Тын диңгез ярларында”, Ә.Маликовның “Атаудагы хисләр” һ.б.) языла.

Сугыш чоры драматургиясендә бер пәрдәлек пьесалар язу активлаша. Сугыштагы кешене сурәтләү омтылышы чынбарлыктан ерак торган әсәрләр язылуга китерә (Р.Ишморат «Дошман лагеренда», М.Әмир «Партизан Иван», 1941; Т.Гыйззәт «Төнге сигнал», 1941). Халыкның тылдагы фидакарь хезмәтен үзәккә куеп язылган әсәрләрдә (Р.Ишморат «Кайту», 1942; М.Әмир «Гөлҗамал», «Миңлекамал», 1944) дә сугыш проблематикасы үзәктә тора. Героика, соклангыч батырлыклар турында сөйләп, көрәшкә рухландыру омтылышы драматургиядә тарихи теманың популярлашуына китерә (Н.Исәнбәт «Җирән чичән белән Карачәч сылу», 1942; М.Гали, Х.Уразиков «Каюм Насыйри», 1944; Н.Исәнбәт «Гөлҗамал», 1944). Ләкин ВКП(б) Үкның 1944 ел 9 август карары белән татар әдәбиятында һәм сәнгатендә тарихи темаларны яктыртуга киртә куела, сугыш елларында аеруча ныгыган халык авыз иҗаты белән бәйләнешләргә тискәре мөһер сугыла. Бер үк вакытта, сугыш чорын нигездә халыкның ил азатлыгы өчен көрәштәге батырлыгы ноктасыннан күрсәтүнең генә хуплануы, сугыш ачкан күп кенә сәяси, иҗтимагый яраларның әдәбиятка кертелмәве сугыштан соңгы чор сәхнә әдәбиятына да йогынты ясый.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Сугыш чоры татар поэзиясендә фәлсәфә ни рәвешле үсеш-үзгәреш кичерә, аның нинди алшартлары бар?

2. Чор әдәбиятында мифлаштыру күренешенең иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-эстетик нигезләре нидән гыйбарәт?

3. Сугыш чоры татар әдәбиятында нинди мотивлар алгы планга чыга?

**Әдәбият исемлеге.**

1. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

2. Теория литературы. Т.4. Литературный процесс. – М.: ИМЛИ РАН, «Наследие», 2001. – 624с.

3. Галиуллин Т. Шигърият баскычлары / Т.Галиуллин. – Казан: Мәгариф, 2002. – 229 б.

4. Кулаков В. Поэзия как факт. Статьи о стихах / В.Кулаков. – М.:Новое литературное обозрение, 1999. – 400 с.

5. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.5: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. - 543 б.

## Тема 2. Сугыш чоры татар поэзиясе контекстында М.Җәлил иҗаты (1906 – 1944)

**Лекция 1**

**Аннотация.** Лекциядә М.Җәлилнеңтормыш юлына күзәтү ясала, башлангыч чор иҗатына хас төп үзенчәлекләр билгеләнә, чор әдәбиятына алып килгән яңалыклары, традицияләрне дәвам итүе тикшерелә.Утызынчы еллар татар поэзиясенә алып килгән яңалыгы лирик һәм лиро-эпик әсәрләре мисалында раслана.

**Ачкыч сүзләр:**поэзия, тематика, реализм, романтизм, поэтик алымнар, мифологик мотив һәм образ.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат биографиясе.
2. Шагыйрьнең 1920 нче еллар иҗатының үсеш тенденцияләре.

Татар халкының каһарман улы, яшәү мәгънәсен туган халкына хезмәттә күреп, үзеннән соңгы буыннарга үлмәс иҗат калдырган, «Моабит дәфтәрләре» белән милли шигъриятне дөнья киңлекләренә чыгарган, язмыш сынауларына бирешмичә, үлемен батырларча кабул иткән көчле рухлы шәхес, герой-шагыйрь буларак танылган Муса Мостафа улы Җәлилов 1906 елның 15 февралендә элеккеге Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә. 1913 елда Мусаның әтисе Мостафа абзый, ишле гаиләсен ияртеп, Оренбург шәһәренә күчә һәм вак-төяк сату эшләре белән шөгыльләнә башлый. 1918 елны ул туган авылына кире кайта һәм бер елдан шунда вафат була.

Муса алты яшеннән авыл мәктәбенә укырга керә, гаилә шәһәргә күчкәч, укуын «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Мәдрәсә елларында (1914–1917) матур әдәбият әсәрләрен яратып укый, Тукай, Дәрдемәнд, С.Рәмиев иҗатлары белән якыннан таныша, шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр язып, аларны мәдрәсәдәге кулъязма журналга урнаштыра бара. 1919 елның декабрендә туган авылы Мостафага кайта һәм мәктәп балаларын, яшүсмерләрне бердәм оешмага туплау буенча культура-агарту эшләре алып бара. 1920 елның гыйнварында М. Җәлилнең актив катнашы белән Мостафа авылы яшьләренең комсомол ячейкасы төзелә. Оренбургтагы хәрби уку йортларында белем алганнан соң, әдәби мәйданга омтылган яшь шагыйрь 1922 елның көзендә Казанга килеп, журналистлык һәм иҗат эшенә кереп китә. Башта газетада эшли, белемен күтәрү максатыннан Татрабфакта укый. 1925 елда аның «Барабыз» исемле беренче китабы дөнья күрә.

1925–1927 елларда ул янә Оренбург якларында комсомол эшләрендә катнаша, хәтта 1927 елда комсомолның Бөтенсоюз киңәшмәсенә делегат итеп Мәскәүгә җибәрелә һәм шунда эшкә калдырыла. «Кечкенә иптәшләр»,

«Октябрь баласы» исемле балалар журналларын оештырып, аларның мөхәррире була. 1927–1931 елларда Мәскәү дәүләт университетының әдәбият-сәнгать факультетында белем өсти, 1933–1934 елларда башкалада татар телендә чыга торган «Коммунист» газетасы җитәкчеләренең берсе була, СССР Язучылар берлегенә кабул ителә, 1935 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында оештырылган Татар опера студиясенә чакырыла. 1939 елда язмыш аны кабат шул студия белән Казанга кайтара: әүвәл театрда әдәби хезмәткәр була, соңрак ТАССР Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе итеп билгеләнә.

Сугыш башлангач, Җәлил политруклар курсын тәмамлый, «Отвага» газетасында эшли, 1942 елның февралендә Төньяк-Көнбатыш фронтка җибәрелә. Волхов фронтына эләгә, 1942 елның 26 июнендә әсирлеккә төшә һәм Германиягә озатыла. Алманнар төрки–татар әсирләреннән легион төзеп, аны фронтка җибәрергә әзерлиләр. Лагерьда фашистларга каршы яшерен оешма төзелә, М.Җәлил шушы оешма эшендә катнаша, җитәкчеләренең берсе була. Әлеге оешма поляк партизаннары белән элемтә урнаштыра, 1943 елның февралендә легионның Көнчыгыш фронтына җибәрелгән беренче батальоны белорус партизаннары ягына чыга. Соңрак дошманнар әлеге оешманың эзенә төшә, җәлилчеләр дә җәзага тартыла.  1944 елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлилнең һәм 11 көрәшченең башы киселә.

1956 елның 2 февралендә СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән Муса Җәлилгә Ватан сугышы чорында күрсәткән тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелә, ә әсирлектә тудырган поэтик иҗаты — бөтен дөньяга мәшһүр «Моабит дәфтәрләре» Ленин премиясенә лаек була. М.Җәлил үзенең истәлекләрендә: «*Дөньяда шулай итеп яшәргә кирәк: үлгәннән соң да үлмәслек булсын,— яшәүнең бөтен максаты шунда түгелмени?! Без үлемнән курыкмыйбыз дип әйтәбез икән, бу без яшәргә теләмибез, безгә һәммәсе барыбер дигән сүз түгел әле. Без тормышны бик яратабыз, яшәргә телибез һәм шуңа күрә дә үлемгә җирәнеп карыйбыз. Әгәр дә синең үлемең кирәк икән (Ватан өчен сугышта) һәм Ватан өчен үзең теләп*

*кабул иткән бу үлем картлык көннәренә кадәр булган утыз-кырык еллык тыныч хезмәттә үткән гомереңне каплый ала икән, мин иртә һәлак булдым дип кайгырырга һичбер сәбәп юк...*», - дип яза. Бу сүзләрдә шагыйрьнең иҗатында кызыл җеп булып сузылган яшәеш фәлсәфәсе, тормыш позициясе, үлем-үлемсезлеккә, Ватанына мөнәсәбәте чагыла.

Муса Җәлилнең иҗат мирасын берничә баскычка бүлеп карарга мөмкин. Инкыйлаби көрәш һәм гражданнар сугышы алып килгән революцион романтика белән мавыккан эзләнүләр чоры (1920–1936 еллар) иҗаты яшьләрнең яңа сәнгать тудыру омтылышы белән ясаган тәҗрибәләренә аваздаш: илдә баручы яңалыкларга ихластан ышанган  яшь шагыйрь азатлык өчен көрәшкә дан җырлый, җимерү фәлсәфәсен уздыра. Егерменче еллар иҗаты тулысы белән советчыл идеологияне тезмә формада тәкъдим итүче агитация–пропаганда шигырьләре буларак бәяләнә ала һәм аларда идеологик эчтәлекле өч төп мотив күзәтелә: *якты киләчәккә бару, изге көрәш юлында корбан булу, көрәш*. Әлеге мотивлар, нигездә, шигырьдән-шигырьгә кабатлана баручы ил, байрак (әләм), көрәшче кебек тотрыклы сәяси-мифологик образлар ярдәмендә хасил була һәм алар шагыйрьгә романтик, чынбарлыктан ераклашкан көрәш рухын тергезергә ярдәм итә.

Әйтик, «Күк утлары» (1923) шигыре яңа тормыш төзү өчен көрәш картинасын сурәтли: «*Безнең өстә анда һаман әле / Ут чәчәләр, туплар аталар./ Яндырырга теләп яшь әләмне / Тартышалар, чиктән ашалар*». Байрак яки әләм мифологик образы әлеге яңа тормыш төзүче илнең билгесе, символы булып килә һәм көрәш мотивын барлыкка китерә. Аның икенче мәгънәсе яңа тормышның хезмәт ярдәмендә корылачагына ишарә ясый: «*Кадап куйгач биек бер урынга / Эш әләмен, ирек утларын*…». Шигырьдә әләмне күккә алып менү — ил хакында дөньяга хәбәр итү кебек тә аңлашыла. Шушы мәгънәләрдә ул шагыйрьнең башка шигырьләрендә дә еш очрый, яңа мәгънәләр дә ала. «Бәйнәлмиләл» (1921) шигырендә тигезлек өчен көрәш, көрәшкә өндәү символы, «Янчы, дөнья, янганыңны мин карыйм…» (1922) шигырендә җиңү хәбәрчесе кебек файдаланылган.

Якты киләчәккә бару, шул юлда көрәш мотивлары ил образы белән тыгыз бәйләнгән, ул яңа тормыш төзүче, якты киләчәк хакына көрәшүче, бәхеткә баручы ил булып тәгълләшә. «Ил кызы», «ил шатлыгы», «киң ил», «ил кырлары», «илкүләм көрәш», «ил төзелешләре», «ил батырлары», «ил халкы», «ил җәннәте» кебек образ, сүз–сурәтләр шушы мәгънәне төрле яклап көчәйтүгә хезмәт итә. Мондый лирик әсәрләрдә безнең ил / башка илләр кебек үзенчәлекле каршылыкта барлыкка килә, туган илгә оппозициядә башка илләр, коллыкта яшәүче дәүләтләр, көрәш юлына чыкмаган илләр куела («Кышкы шигырь», 1935). Көрәшкә өндәп язылган «Парча» (1922) шигырендә, мәсәлән, «ирек дөньясына» юнәлергә тиеш ил образы тудырыла, «ил» иҗатны бәяләүче урын кебек гомумиләштерелеп тә аңлана. Аерым лирик әсәрләрдә ил образы бердәмлек мәгънәсе белән тулыландырылган вариантта да урын ала. «Йөрәктән» (1923) шигырендә, әйтик, җирдә якты киләчәккә ышанучыларның күплеге ил шатлыгын билгели кебек идея үзәккә куела:

*Куркулардан ерак бу теләкләр,*
*Теләктләшләр – җирдә җыйнау без,*
*Ил шатлыгы – мондый яшь йөрәкләр*
*Мин берүзем түгел – меңәү без!*

Изге көрәш юлында корбан булу һәм көрәш мотивлары белән бәйле көрәшче образы исә дошманнарга каршы, ил бәхете һәм азатлыгы өчен көрәшкә нисбәтле туа, «ил улы», «ил кызы» буларак карала. Җәлилнең бу чорда иҗат ителгән «Сугышта» (1920), «Үлем алдыннан» (1923), «Әсирлектә» (1923) кебек шигырьләрендә көрәшчегә каршы куелган дошман — илдәге социалистик үзгәрешләрне кабул итмәүче шәхес образы күзәтелә. Ул илдәге үзгәрешләрне якламаган, яңа тормыш юлына аркылы төшүче, илне бәхеткә чыгаруга комачаулаган кеше булып тәгълләшә. Көрәшкә күтәрелгән, яраланган лирик герой исә үз максатын «изге көрәш» дип атый, шуңа кушыла алуы белән горурлана, көрәш юлында табылган батырлык культы алга сөрелә:

*Без әле яшьләр,*

*Сугышта булмадык,*

*Үтерешмәдек,*

*Сөңгеләр очлап, кылыч кайрап, янап,*

*Ут-дары астында,*

*Кайда йөзмәдек.*

*Ә... шунда да*

*Көн дә көрәш,*

*Көн дә...* («Җиңәбез», 1926).

М.Җәлилнең шушы еллар иҗатында урын алган бәхет мотивы да, нигездә, идеологик эчтәлектә калыплаша. Шагыйрьнең лирик герое батырларча үлү үлемсезлек китерә, бәхет көрәшче булудан гыйбарәт дип белдерә. Мәсәлән, «Бәхет» (1919) исемле беренче шигырендә үк үзен батыр сугышчы итеп тойган лирик герой халыкны азатлык өчен көрәшкә күтәрү хыялы белән яна, шәхси бәхетне көрәштә табарга омтыла. Бу чорда иҗат ителгән аерым шигырьләрдә совет илендә яшәүне иң зур бәхеткә санау рухы өстенлек итә. «Кышкы шигырь»дә (1935) дә бәхет мотивы нәкъ әнә шундый эчтәлектә ачыла:

*Кояш!*

*Нинди тормыш бездә!!.*

*Бәхетле без икебез дә:*

*Данлыклы, шат илнең җырын*

*Җырлау насыйп бүген безгә!*

«Васыять урынына» (1922), «Нигә бирдең җиләк» (1922), «Хатирә» (1922) кебек шигырьләре исә лирик геройның мәхәббәт шатлыгыннан, сөю ләззәтеннән юану, бәхет табарга омтылышы турында сөйли. Ләкин аларда да лирик герой һәм ул яшәгән тормыш — көрәш заманы кебек аңлашыла.

Егерменче елларның икенче яртысыннан М.Җәлил шигырьләрендә эчтәлек һәм форма бердәмлеге лирик-фәлсәфи стильдән, революцион романтизмнан социалистик реализмга, реалистик поэзия казанышларына йөз тоту, шартлы романтик сурәтлелектән реалистик принципларга күчеш белән

билгеләнә. Мотивлар һәм төп мифологик образлар сакланса да, 1924–1929 елларда М.Җәлил аларны яктыртуның яңа юлларын эзли башлый, иҗатында, гомумән татар яшьләр шигъриятендәге кебек үк, үткән / бүгенге каршылыгы үзәккә куела. Мәсәлән, «Үткән көннәрдән» (1924), «Әти үлгәч» (1924), «Ленин туды» (1924), «Безнең авыл» (1927) кебек шигырьләре яңа тормышны элекке чорны кире кагу аша данлый.

Шигырь тукымасында корган каен, карт сука образлары үткәннең югалуы, бетүе хакында хәбәр итсә, яшь каен, трактор образлары бүгенге һәм киләчәк билгесенә әверелә. «Сукачы угълы» (1923), «Боз ага» (1923), «Иске Себер җыры» (1924) кебек шигырьләр үткәнгә үкенеч белдереп, бүгенгене көрәш чоры итеп карап, аның белән горурланып языла, ач, авыру, эш белән ватылган «әти», «әни», «сука», «кара тормыш» кебек сүз–сурәтләр үткәннең билгеләренә әверелә. Бүгенгегә нисбәтле, Ленин, завод, трактор, туй-бәйрәм образ-детальләре калка.

М.Җәлилнең Бөек Ватан сугышына чаклы иң җитлеккән, лирика һәм лиро-эпикада матур әсәрләр тудырган чоры буларак билгеле 1932–1941 еллар иҗатында мотивлар үзгә төсмер ала: *яңа тормышны данлау, дошманнарга нәфрәт белдерү, көрәш* мотивлары аерылып чыга.

Яңа тормышны данлау мотивы алга чыккан лирик әсәрләрдә сәясәтчеләр образларының мифлаштырылуы – дөнья мәдәниятендә билгеле архетиплар теориясе белән бәйле рәвештә сурәтләнүе күзәтелә.Ленин образы акыллы карт архетибын идеология кысаларына «буйсындырып» калыплаша башлый. Мәсәлән, «В.И.Ленин» (1930), «Уналтынчы удар» (1930) һ.б. шигырьләрдә көрәшне җитәкләүче Ленин образын изгеләштерү күренә, мифлаштыру барышында яктылык, кояш һәм ут символик образлары ярдәмгә килә. Акыллы карт архетибының үзенчәлекле «варианты» буларак, ул халыкны, дәүләтне алга җибәрүче, юл күрсәтүче юлбашчы функциясендә сурәтләнә. Әләм образы да Ленин әләме кебек уйнатыла. Бераз соңрак М.Җәлил иҗатында Киров, Сталин образларын мифлаштыручы шигырьләр дә пәйда була. «Сталинга» (1936), «Без

кул күтәрәбез» (1937), «Сталин турында җыр» (1937) кебек шигырьләре шул хакта сөйли. Яңа тормышны данлау мотивы җыр, марш формаларына мөрәҗәгать итүгә дә китерә («Кызыл очкыч җыры» (1933), «Комсомол бригадасы җырлары» (1933) һ.б.), ил төзүче, көрәшче, ил кызы, ил улы образларын калкыта.

М.Җәлил иҗатында үтәли күзәтелүче дошманнарга нәфрәт белдерү мотивы бу чорда яңа образ – эчке дошман образы аша беркетелә. Дошман / карак / колхоз милкен урлаучы /ялкау/ битараф кебек төгәлләшеп, ул ил бәхетенә кул сузучы статусына куела. «*Илгә биргән антым бар,/ Күк юрга!/ Җибәрмәмен якын да / Бу кырга*!» кебек риторик өндәүләр лозунг сүзләре кебек яңгырый. Көрәшче–герой исә балыкчылар, челюскинчылар, колхоз кызлары, диңгезчеләр, төз атучы – «кызыл карчыгалар», кызылармеецлар, милиционер кызлар образларыннан җыела.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. М.Җәлилнең тормыш биографиясенә күзәтү ясагыз?
2. Муса Җәлилнең 1920-30 нчы еллар иҗатына нинди үзенчәлекләр хас?
3. Шагыйрьнең бу чор иҗатында нинди алымнар һәм мотивлар өстенлек итә?

**Әдәбият исемлеге.**

1. Галиуллин Т., Гафиятуллина Н. Керсез йөрәк монологы / Т.Галиуллин., Н.Гафиятуллина //Җәлил М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 5-20.
2. Заһидуллина Д. М.Җәлил иҗатында мифологик образлар / Д.Заһидуллина // Муса Җәлил: иҗаты һәм батырлыгы. XXI гасырдан караш. – Казан, 2007. – 69-73 б.
3. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

4. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.5: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. - 543 б.

**Лекция 2**

**Аннотация.** Лекциядә М.Җәлилнең утызынчы еллар һәм “окоп поэзиясе” иҗатына хас төп үзенчәлекләр билгеләнә, чор әдәбиятына алып килгән яңалыклары, традицияләрне дәвам итүе тикшерелә, төп мифологик мотивлар аерып билгеләнә.

**Ачкыч сүзләр:**поэзия, тематика, реализм, романтизм, поэтик алымнар, мифологик мотив һәм образ.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. Муса Җәлилнең 1930 нче еллар иҗатына бәя.
2. Муса Җәлилнең сугыш чоры иҗаты: этаплары, “окоп поэзиясе” яки фронт лирикасының үсеш-үзгәреш тенденцияләре.

Утызынчы елларның икенче яртысыннан шагыйрьнең дөнья барышын, җәмгыять үсешен тирәнрәк аңлый баруы, идеологиягә мөнәсәбәте үзгәрүе иҗатының да яңа төсмерләр белән баюына этәрә: символик образлар аркылы җәмгыятькә җитлеккән караш сизелә башлый, геройның эчке дөньясын тасвирлауга игътибар арта. Халык авыз иҗатыннан килгән образларны файдалану, символлар куллану татар шигъриятенең борынгыдан килгән традицияләреннән файдалануга китерә. Мәсәлән, «Хат ташучы» (1938) поэмасында яңа тормышны данлау мотивы бригадир, иген үстерүче Фәйрүзә белән хат ташучы Тимербулатның мәхәббәт тарихына бәйле яктыртыла.

Идеологик эчтәлекле сызыкта яңа тормыш төзүче шәхеснең рухи формалашу, җитлегү тарихы үзәккә алынып, патриотизм рухында хәл итепә, совет чынбарлыгын мактау белән үрелеп китә. Шуның белән янәшәдә мәхәббәт тарихы хакында сөйләүче икенче сызыкта халык җырларыннан алынган сурәтләү чаралары, табигать матурлыгы, җыр образы, төсләр символикасы мәхәббәтнең гүзәллеген ачуга юнәлтелә: *«Буе зифа тал кебек, йөзе алсу таң кебек. Йөз карашы Чулпан кебек, сүзе татлы бал кебек», «Ялкын күзле Фәйрүзәкәй һәркемгә якын иде»* һ.б.

Бу чор лирикасындагы сыйфат үзгәреше көрәш мотивына бәйле көрәшче–батыр егет схемасының пәйда булуында да чагыла. Ул моңа кадәрге лирик әсәрләрнең үзәгендә торган  көрәшче мифологик образын соцреализм кысаларыннан алып чыга. Батыр егет  акбүз ат, үткен кылыч детальләре ярдәмендә ачыклана, милли–мифологик төсмерле килеп чыга, татар әкиятләреннән күчкән батыр көрәшчегә әверелә. Менә «Батыр егет турында җыр»дан (1936) бер өзек: «*Батыр егет китте акбүз атта / Туздырырга дошман сафларын./ Акбүз аты кайтты ялгыз гына,/ Батыр егет үзе кайтмады*». Шигырьләрдәге татар халык җырларына охшатып стильләштерү күренеше бу тәэсирне көчәйтүгә китерә.

Җәлил әсәрләрендә еш мөрәҗәгать ителгән  байрак яки әләм көрәш билгесе статусында кала, ил образы исә «туган ил» кебек яңгыраш ала. Гөл чәчәкләре, таң җиле, чык төшкән үләннәр, Чулпан йолдыз, куш алмагач кебек милли әдәбият өчен традицион образ–детальләр «яңа тормыш өчен көрәшүче ил» формуласын – «татарлар яши торган ил» формуласы белән алыштыра. 1938–1941 еллар шигъриятендә ил образы Ватан–ана төсендә бирелә башлый («Ана» һ.б.), җирән кашка, урман, өянке, ал чәчәкләр детальләре шулай ук милли яңгыраш хасил итә.

Әлеге сыйфат үзгәреше  Җик–мәргән хакындагы мифологик сюжетка нигезләнгән «Алтынчәч» (1940) либреттосында да күренә. Әсәр тукымасында көчле рухлы, язмышның сындырып сынауларына да бирешмәгән, бетүгә хөкем ителгәннән соң да югалмаган Тугзак ана татар халкының символик

гәүдәләнеше, башбирмәс образы булып аңлашыла: «*Бетермәкче идең ыругымны, Менә – үзем, менә – улларым. Халык мәңге үлми*». Җик-мәргән – аның лаеклы дәвамы да – шул мәгънәви яссылыкта кабул ителә, Алтынчәч азатлык символы булып төгәлләшә. Җәлил үзе дә, Алтынчәч образын аңлатып, болай дип яза: «Алтынчәчне азатлык символы итеп күздә тотып, мин Җикнең Алтынчәчкә булган мәхәббәтенә тирәнрәк мәгънә бирергә тырыштым. Бу – азатлыкны, бәхетне ярату. Алтынчәч – Җикнең бәхете, өмете, азатлыгы. Димәк, ул халыкның да бәхете, өмете һәм азатлыгы. Менә ни өчен либретто «Алтынчәч» дип аталды». Татар халкының азатлык, бәйсезлек өчен көрәшен гәүдәләндерү аша субъектив эчтәлектә Муса Җәлил халыкның шул чордагы яшәешен чагылдыра, әсәрне халкын Тугзак ана кебек батыр булырга чакыру идеясе белән баета. Әнә шул рәвешле шагыйрнең 1920-1930 нчы еллар иҗатында сыйфат үзгәреше идеологик мотивлардан милли традицияләргә йөз белән борылуга таба хәрәкәт итә башлый һәм бу үзенчәлек сугыш чоры иҗатында тулырак тормышка ашырыла.

Ил өчен көрәш темасы әйдәп барган 1941-1944 еллар иҗаты Җәлил шигъриятендә аерым бер чорны тәшкил итә. Лирикасының эчке яңгырашына, фәлсәфи фикернең тирәнрәк аңланыш алуына, сүз-сурәтнең яңа баскычка күтәрелүенә бәйле төстә әдәби тәнкыйть бу чорны шартлы ике өлешкә бүлә: 1941-1942 еллар – фронт лирикасы һәм 1942-1944 еллардагы тоткынлык иҗаты.

Фронт лирикасына мөнәсәбәтле шигырьләр, нигездә, башланып киткән Бөек Ватан сугышына мөнәсәбәт белдереп языла. Шуңа күрә аларның күбесенчә яшәү / үлемоппозициясенә корылуы күзгә ташлана: үлемгә фәлсәфи якын килгән әдипләр моңа кадәр бетү, югалу мәгънәләрендә килгән үлемне мәңгелеккә илтүче чара дип кабул итәләр; Ватан азатлыгы өчен үлем үлемсезлеккә, үлгәннән соң яшәүгә (азатлыгы өчен үлгәннәрне Туган ил бервакытта да онытмас, халык йөрәгендә мәңге яшәр гыйбарәсе шуңа тоташа) юл алу буларак кабул ителә, нәкъ менә шул яссылыкта үлем яшәү белән тигезләшә:

*Әйдә, җырым,*

*батыр җиңү дәртен*

*Алып керик ялкын эченә.*

*Мин калмасам җирдә,*

*син калырсың*

*Һәйкәл булып үлмәс эшемә.*

*(«Әйдә, җырым!», 1941).*

Шагыйрьнең бу чорда иҗат ителгән шигырьләрендә җиңүгә ышаныч, илне көрәшкә өндәү, дошманга нәфрәт һәм илне саклау хакында ант бирү мотивлары әйдәп бара. Мәсәлән, «Хуш, акыллым» (1941), «Окоптан хат» (1941), «Чулпанга» (1941) кебек шигырьләр илне, якыннарны саклау турында ант бирү, җиңүгә ышаныч мотивлары белән сугарыла. Яңа мотив буларак рус поэзиясендә киң урын алган илнең җимерелүе мотивы «Госпитальдән» (1941), «Европада яз» (1942) кебек шигырьләрендә чагылыш таба. Сугышның беренче көннәрендә язылган «Әйдә, җырым» (1941), «Дошманга каршы» (1941), «Соңгы көрәшкә» (1941), «Тупчы анты» (1941) кебек шигырьләрендә дошманга нәфрәт, илне көрәшкә өндәү мотивлары алга чыга. Ватанны, Туган илне ярату да дошманга, фашистларга көчле нәфрәт белән аерылгысыз бәйләнештә алына, көрәшче – сугышка керүче, дошман – Гитлер, фашист, талаучы кебек сурәтләр тотрыклы:

*Ил!*

*Алдыңда синең мин ант итәм,*

*Шаһит булсын кулым ярасы:*

*Гитлер явын тар-мар итми торып,*

*Якты күрмәс күзем карасы! («Госпитальдән», 1941).*

Мондый шигырьләрдә ил образы көчле бирелә.«Чын ирекнең гөрләп чәчәк аткан бакчасы» шагыйрьнең алдагы әсәрләре белән чагыштырганда үзгәреш кичерә: Туган ил— туганнар, кадерле кешеләр, тыныч туган җир

образлары аша төгәлләшә һәм көрәш барган җир түгел, нәкъ менә сугышка каршы куелган тынычлык җире кебек гомумиләшә. Үлемгә мөнәсәбәт үзгәреп, сагыну, шом, кайгы хисләре якыннарыннан мәңгегә аерылышу эчтәлеге белән кушыла. Мәсәлән, «Хуш, акыллым» (1941) шигыре сөйгәненнән, туган ягыннан аерылуга газапланган лирик герой кичерешләрен үзәккә ала. Сөйгәненнән аерылу, үлемнең янәшәдә генә йөрүе, кабат күрешергә мөмкинлекләрнең чикле булуы хис сәбәбенә әйләнә. Үлемгә мөнәсәбәт ике яклы төс ала: батырларча үлемнең үлемсезлеккә, мәңгелек яшәешкә юл алуын аңлаган, аны шатланып кабул иткән лирик герой «татлы йокының» сөйгәненнән мәңгегә аерачагын уйлап сагышлана, шомлана һәм: *«Татлы булыр йокы... Тормышымны батырларча бирсәм ил өчен, Тормыш дустым – синең йөрәгеңдә дәвам итсә йөрәк тибешем»,* – дип, сөйгәне йөрәгендә «яшәячәгенә» өметләнеп юана:

*Ахыр чиктә синең саф сөюең*
*Җиңеләйтер үлем газабын,*
*Илемне һәм сине сөюемне*
*Каным белән җиргә язармын.*

Шигырьләрдә романтик (Чулпан йолдыз, җитез аргамак, таң, гөл) һәм натуралистик (кан, үч, нәфрәт, каска, штык) образлар янәшәлеге еш күзәтелә, Җәлил төп эчтәлекне бер поэтик образга җыйнап тәкъдим итә башлый. Мәсәлән, «Чулпанга» (1941) шигырендә метафора сыйфатында килгән Чулпан йолдызның күпмәгънәлелеге лирик герой хисләрен, идеяне бер үзәккә туплый.

Бердән, ул татар шигърияте традициясендәгечә ялгызлыкны, сагышны чагылдырып, аерылу хәсрәтен сынландырса, икенче яктан, лирик «мин»нең җиңүгә ышанычы, илнең матур киләчәгенә өмете булып яңгырый *(«Шатланырмын күреп һәр таң саен үз илемдә Чулпан калыкканын»*). Үлем-шатлык кебек капма-каршы төшенчәләрнең янәшәлеге идея буларак Туган илне генә түгел, якыннарны саклап, алар азатлыгы хакына дөньядан китү бәхет ул дигән фикерне калкыта *(«Синең бәхтең өчен һич сызланмый Каршы алам көлеп үлемне...»*). «Яшь» (1942) шигырендә берничә мәгънәви эчтәлекне үзенә

туплаган күз яше образына мөрәҗәгать итеlә. Бердән, ул аерылу хәсрәтен гәүдәләндерсә *(«...Ике генә тамчы яшең тамды Яңагыма уйчан йөзеңнән»*), икенче яктан, нәфрәт билгесе булып тора *(«изге яшең илнең үч һәм нәфрәт Уты булып үсәр күңелдә»*) һәм, тагын да киңәйтелеп, ил хәсрәте, нәфрәте булып гомумиләшә *(«Ачылыгын халкым күз яшенең Дошман шунда татып карасын!..*).

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Шагыйрьнең “окоп поэзиясе” чоры иҗатында нинди мотивлар урын ала?

2. Шагыйрьнең “окоп поэзиясе” чоры иҗатында ил, әләм, көрәшче образларының мәгънәви бөтенлеген аңлатыгыз.

3. Муса Җәлилнең “окоп поэзиясе” чоры иҗатында фәлсәфә бирелешен аңлатыгыз.

**Әдәбият исемлеге.**


2. Галиуллин Т., Гафиятуллина Н. Керсез йөрәк монологы / Т.Галиуллин., Н.Гафиятуллина //Җәлил М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 5-20.

3. Заһидуллина Д. М.Җәлил иҗатында мифологик образлар / Д.Заһидуллина // Муса Җәлил: иҗаты һәм батырлыгы. XXI гасырдан караш. – Казан, 2007. – 69-73 б.

4. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

5. Кашшаф Г. Муса Җәлил / Г.Кашшаф. – Казан: Таткнигоиздат, 1961. – 425 б.


## Лекция 3

**Аннотация.** Лекциядә М.Җәлилнең тоткынлык чоры иҗатына хас төп үзенчәлекләр билгеләнә, фәлсәфә үзгәреше ачыклана, чор әдәбиятына алып килгән яңалыклары, традицияләрне дәвам итүе тикшерелә, төп мифологик мотивлар аерып билгеләнә.

**Ачкыч сүзләр:**поэзия, реализм, романтизм, поэтик алымнар, мифологик мотив һәм образ, фәлсәфә.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. Муса Җәлилнең тоткынлык чоры иҗаты: төп тенденцияләре
2. Шигырьләрдә урын алган төп мотивлар, мифологик образ-детальләр, алар аша үткәрелгән фикер-фәлсәфә һ.б.

1942 ел, төгәлрәге, аяныч әсирлеккә төшү Муса Җәлил шигъриятенә яңа сыйфат үзгәрешләре алып килә. Шагыйрьнең тоткынлыктан кайткан шигырьләр җыентыгын шартлы рәвештә «Моабит дәфтәрләре» дип атыйлар. Беренче дәфтәр Франциядәге Ле–пюи лагерендагы татар әсирләре кулына эләгә, 1946 елны әсир Нигъмәт Терегулов алып кайта. Икенче дәфтәрне Бельгия әсире Андре Тиммерманс 1947 елны җибәрә. Ике дәфтәрдә Җәлилнең 94 шигыре теркәлгән.

Тоткынлыкта язылган шигырьләрендә яшәү һәм үлемгә мөнәсәбәт яссылыгыннан фәлсәфи ноктада автор бөтенләй башка югарылыкка күтәрелә, мифологик мотивларның да фәлсәфи эчтәлектә калыплашуы күзәтелә. Муса Җәлил поэзиясе бу елларда эчтәлек ягыннан гына түгел, форма җәһәтеннән дә яңа үрләр яулый:шигырьләрен төзүдә төп композицион алымнар булган кабатлаулар, көчәйтүләр хиснең дәрәҗәсен арттыруга хезмәт итә («Ышанма», 1943; «Җырларым», 1943 һ.б.), интонация үзгәреше (салмак интонация үлемгә тыныч мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлтелә: «Дуска» (1943)), сүз-сурәт тә фәлсәфи эчтәлекне яктырту максатында кулланыла («Җырларым», 1943; «Чәчәкләр», 1943), якты хыял, якты гомер, ал таң, акбүз ат, зәңгәр томан, ак дулкыннар кебек төсне белдерүче эпитетлар фәлсәфи мотивларны җиткерүдә, лирик герой

күңеленең матурлыгын, керсезлеген ачуда тераккә әйләнә.

Бу чорда иҗат ителгән шигырьләрдә төп мотивлар буларак илгә тугрылыкны раслау, җиңүгә ышаныч, батырлыкка дан җырлау, илне сагыну, тоткынлык мотивлары аерылып чыга. «*Мин чикмәдем, дускай, бер карыш та,/ Батырларча алга атладым./ Яулык шаһит: сине һәм илемне / Йөрәк каным белән сакладым*» кебек раслаулар («Яулык», 1942, «Кичер, илем», 1942, «Ирек», 1942 һ.б.) «Моабит дәфтәрләре»ндә кызыл җеп булып сузыла.

Туган илгә тугрылыкны раслау мотивы ант һәм ышаныч образлары, үлем-үлемсезлек төшенчәләре белән тыгыз бәйләнештә бирелә, алар шагыйрь шәхесе белән Туган ил арасындагы мөнәсәбәтне ачуда төп чарага әверелә. Моңакадәрге иҗат җимешләрендә шагыйрь үлемне үлемсезлеккә, мәңгелек яшәешкә юлның башлангыч ноктасы дип расласа, хәзер инде коллыктан котылу чарасы итеп карый башлый, шуңа мөнәсәбәттә ирек / коллык кебек оппозицион вариант пәйда була. Моннан тыш Җәлил шигырьләрендә идеология хакыйкатеннән аермалы шәхес хакыйкатенең аерып куела башлавы күзәиелә. «Әсир кеше – дошман» лозунгы хакимият хакыйкатен чагылдырса, Җәлил иҗаты үзенең, дусларының Ватанга бирелгәнлеген раслауга, «система фикерен» кире кагуга юнәлә, шәхес хакыйкатен «әсир кеше дошман түгел» гыйбарәсе белән бәйләп куя. Мәсәлән, шартлы укучы белән язучы сөйләшүенә корылган «Ышанма» (1943) шигыре «система» белән шәхес хакыйкатен аерып куя. «*Ул егылган арып*», «*Алмаштырган илен*», «*Муса инде үлгән*» гыйбарәләре үзе турында әйтелергә мөмкин булган (ул үз илен яхшы белә) карашларның чагылышы булса, шәхес үз хакыйкатен дөреслекне «син ышанма» кебек эндәш сүз белән белдерә, яла фикерләрнең хаксыз һәм ашыгыч булуын раслый. «Син ышанма» риторик эндәшен кабатлап, югары интонация аша үзенең тугрылыгын, намусының пакьлеген, керсезлеген исбатлый:

*Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,*
*“Алмаштырган илен”, - дисәләр,*
*Син ышанма, бәгърем!*
*Мондый сүне*

*Дуслар әйтмәс, мине сөйсәләр.*

Лирик герой үзенең Туган иленә, хатынына тугрылыгы, соңгы канынача көрәшәчәге, ягъни үз хакыйкате турында сөйли, үзенә ышанмаулары өчен борчыла, хаксызлыкны батырлык эшләве – бирешмәве белән җиңәргә омтыла, җиңеп үлгән үлем үлем түгел дип юана.

Яшәү-үлем оппозициясенә таянып язылган «Дуска» (1943) шигырендә батырларча үлү һәм хыянәтче булып үлү каршылыгы үлемне коллыктан котылу һәм Ватанына керсез мәхәббәтен дәлилләүче чара дәрәҗәсенә күтәрә:

*Юк, теләмим мин бу «исәнлекне»,*
*Йөрәк минем моңа үчекмәс.*
*Кешеме мин илем үги иткәч,*
*Җирдә миңа эчәр су беткәч?!*

Үлем темасына язылган шигырьдә, читкәрәк китеп, илнең уңышлары турында сөйләү дә аңа үз үлемен аклау, үлемнең бу очракта бердәнбер дөрес юл булуына инандыру өчен хезмәт итә.

«Моабит дәфтәрләре»нең дә, Җәлил иҗатының да программ әсәре дәрәҗәсенә күтәрелгән «Жырларым» (1943) шигырендә туган илгә тугрылыкны раслау мотивы жыр символик образы аша ачыла. Әлеге образ берничә мәгънә төсмере белән алына: бердән, шагыйрьнең әсәрләре билгесе булып килә *(«Жырларым, сез шытып йөрәгемдә, Ил кырында чәчәк атыгыз!»*). Икенче яктан, гомеренең керсез матурлыгын ачып бирергә сәләтле метафора *(«Гомерем минем моңлы бер жыр иде, Үлемем дә яңгырар жыр булып»*) лирик «мин»гә иленә тугрылыгын раслау, антның эчтәлеген ачу чарасы *(«Үлгәндә дә йөрәк туры калыр Шигъремдәге изге антына. Бар жырымны илгә багышладым, Гомеремне дә бирәм халкыма»*), батырлыкны раслау символы булып та яңгырый. Идея буларак, шигырьдә *яшәүнең, үлемнең, иҗатның ил өчен булырга тиешлеге* әйтелә, илгә багышланган жырлар, илне яклап үлү үлемсезлек китерә дигән фикер раслана.

Илне сагыну мотивлары белән сугарылган шигырьләрдә Туган ил  чит җиргәкаршы куела:

*Туган илем, үксез улың булып*

*Үләм инде читтә тилмереп.*

*Яшем барсын сиңа елга булып,*

*Каным шытсын кызыл гөл булып.*

*(«Соңгы үпкә», 1943).*

Мондый шигырьләрдә туган ил төрле әдәби сурәтләр аша гәүдәләнә. Мәсәлән, «Кошчык» (1942) шигырендә ул җыр һәм кошчык символик образлары ярдәмендә җиткерелә. Шигырь тукымасында ирекле кошчык белән куллары богауланган, әмма рухы сынмаган лирик герой образлары аша белдерелгән ирек һәм тоткынлык каршылыгы алга чыга. Тоткынлык газаплары ирекле кошны әсирләр белән очраштыру, риторик эндәш кебек поэтик алымнар аша җиткерелә:

*Син очарсың, бәлки, минем илгә,*
*Син ирекле, җитез канатлы.*
*Тик әйт, кошчык,*
*Синең минем янга*
*Бу килүең соңгы кабатмы?*

Тоткынлык мотивы «Бүреләр» (1943), «Таш капчык» (1943), «Алман илендә» (1944) кебек шигырьләрдә алга чыга, мондый әсәрләрдә фаҗигалелек көчле.

Бер төркем шигырьләрдә тоткынлыкта яшәп, палач балтасы астында газиз гомере өзеләчәген белгән, илендә әсирләр, ягъни дошманнар исемлегендә йөргән шагыйрь язмышы фаҗига буларак ачыла. Мәсәлән, «Соңгы үпкә» (1943) әсәрендә төп хиснең сәбәбен тоткын геройның әсирлектә үлемгә әзерләнүе, үлемнең аны яшәеш матурлыгыннан аерачагын уйлап газаплануы тәшкил итә. Чит җирдәге үлем фаҗигагә тиңләштерелә, хис-кичереш эчтәлеген яхшылыкка яманлык булып кайткан җаваптан туган хаксызлык, язмышка үпкә тәшкил итә. Шигырь тукымасында үлем һәм хыянәт тулы дөньяда яшәү үлем белән бер, ә

инде халык күңелендә калу иң олы җиңү ул дигән идея уздырыла, лирик герой ирек, әнкәң янында, сөйгәнең белән бергә булу – бәхет, ә илеңә тугрылыклы калып үлүнең яшәүне раслаучы дәлил икәнлеген ассызыклый. Шагыйрь тәне үлгәннән соң да үзенең рухи җимешләрендә яшәячәген, «кызыл гөл, елга» булып калкачагын уйлап, юаныч, фаҗигале язмышына таяныч таба.

Аерым шигырьләрдә дошман образы фашист кебек төгәлләшеп, югары мәдәниятле, акыллы немец халкының фашизм колына әверелүе фаҗига буларак кабул ителә. «Алман илендә» (1944), «Катыйльгә» (1943), «Вәхшәт» (1943), «Бүреләр» (1943), «Кол» (1943), «Хөкем алдыннан» (1943), «Таш капчык» (1943) кебек фашизмга бәя булып яңгыраган шигырьләр нәкъ менә шундый фикер белән сугарыла. Мәсәлән, «Бүреләр» (1943) шигырендә үз-үзе белән каршылыкка кертелгән бүре метафорасы дошманны бәяләүгә юнәлтелә. Боҗралы композиция ярдәмендә бүреләрнең кешеләрдән ерткычрак булуы турындагы беренче строфадагы фикер соңгы строфада кешенең аңардан да явызрак булу мөмкинлеген күрсәтә:

*Кешеләр сугыша, кан коя,*
*Киселә меңнәрчә гомерләр.*
*Төн буе улашып якында*
*Иснәнеп йөриләр бүреләр.*
*Бүреләр,*
*Аh, ләкин бүреләр*
*Бу кадәр үк ерткыч түгелләр.*

«Вәхшәт» (1943) шигыре дә шундый ук эчтәлек белән сугарылган: фашистларның, аналарны, балаларны кырга куып, атып үтерүләре кичереш үсешенең сәбәбе булып тора:

*Ул сарыла шашкан анасына,*

*Нәни күңеле сизә, күрәсең!*

*– Аталар бит, әнием, яшер мине,*

*Әнием, бәгърем, килми үләсем!..*

Көннең яңгырлы булуы, болытларның җиргә иелүе, елгаларның үкереп агуы, бу вәхшәткә *«түзә алмаган җир-ананың, тешләрен кысып, үксеп җылавы, көзге урманның шашып шаулавы, җил сызгыруы»* кебек әдәби детальләр хисне көчәйтүгә юнәлдерелә.«Үзем күрдем» гыйбарәсен кабатлау вәхшилекнең көчен арттыруга, эмоциональ тәэсирлелекне көчәйтүгә хезмәт итә. Якты, тугрылыклы үлем шушы вәхшилекне җиңә алырдай көч югарылыгына күтәрелә. Дошманга нәфрәт белән сугарылган мондый әсәрләрдә фашизмга бәя бирү һәм лирик геройга үз кичерешләрен тирәнрәк ачу максатыннан катыйль («Катыйльгә»), шакшы куллар, канга туймас Гитлер, фашист этләре («Дошманга каршы»), кызыл күзле, юеш танаулы җәллад («Хөкем алдыннан»), зур борынлы, ямьсез бакыр күзле («Вәхшәт») кебек натуралистик образлар, сүз-сурәт, эпитетлар өстенлек ала, «Моабит дәфтәрләре»нең үзенчәлекле лексик катламын тәшкил итә.

Батырлык мотивы шигырьләрдә еш кына мифологик мотивлар, образлылык ярдәмендә белдерелә. Мәсәлән, «Ана бәйрәме» (1943) балладасында әкияттәгечә өч ул, аларның икесе яуда башын салу, «алмаз кылычлы» өченче улның җиңеп кайтуы, хәбәр китерүче җил һәм күгәрчен, кайгыдан сукырайган ананың күзләре ачылу кебек мотивлар ил өчен көрәшне данлауга хезмәт итә. «Сандугач һәм чишмә» (1942) балладасында аллегорик образлылык шулай ук ил өчен үлү фикерен калкыта. «Кызыл ромашка» (1942) балладасында батырлык иң югары кыйммәт дәрәҗәсенә куела. Халык мифологиясеннән килүче образларны ил белән бәйле уйнату тагын да көчәя. Күп кенә шигырьләрдә «ил» төшенчәсенең милли эчтәлеге калкытыла. «*Туган илем, якты өем*» дип белдерүче лирик геройның аны сагынуы, ашкыну–омтылышы карлыгач, алтын балык, көмеш яллы җитез аргамак кебек милли–мифологик образлар белән янәшәлектә китерелә. Сандугач һәм чишмә, ромашкалар, күгәрчен, җил, кош, гөл кебек образлар, Көрәшче–егет образын тудыручы детальләр төсендә акбүз ат, алмаз кылыч, тояк тавышы, көмеш саплы кылыч кебек таныла торган берәмлекләр ил образының милли аңланылышына китерә. Шуның белән янәшәдә шагыйрьнең «Моабит дәфтәрләре» циклында

Ана башлангычын мифлаштыру күренеше, туган ил – табигать – туган җир – ана чылбыры пәйда була.  «Шагыйрь» (1942), «Юллар» (1943), «Яшь ана» (1943) кебек шигырьләрдә Ана образы туган ил, кешелек башлангычы белән тәңгәлләштереп сурәтләнә.

Моңа кадәр Җәлил әсәрләренең үзәгендә торган архетипик герой–көрәшче образы да өр–яңа статуста күренә: илне яклап көрәшкән батыр, тугры сугышчы; шагыйрь–герой. Мәсәлән, «Шагыйрь» (1942) шигырендә ул язганнары белән давылны җиңүгә өлеш керткән гадәттән тыш кеше кебек тәкъдим ителә. Ә инде «Була кайчак» (1943), «Җырларым» (1943) кебек шигырьләрдә ил өчен корал тотып көрәшкән, җырлары белән меңнәрне көрәшкә күтәргән каһарман, гомерен, иҗатын, үлемен ил азатлыгы өчен дип белдергән юлбашчы төсендә пәйда була.

Әнә шулай М.Җәлил иҗатын мотивлар төрлелеге ноктасыннан күзәтеп-бәяләп чыгу аның лирикасының үсеш юлында берничә этапны үтүен ачыклый, үсеш процессындагы күчеш-тирбәлешләрне дәлилли. Ул әдәбиятка яңа тормыш төзү хакындагы олы бер миф тудырылу вакытында килә һәм ил, көрәшче һәм байрак мифологик образлары М.Җәлил шигъриятендә шушы мифның аерылгысыз өлешләре кебек урынлаша. Ләкин шагыйрьнең халык авыз иҗатына  мөрәҗәгате, татар әдәбияты өчен традицион образларны идеологик–мифологик образларның детальләре төсендә куллануы сәяси схематизмны атлап чыгарга ярдәм итә. Әлеге үзенчәлекләр барысы да М.Җәлил иҗатының идеологик эчтәлеккә генә сыешмавы, тар кысаларда калмавы хакында хәбәр итә. Нәтиҗәдә Җәлил шигърияте милли–шәхси эмоциональлек белән өретелә, аның тәэсир көче чиктән тыш арта. Шундый ук күренеш лиро–эпик әсәрләр материалында да аермачык. «Моабит дәфтәрләре»ндә шагыйрь, идеологик чикләрдән узып, гомумкешелек кыйммәтләре хакында җырлаучыга әверелә. Муса Җәлилнең иҗатчы буларак бөеклеге дә шунда.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Шагыйрьнең тоткынлык чоры иҗатында нинди мотивлар урын ала?

2. Муса Җәлилнең тоткынлык чоры иҗатында фәлсәфә үзгәрешен аңлатыгыз.

3. Муса Җәлилнең тоткынлык чоры иҗатында милли нигезләргә борылыш нинди үзенчәлекләр аша чагылыш таба?

**Әдәбият исемлеге.**


1. Галиуллин Т., Гафиятуллина Н. Керсез йөрәк монологы / Т.Галиуллин., Н.Гафиятуллина //Җәлил М. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 5-20.

2. Заһидуллина Д. М.Җәлил иҗатында мифологик образлар / Д.Заһидуллина // Муса Җәлил: иҗаты һәм батырлыгы. XXI гасырдан караш. – Казан, 2007. – 69-73 б.

3. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

4. Кашшаф Г. Муса Җәлил / Г.Кашшаф. – Казан: Таткнигоиздат, 1961. – 425 б.

5. Мостафин Р. Өзелгән җыр эзеннән / Р.Мостафин. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1982. – 464 б.


## Тема 3. XX гасырның икенче яртысы татар поэзиясе контекстында Хәсән Туфан иҗаты (1900 – 1981).

**Лекция 1**

**Аннотация.**Лекциядә Х.Туфанның тормыш юлы турында мәгълүмат бирелә, тоткынлык чоры иҗатының төп үсештенденцияләре ачыклана. Тоткынлык елларында язылган шигырьләрендә мотивлар үзгәреше, лирик герой бирелеше, образ-детальләр, аларга салынган мәгънәләр тикшерелә, шигырь төзелешенә алып килгән яңалыгы билгеләнә.

**Ачкыч сүзләр:**лирика, мотив, лирик герой, строфа, образ, деталь.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак

бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. Хәсән Туфанның тормыш һәм иҗат биографиясе.
2. Шагыйрьнең тоткынлык чоры иҗатында мотивлар төрлелеге , шигырь техникасына керткән яңалыгы.
3. Мотивлар төрлелеге, образ-детальләр, аларга салынган мәгънә бөтенлеге һ.б.

Татар поэзиясенең классик шагыйре Х.Туфан – XX йөз әдәбият мәйданында үз мәктәбен булдырган, классик иҗаты белән узган гасыр шигъриятендә тирән эз калдырган, милли сүз сәнгатен сүз-сурәт һәм фикер, сәнгатьчәлек ягыннан баеткан сүз осталарының берсе. Хәсән Фәхри улы Туфан 1900 елның 27 ноябрендә (яңа стиль белән — 9 декабрьдә) элекке Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волосте (хәзерге Татарстанның Аксубай районы) Иске Кармәт авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә. Булачак шагыйрьнең әтисе Фәхри абзый, иген игүдән тыш, сәгать төзәтү, пыяла кую, тимерчелек кебек эшләр белән шөгыльләнә һәм бу һөнәрләргә балаларын да өйрәтә. Моның өстенә, аның өлкән уллары, һәр елны Себер һәм Урал якларына китеп, шахтада да эшләп кайта.

Хәсән укырга-язарга әтисеннән һәм үзлегеннән өйрәнә, ә 1905 елгы революциядән соң Кармәттә мәктәп ачылгач, шунда йөреп укый башлый. 1914 елның язында ул Тобол губернасының Ахман авылында җир алып урнашкан абыйлары янына китә һәм җәен алар белән бергә бакыр колчеданы руднигында эшли. Шул елның көзендә абыйлары аны Уфага «Галия» мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр. Үз чорының алдынгы уку йортларыннан саналган бу мәдрәсә Х. Туфанның белем даирәсен киңәйтүгә һәм әдәби иҗат эшенә тартылуына уңай йогынты ясый. Шунда ул Г. Ибраһимовтан әдәбият дәресләре тыңлый, шул ук мәдрәсәнең шәкерте Ш. Бабич оештырган түгәрәккә йөреп, шигырь серләренә

өйрәнә, әдәби кичәләрдә С. Рәмиев, М. Гафури, С.Сүнчәләй кебек шагыйрьләрнең чыгышларын ишетә.
Җәйге каникул вакытларында яшүсмер егет, укуын дәвам итәргә акча юнәтү өчен, Урал рудникларында шахтер, сәгать төзәтүче, Лысьва металлургия заводында токарь булып эшли. 1917 елның Февраль көннәрен, аннары Октябрь революциясен ул шунда, Лысьва заводында, каршылый. 1918—1924 елларда Х. Туфан Урал һәм Себер мәктәпләрендә балалар укыта. 1924 елның җәендә Казанга килә һәм 1928 елга кадәр Н. Нариманов исемендәге 17 нче номерлы Бишбалта мәктәбендә укытучылык хезмәтен дәвам иттерә. 1928 елның язында Х. Туфан Кавказ һәм Урта Азия якларына җәяүле сәяхәткә чыгып китә. Бу ике елга сузылган сәяхәте вакытында ул төрле халыкларның тормышлары белән якыннан таныша, халык иҗаты әсәрләрен өйрәнә, ашуглар, акыннар белән очрашып сөйләшә. Болар һәммәсе шагыйрь иҗатын яңа темалар, яңа хисләр белән баета.

Сәяхәттән кайткач, Х. Туфан 1930 — 1934 елларда Татарстан радиокомитетында әдәби һәм музыкаль тапшырулар редакторы, аннары 1937 елга кадәр «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының җаваплы секретаре булып эшли.

1940 елның 18 ноябрендә Туфан кулга алына һәм  ел ярым Черек күл төрмәсенең ялгыз камерасында утыра. 1942 елның 7 мартында үлемгә хөкем ителә, ике айдан соң үлем карары 10 ел каты режимлы колониядә утыру белән алмаштырыла. Шагыйрь төрле лагерьларда иң авыр эшләрдә эшли, 10 елын тутырганнан соң, Себергә гомерлеккә сөргенгә җибәрелә.Җепшеклек алып килгән үзгәрешләр тәэсирендә, 1956 елның җәендә Х.Туфан азат ителеп, Казанга кайта һәм гомеренең соңгы көннәренәчә шунда яши.

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен Хәсән Туфан ике тапкыр (1970, 1980) Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә, ә «Сайланма әсәрләр» (Казан, 1964) китабы өчен аңа 1966 елда Татарстан АССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.Хәсән Туфан 1981 елның 10 июнендә Казанда вафат була.

Х.Туфан әдәби мәйданга сүз сәнгатенең яңа үсеш юлларын эзләп, шартлы алым-сурәтләргә урын биргән, имажинизм, футуризм кебек модернистик агымнар, алымнар белән мавыккан, һәр яктан яңалыкка омтылган 20 нче елларында аяк баса һәм үзенең иҗат юлында берничә баскыч, этапны үтә.

Туфанның тоткынлык чоры иҗаты поэтик яктан камилләшә, фәлсәфә һәм сурәтлелек җәһәтеннән яңа югарылыкка күтәрелә. Әгәр утызынчы еллар эпостан лирикага күчү белән характерланса, 40-50 нче еллар лирикасы, лирик табигатен һәм төп үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, фәлсәфи яктан тирәнәю, мотивларның үзгәрүе белән билгеләнә. Үз фикерен укучыга җиткерү максатыннан Туфан тирән эчтәлекле, күпмәгънәле метафора, символлардан файдалана яки үз тормышына, язмышына кинаяле бәя бирә; чор кешесенең яшәешен аерым бер шәхес, нигездә, лирик герой язмышы, аның хәсрәте, рухи кичерешләре аша җиткерә һәм татар поэзиясен чын мәгънәсендә камил, тирән эчтәлекле лирик үрнәкләр белән баета.

Шушы еллар аралыгында шагыйрь иҗатындагы форма эзләнүләре бишъюллыкта беренче һәм бишенче юлларның кабатлануына корылган яңа тип строфага мөрәҗәгать итүдә чагыла. «Гөлләр инде яфрак яралар» (1945),«Иртәләр җитте исә» (1944), «Халыклар капкасы янында» (1947), «Кая шулай ашыгасың, йөрәк?» (1953) кебек шигырьләре шул калыпка салып иҗат ителә, беренче һәм соңгы юлларның кабатлануы лирик герой кичерешен, автор фикерен көчәйтүгә хезмәт итә.  Эчтәлек яңарышы исә фәлсәфи рухның көчәюенә тоташа.

Туфанның бу чор иҗатында төп темалар буларак  заман фаҗигасе, халык язмышы, мәхәббәт темалары урын ала; өч төп мотив – *фаҗига һәм шул фаҗига тудырган хәсрәт, үкенеч һәм шуңа бәйле тугансагыш* мотивлары – әсәрләренең үзәген тәшкил итә, нигездә, алар туган як / чит җир, ирек / ирексезлек (тоткынлык) оппозицияләре аша тәгәлләшә.

Туфанның бу чор иҗатын *хәсрәт мотивы* кисеп үтә, лейтмотивка әверелә. Мәсәлән, «Агыла да болыт агыла» (1951) шигырендә хәсрәт мотивы алга чыга. Туган җиреннән аерылырга мәҗбүр ителгән лирик герой һәм

тирәлекне гәүдәләндерүче битараф болыт мөнәсәбәтләре аша җәмгыятьнең, тирә–юньдәгеләрнең шәхес культы алып килгән үзгәрешләрне күрмәмешкә салышуына хәсрәтләнү сиземләнә. Хәсрәт мотивының үзәген тәшкил иткән лирик герой белән гомернең узуын, язмышны гәүдәләндерүче болыт образлары ирек белән ирексезлекнең билгеләренә әверелә. «Нәрсә әйтер туганнарыма?» риторик соравының, «агыла да болыт агыла» тезмәсенең кабатлануы композицион яктан шигырьне туплап торучы принцип һәм фокус хезмәтен үтәсә, икенче яктан хәсрәтнең дәрәҗәсе көчәюне тәэмин итә, хәтта интонация үзгәреше, гомер юлына ironияле бәя дә шул максатка юнәлтелә:

*Роман кебек күңелле син, юл!*
*Азмы синдә гомер уздырдым,*
*Ничә кием чабата синдә,*
*Ничә кием итек туздырдым!*
*Роман кебек күңелле син, юл!*

*Ә син, яңгыр, искә төшермә*
*Итегемнең ничек икәнен....*
*Яланаяк килдем дөньяга,*
*Шулай гына, бәлки, китәрмен,*
*Ә син, яңгыр, искә төшермә!*

Шушы чорда иҗат ителгән «Илдәниләр бар икән?» (1944) шигыре дә якыннарыннан аерылган, изоляциядәге кешенең үзен каһәрләгән ил язмышын кайгыртып хәсрәтләнүенассызыклый, хәсрәт мотивын үзәккә ала. Хәсрәт мотивы, лирик геройның сагыш белән өретелгән әрнү хисе үзгәрешсез сакланса да, сәбәпләрнең төрлеләнүе күзгә ташлана, бу исә Туфанның күңел фаҗигасен бербөтен күзалларга ярдәм итә. Лирик геройның билгесезлектә яшәве, ялгызлыгы, өметләренең акланмаячагын белү үзе дә илнең фаҗигасе дәрәҗәсенә кадәр үстерелә:

*Илдә ниләр бар икән:*
*Юллар зәңгәр кар микән?*

*Һавадагы алсу шәүлә*
*Пожар микән, таң микән?*
*Илдәниләр бар микән?*

Шигырьнең беренче строфасында ук кулланылган зәңгәр кар, пожар, таң образлары, кабатланып, символ дәрәҗәсенә җиткерелә: *зәңгәр кар һәм таң* лирик геройның якты киләчәккә өметләрен, *пожар* илдә барган канлы вакыйгаларны символлаштыра. Шагыйрьнең «Авырган минутларда» (1942), «Хәят» (1942) һ.б. шигырьләрендә дә җәмгыятьнең кешелексезлеген, иҗтимагый-сәяси вазгыятьне «эзоп» теле аша тасвирлау урын ала.

«Гөлләр инде яфрак яралар» (1945), «Каеннар сары иде» (1942), «Чәчәк сибелә җилдә» (1947), «Тынма, давыл» (1951), «Моабитны күрдем төшемдә» (1947), «Сугыш» (1947) кебек шигырьләрне *фаҗига мотивы* берләштерә, боларда үзәк мотив сугыш образы ярдәмендә ачыла һәм Туфанның үз язмышын чагылдыру яки ярдәмче мотив буларак урын алган идеологиягә бәя бирү чарасына әверелә. Мәсәлән, «Чәчәк сибелә җилдә» (1947) шигырендә ике кулын артка куеп, кешене атарга алып бару сурәте аша шәхес культының фаҗигасе, яңа каберлекләр күренеше күз алдына бастырыла. Кешене табигатьнең бер кисәге итеп карап, Туфан бу фаҗигагә киләчәк гасырлар күзлегеннән, гуманизм ноктасыннан бәя бирә.

Бәхет / хәсрәт каршылыгына корылган «Каеннар сары иде» шигыре дә кеше һәм табигать образларын янәшә куя, төп мотив каеннар, гөлләр, астралар кебек аллегорик образлар аша җиткерелә, сары – кайгы янәшәлеге автор фикерен көчәйтүгә юнәлтелә. Шагыйрь тормышның кайгылы чагын сурәтләү объекты ясый: табигатьтәге көз, салкынлык, күңелсезлек кеше тормышына янәшә бирелә, әсәрнең үзәгендәге эти, сабый кебек үк, аллегория ярдәмендә аңлатылган кешеләр дә кайгыда. Шул аллегорик, символик сурәтлелек аша җиткерелгән фәлсәфи идея болай формалаша: ил кайгылы вакытта хәтта сабый балалар да бәхетсез.

Шагыйрьнең «Сиңа» (1953), «Тамчылар ни диләр?» (1957), «Бәхет» (1956), «Кайсыгызның кулы җылы?» (1956) һ.б. күңел лирикасына мөнәсәбәтле

шигырьләрендә *фаҗига мотивы* сөйгәнен югалтуга бәйле формалаша. Мәсәлән, «Кайсыгызның кулы җылы?» (1956) шигырендә хатынының үлеме төрмә газапларыннан җаны өшегән, хәсрәт эчендә яшәгән лирик геройның халәтен тирәнәйтә.«Вулканнарга керер идем, шундадыр ул... дисәләр» тезмәсе хәсрәтнең дәрәҗәсен чагылдырып, аның түзеп булмастай икәнлеге хакында сөйли. «Сиңа» (1953) шигырендә сөйгәнен югалткан лирик геройның сагыш хисен көчәйтү өчен шагыйрь чагыштыру куллана: лирик герой язның чәчәкләр калдырып китүеннән дә сагышлана, инде сөйгәне өчен сагышлану икеләтә тирән. Чагыштыру бу өлештә катлаулы сурәт төсен ала: моның өчен автор «яз»ны җанландыра, «сиңа» карата да, «яз»га карата да «китте» фигылен файдалана-кабатлый, «дә» кисәкчәсе шулай ук «син» һәм «яз»ны янәшә куя, «ядкарь» һәм «истәлек» синонимнары, «чәчәкләр» һәм «төсең» сүзләренең контекстуаль синоним булып килүе дә шушы максатка хезмәт итә. Гипербола (ничә тапкыр үттем җир шарының орбитасын), һәм соңгы юлдагы кабатлау (табалмадым, табылмадың) сагыш хисен иң югары ноктага – гаҗизлеккә җиткерә. Лирик герой, сөйгән кешесе саубуллашып киткән булса дип, сагышыннан юану эзли. «Тамчылар ни диләр» (1957) шигырендә лирик герой үткән тормышын күздән кичерә, хатынының эштән куылып та, газиз кешесеннән баш тартмавын, донор булып – кан биреп, вафат булуын сөйли. Лирик геройның фаҗигасе, шуның тәэсирендә туган сагышы, үкенеч хисләре тамчы-тамчы эзләр кебек өзек-өзек детальләр, символлар, кинаяләп сөйләү, шигъри сурәтләр күплеге аша тирәнәйтелә.

Илленче елларның икенче яртысында татар шигъриятен иҗтимагый–фәлсәфи шигырьләргә баеткан «Киек казлар» (1956), «Битараф ай» (1956), «Эстафета» (1956), «Сөйли торган материя» (1953), «Сүз кушасы килә талларга» (1956), «Кая шулай ашыгасың, йөрәк?» (1953) кебек фәлсәфи лирика үрнәкләрен *үкенеч һәм шуңа бәйле туган сагыш мотивы* берләштерә. Аккош («кырда ике ак канат ята»), гүзәл миләүшә («Сөйли торган материя»), таллар («Сүз кушасы килә талларга») образлары аша кеше гомеренең кыйммәте, яшәү мәгънәсе, тарихи вакыйгаларның кеше язмышына тәэсире хакындагы

уйланулар җиткерелә, үкенеч, шуңа бәйле туган сагыш мотивы алга чыга. Бу шигырьләр тормышның таҗы — кешенең газаплар, фаҗигаләр аша кешелекле булып калырга омтылуы хакында сөйли. Әйтик, Х.Туфанның «Киек казлар» (1953) шигырендә автор шәхес культы, сугыш газапларын кичкән буынны (без) һәм киек казларны янәшә куя. Казлар китү тудырган әрнү хисе тулы бер буынның кичергән газаплары тудырган кайгы хисенә кадәр үсә. Шигырь илдәге кешеләрне мәҗбүри туган җирдән аеру вакытын искә ала, ул заманнар үтте дип ышану — якты моң (хис) үзәккә куела.

«Сөйли торган материя» (1953) шигыре «гүзәл миләүшә» күреп туктап калган юлчының чәчәккә мөрәҗәгате, риторик эндәше белән башлана. Шагыйрь миләүшәне кешегә хас сыйфатлар белән бизи, җанландыра, кеше дә, гөл дә - матдә:

*Ничә миллион гасыр үтте инде*
*Безнең шушы җиргә килгәнгә...*
*Син бер гөлгә инде әверелгәнсең,*
*Ә мин менә кеше дигәнгә, - дип яза.*

Шигырьнең икенче өлешендә лирик герой үз мәхәббәте хакында сөйли башлый, беренче өлештәге соклану хисе сагыну, сагыш белән алмашына.Ләкин бу ике өлеш сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә: чәчәк мәхәббәте турында сөйләгән лирик герой, үз мәхәббәтен искә төшереп, табигать белән кешене тагын бер кат тигезләп куя. Табигать тә, кеше дә - матдә, ярата белә, матур... Ләкин соңгы юллар аерманы да күрсәтә һәм фәлсәфи мәгънә ала: без бертуган, ләкин кеше сөйли, сагына, җырлый белә, ди шагыйрь. Шул рәвешле, шагыйрьнең 40-50 нче еллар лирикасы фәлсәфә, тирән лиризм, тоткынлык газабын кичерүче лирик геройның хис-кичереше аша яктыртылган елъязманы хәтерләтә.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Хәсән Туфанның тоткынлык чоры иҗатына нинди үзенчәлекләр хас?
2. Шагыйрьнең тоткынлык чоры иҗатында нинди мотивлар урын ала?

3. Шагыйрьнең тоткынлыкчоры иҗатында шигырь калыбына керткән яңалыгын аңлатыгыз.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Галиуллин Т.Акыл һәм җан берлеге // Шәхесне гасырлар тудыра: Әдәби тәнкыйть, хикәяләр. — Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. —192б.

2. Гафиятуллина Н. Ак чәчәк аткан иҗат... / Н.Гафиятуллина // Мәйдан. – 2006. - № 2. – Б.87-92

3. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

4. Сабиров Р. Шигырьләрдә — минем йөрәгем…. / Р.Сабиров. – Казан: Школа, 2006. – 186 б.

## Лекция 2

**Аннотация.**Лекциядә Х.Туфанның тоткынлыктан соңгы чор иҗатының төп үсештенденцияләре ачыклана. 1960-80 нче елларда язылган шигырьләрендә мотивлар үзгәреше, лирик герой бирелешетикшерелә, образ-детальләр, аларга салынган мәгънәләр ачыклана.

**Ачкыч сүзләр:**лирика, мотив, лирик герой, образ, деталь.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә эзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. Хәсән Туфанның тоткынлыктан соңгы еллар иҗаты: мотивлар төрлелеге, үсеш-үзгәреш тенденцияләре.

2. Шагыйрьнең бу чор шигъриятендә иҗат мотивының бирелеше, Тукай турындагы шигърияткә керткән яңалыгы һ.б.

Билгеле булганча, алтмышынчы еллар татар поэзиясенең бер тармагын салмак лирика тәшкил итә, аның үсеш-үзгәрешендә дә Х.Туфан иҗаты әһәмиятле урын тота. «Салмак лириклар» иҗатына эчке уйлану, лиризм, гади һәм традицион шигъри сөйләмгә өстенлек бирү хас; аларны сүз сәнгатенең үткән, бигрәк тә халык җыры, Тукай традицияләренә таяну, әхлакый яңаруга омтылыш якынлаштыра. Бу юнәлештә үткән традицияләрне саклап, буыннарга җиткерү теләге көчәя, еш кына традицион әхлаклы авыл яшәеше шәһәр тормышыннан өстенрәк куела. Әлеге билгеләр үзләре үк Х.Туфанның алтмышынчы-сиксәненче иҗатын характерлый. «Гомер эзләрең буйлап» (1969), «Кармәт истәлекләре» (1970), «Еракларга алып киттеләр» (1967) кебек шигырьләрендә үзенең яшьлек елларын сагынучы, үткәннәргә бәя бирергә тырышучы, «Талантлы син, кеше туганым» (1959), «Һиндстанны эзлим» (1956), «Тугызынчы дулкын» (1962), «Якыная бара» (1961) кебек әсәрләрендә кешенең табигать белән бәйләнешенә мөнәсәбәттә гомумән кешелек яшәешенең төп фәлсәфи кануннарын аерып алырга омтылучы лирик герой алгы планга чыга, *үткәннесагыну мотивы* үзәккә куела. Бу елларда иҗат ителгән мәхәббәт лирикасында да шушы мотив көчле бирелә.

Х.Туфанның алтмышынчы еллар иҗатында бер тармакны милләт тарихында тирән эз калдырган шәхесләр образларын яктырткан әсәрләре били, шагыйрь аеруча Тукай образына еш мөрәҗәгать итә. «Һаман шулай», «Халык төсе», «Без һаман бергә», «Язгы авазлар», «Чәчәкләр китерегез Тукайга» (1966), «Кулын канга батырса да» (1968) кебек әсәрләре Х.Туфан иҗатында яңа мотив – *иҗат мотивы* пәйда булуын хәбәр итә. Шагыйрь каләм, сүз көчен югары күтәрә, Тукайны иҗат югарылыгы символы итеп куя, Тукай образын бизәүдә сакральләштерү, изгеләштерү тенденциясе тоемлана. Әлеге мотивка мөнәсәбәтле шигырьләрендә үзенчәлекле күренеш: социологик юнәлешне тулаем кире кагып, иҗтимагый-әдәби эчтәлекне берләштерү күзәтелә. Каләм иясе һәм сәясәтчеләрне янәшә куеп, шагыйрь халыкның төп әйдаманнары – шагыйрьләр дигән нәтиҗәгә килә, шагыйрь образына бәйле рәвештә,

сәнгатьнең изге вазифа-бурычлары турында фикер әйтелә. Х.Туфан шулай әдәбиятның тормыш-яшәештәге урынын хәтта хакимият баскычыннан югары күтәрергә тели. Шул юлда әдәби мираска мөнәсәбәт хакында уйлануларның матур үрнәге буларак «Чәчәкләр китерегез Тукайга» (1966) шигыре мәйданга килә. Шатлык - рәнҗү - өмет рәвешендә кискен өч өлешкә аерылып торган шигырьне бербөтенгә чәчкә символы җыя, туплый. Символның бер мәгънәсе чәчкәне халыкның сөйгән улына сәламе, тирән ихтирам һәм чиксез хөрмәт, игътибар билгесенә әйләндерә. Шуның белән янәшәдә чәчәкләр - Тукайның мәңгелеге символы да, ә ул буынара бәйләнешне тәэмин итүчеләр - яшьләр. Шуңа аларның шагыйрьгә игътибары бер үк вакытта матурлык та булып кабул ителә.

Туфанның А. С. Пушкинга атап язылган «Кулын канга батырса да... » шигырендә дә иҗат мотивы тотрыклы. Шигырь тукымасында милли азатлык идеяләре Пушкин, Тукай иҗатлары белән бәйләп куела. Әдәби катлам әдәбиятның иҗтимагый дәрәҗәсен күтәрергә омтыла, моның өчен шагыйрьләр һәм хакимнәр – дәүләт эшлеклеләрен янәшә куеп чагыштыра, беренчеләренең өстен булуын раслап, халыкның төп әйдаманнары – шагыйрьләр дигән нәтиҗәгә килә. Социологик кыйммәтләрне кире кагучы катлам моны һич тә аксиология ноктасыннан гына эшләми, бәлки, милли-иҗтимагый аспектны үзәккә куя. Әсәрдә, бердән, ике шагыйрьнең дә милли азатлык яулап алуда терәк булулары күрсәтелсә, икенче яктан, сәнгать иреге хакында сөйләнелә. Әнә шулай иҗат, сәнгатьнең изге вазифа-бурычлары турында фикер калка.

Аерым әсәрләрендә сәяси, иҗтимагый характерлы тәнкыйть көчле чагылыш таба, бу төркем әсәрләрдә шагыйрь иҗатының утызынчы елларында пәйда булган *сәяси барышка бәя мотивы* кабат яңара. Мәсәлән, Х.Туфанның «Сез кая барасыз, йолдызлар?» (1953-67) шигырендә метафора-символлар, эзоп теле аша җәмгыятькә, сәяси системага бәя урын ала, кешенең үз-үзен танып-белү мәсьәләсе төп проблема буларак күтәрелә, әсәрләр үзәгенә «без нигә мондый?» кебек сораулар куелып, тормыш гаделсезлеге тудырган борчылу, үкенү хисе эчтәлеккә үтеп керә. Х.Туфан битараф йолдыз, җил, кибән, итек

символларына күпмәгънәлелек биреп, сәясәт, илдәге тоталитар система образын тудыра:

*...Эзне кая, итекне дә хәтта*
*Күреп булмый... Шундый караңгы.*
*Күктәгеләр күрми минем хәлне,*
*Ә мин күрәм, күрәм аларны...*

*Җемелдәмә, искә төшермә лә!*
*Ансыз да бит*
*Хәтердә минем:*
*Без Казанга:* «*Сау бул*» *– дигән төндә*
*Син болытлар артында идең,*
*Болытлар артында...*

Шигырьдә лирик геройның әрнү хисенә илдәге сәяси вәзгыять, утызынчы еллардан үзгәрешсез диярлек калган тәртипләр сәбәп булып килә, болыт образы нәкъ менә шул эчтәлектә әсәр тукымасында урын ала. Юану өлешенең булмавы, сызлануның даими дәвамлылыгы шагыйрьнең киләчәк өчен борчылуын, өметсезлеген искәртә.

Һәр строфасы диярлек аерым тезмәләр кабатлануына корылган «Ни булды сиңа?» (1956) шигыре сәяси барышка бәя мотивын Идел образына мөнәсәбәтле җиткерә. «*Син нигә уйчан бүген - Син, никтер, уйчан бүген*» дип Иделгә — илгә эндәшүче лирик герой мондагы тәртипләрне борчылу сәбәбе итеп саный. «*Ни булды, Идел, сиңа?*» юлының кабатлануы әлеге борчылу хисен тагын да көчәйтә, әйтерсең лә, Идел уйчанлыгының сәбәбен белмәү лирик геройны тынгысызлый. «Яраса, сөйлә миңа» тезмәсен аерып, әлеге сәбәпне әйтергә ярамаска да мөмкинлегенә игътибар юнәлтелә.

Шул рәвешле, Х.Туфан иҗатында якты киләчәккә ышаныч, шул юлда көрәш, аерылу, сәяси брышка бәя, хәсрәт, фаҗига һәм үкенеч, иҗат, үткәнне сагыну мотивлары иңләп ала. Шагыйрь поэзиясенең үзәгендә үз кичерешләре аша халык язмышын җиткерүче, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылучы,

кешелекнең яшәеш кануннары хакында уйланучы, эзләнүче, иҗатның төрле этапларын, үсеш-үзгәреш баскычларын бер ноктага туплаучы лирик герой тора. Әлеге сыйфат-үзенчәлекләр үзләре үк Х.Туфан иҗатының байлыгы, күпкырлылыгы хакында сөйли, XX гасыр татар поэзиясен баета.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Хәсән Туфанның 1950 нче елларда иҗат ителгән шигырьләрендә фәлсәфә бирелешен аңлатыгыз.

2. Шагыйрьнең тоткынлыктан соңгы чор иҗатында нинди мотивлар урын ала?

3. Хәсән Туфанның тоткынлык чоры иҗатында милли нигезләргә борылыш нинди үзенчәлекләр аша чагылыш таба?

**Әдәбият исемлеге.**


2. Галиуллин Т.Акыл һәм җан берлеге // Шәхесне гасырлар тудыра: Әдәби тәнкыйть, хикәяләр. — Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. —192б.

1. Гафиятуллина Н. Ак чәчәк аткан иҗат... / Н.Гафиятуллина // Мәйдан. – 2006. - № 2. – Б.87-92

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

3. Сабиров Р. Шигырьләрдә — минем йөрәгем…. / Р.Сабиров. – Казан: Школа, 2006. – 186 б.


## Тема 4. Бөек Ватан сугышы еллары (1941-1945) татар прозасы (гомуми күзәтү)

**Лекция 1**

**Аннотация.** Лекциядә Бөек Ватан сугышы елларында (1941-1945) әдәби-мәдәни барыш, сугыш еллары татар прозасында юнәлешләр, иҗат агымы, жанрлар өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** иҗат агымы, жанрлар, хикәя, нәсер, очерк.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы:**

1. Бөек Ватан сугышы елларында (1941-1945) әдәби-мәдәни барыш.
2. Сугыш еллары татар прозасында юнәлешләр.
3. Соцреалим иҗат агымы: сугыш чоры прозасында тоткан урыны.
4. Яшәеш фәлсәфәсен сугыш темасына төреп биргән хикәяләрдә яшәү / үлем бинар оппозициясе.
5. Сугыш чоры прозасында жанрлар (нәсер, хикәя, очерк).

Бөек Ватан сугышы елларында татар әдәбияты сугыш вакыйгасы куйган таләпләргә җавап бирә. Бу елларда  татар прозасы ***ике юнәлештә*** үсә.

***Беренче – әйдәп баручы юнәлешне*** 1917 елдан соң сәяси тормыштагы үзгәрешләр һәм иҗтимагый вазифаларның эчтәлеге яңаруы нәтиҗәсендә ***яшәп килүче идеология шартлары әзерли***. Билгеле булганча, әлеге вәзгыять кешене иҗтимагый тормышта һәм көнкүрештә тасвирлауны алга ала, үзара дуслык һәм ышанычка корылган мөнәсәбәтләр тәрбияләү бурычын куя. XX йөз башы татар әдәбиятындагы халык азатлыгы, милли үсеш идеяләре, шулай ук мәхәббәт, әхлак төшенчәләре урынына пролетариат мәнфәгатьләренә хезмәт итәрлек, социалистик җәмгыять  үсешендә таяныч булырлык  идеяләр алга сугарылуы мәгълүм. Пролетариат сыйныфының “социологик” идеалы калка, Й.Нигъмәтуллина әлеге күренешне мәдәниятнең семантик-синтаксик төренең өстенлек алуы белән нигезли.

Әдәбият галиме Д. Заһидуллина яңа концепциянең нигезенә революцион сәнгатьтә революциянең үзе чагылу, чынбарлык материалы сәнгать әсәренә күчерелгәндә, коммунизм идеалы яктылыгында бәяләп күчерелү; әсәрнең тормышка яңадан актив тәэсир ясавы – хезмәт ияләрен коммунизм  идеяләре

рухында тәрбияләүгә булышу принциплары салына, дип билгели. Галимә марксистик теориянең татар әдәбиятына үтеп керүенең фәлсәфи һәм теоретик җирлеген нигезли. XX йөз башы әдәби фикерендәге “җәмгыятьчеләр мәктәбе”, позитивизм теориясе өйрәтүләрендә үк әзерләнгән була. XX йөз башында иҗат ителгән әсәрләрдәге рухи башлангыч, мәхәббәт фәлсәфәсе марксистик теориядә кире кагыла, яшәү көчен символлаштырып, яшәешнең нигезендә яткан субъективлык, эчке дөнья белән бәйләнгән мәхәббәткә алмашка позитивистик төшенчәләр килә. Инкыйлабтан соң башланган “тигезләү” нәтиҗәсендә җәмгыять үсешенә “массалар сәясәте” үтеп керә, фәлсәфи фикердә бу күренеш “массалар күтәрелеше” исемен ала. З.Фрейд  күзаллаган иҗтимагый төзелеш – хакимият вәкилләрен күккә чөйгән, калганнарны үз-үзләрен бәяли алмаучы, агымга ияреп яшәүче, тотрыксыз халәттә яшәүче кебек бәяләгән  “юлбашчы – элита – масса” структурасы  тормышка ашырыла. Әдәбиятта “толпа” “масса кешесе” төркеменә кертелә. Шул рәвешле, XX гасыр башындагы идеалларны социалистик җәмгыять төзүче бөеклек, гаделлек, олылык символы буларак күтәрелгән Ленин, Сталин образлары алыштыра.

Агымдагы шартларда татар әдәбиятында яңа тормышны социалистик идеяләргә нигезләнеп төзү мәсьәләсен үзәккә куйган әсәрләр языла – соцреализм агымы формалаша (1917–1932). Татар әдәбиятында ул – коммунизмның җиңәчәгенә чиксез ышаныч, оптимизм белән сугарылган әдәби агым. Кешедәге героизм, корбанчылык сыйфатларын данлап, яңа тормыш хакына үзен корбан итүчеләргә сокланып мәйданга килсә дә, 1932 елдан соң соцреализм агымы җәмгыять үсешенең бер юлы булган марксистик-ленинчыл концепцияне бердәнбер хакыйкать итеп исбатлуга кадәр үсә. 1934 елны рәсми рәвештә расланган соцреалим иҗат агымы 40-50 еллар әдәбиятының үсешен билгели. Бу дәвердә әдәбиятны сыйнфый көрәш, социалистик тәрбия чарасы итеп күрү, әсәрләрдә тудырылган тормышның чынбарлыкка якын булырга тиешлеген күтәрү марксизм тәгълиматына нигезләнгән закончалыкларның урнашып җитүе турында хәбәр итә. С.Франк фикеренчә, марксистик теория төп

максатларына ирешү өчен патриотизм тойгысы тәрбияләүне көчәйтү бурычын да куя һәм бу вазифа әдәбиятка йөкләнә.

Сугыш вакытында милли әдәбиятларның үсеше мәсьәләсе СССР Язучылар союзының игътибар үзәгендә була. ВКП(б) Үзәк Комитеты 1942 елны кабул иткән “Матбугат өлкәсендә партиянең иң әһәмиятле бурычлары турында” дигән карарында: “Хәзерге хәл белән бәйләнешле рәвештә, бөтен үзәк һәм урыннардагы көндәлек матбугатта игътибарны Кызыл Армия һәм флотның эчке тормышын һәм көнкүрешен ачыклауны көчәйтергә”, – дип билгели. Рус һәм татар язучыларының бергәләп эшләүләре һәм иҗат итүләре бу елларда гадәти күренешкә әверелә.

Сугыш елларында барлык язучылар да публицистикага мөрәҗәгать итә. Публицистика аеруча проза жанрларына йогынты ясый, аларга үтеп керә. Жанр элементларының үзара тыгыз аралашуы ***кече жанрлар – хикәя белән очерк*** арасында чикләр җуела бара. Хикәядә публицистик пафосның көчәеп китүе, очеркның төзек композициягә корылуы – моның ачык мисалы. Әйдәп баручы «хәрби заман тормышының кызу агымын тиз арада күрсәтергә мөмкинлек биргән» хикәя, очерк жанрлары башкача сугыш чорының кече яисә лирик эпосы дип тә исемләнә.

1941-1945 еллар аралыгында язылган хикәяләрдә ***хронотоп*** төгәл билгеләнә: вакыйгалар сугыш вакытында взвод, рота, госпиталь, авыл, камалышта калган торак пунктта, елга тирәсендә һ.б. бара. Лирик төсмерле хикәяләүгә еш кына ретроспектив вакытка мөрәҗәгать итү аша ирешелә. Тыныч тормыш кебек төгәлләнүче үткән һәм бүгенгенең кырыс чынбарлыгы каршылыгын көчәйтүгә урын бирелеше ярдәм итә. М.Әмирнең «Сыерчык» нәсерендә (1943) җыелма характердагы кичәге авыл образы хикәяләүченең сыерчык белән сөйләшүе кебек бирелгән әкияти катламда сыерчык теле белән сурәтләнә: яз саен бөдрәләнеп яфрак яра, тирә-якны бал исенә күмеп, аксыл-сары чәчәк ата торган йомшак юкә агачы, гөлбакча, дранча белән ябылган нарат өй. Аңа каршы бирелгән сугыш үткән авыл шыксыз чокырлы, ялангач нарат калдыклары өелгән, кара күмергә әверелгән хәлдә япа-ялгыз сөрәеп калган

ялангач агачлы, өстәвенә, салкын көзне хәтерләтүче язгы җил искән, таланган, йолкынып беткән урманлы кебек тасвирлана. Авторның табышы – хикәяләүче уйларын табигать образына салып, эчке монолог алымын төрләндерүдә. Ловать елгасы, Ильмень күле кебек төгәл бирелгән урынга бәйле тавышларны каршы куеп, алдан ук каршылык көченә басым ясала (елганың гадәттәге мәһабәт шаулау тавышы миналарның ямьсез шартлавына каршы бирелә).

Урын-вакыт бирелешенең символик мәгънәле булуы да соралып тора: иң еш кабатланган яз яңадан туу мәгънәсендә яшәү-үлем, юк ителү конфликтын да көчәйтеп килә. Шул ук вазифа куркыныч тудыручы төн, буранлы кич вакытларына да йөкләнә.

Хикәяләрдә вакыйгалар үстерелеше еш кына хис-кичереш үсеше кебек алып барыла, геройлар тавышында автор тавышы да «ишетелә».

Геройның – кичәге гади хезмәт кешесенең – күңел халәте туган җире, якыннары турында үзалдына уйланып, юксынудан билгесезлектән курку, гаҗизлеккә кадәр үстерелә. Сугышка кергәндәге курку хисенең сәбәбе алда көтелгән газаплар, сагыш, үлем куркынычы кебек төгәлләшә. Ярдәмче геройлар күп очракта исемләнми, алар ана, бала, солдат, карт образлары кебек типиклаштырыла. Шул рәвешле реаль тормыш вакыйгаларына серлелек өстәлә, конфликтның чишелеше ирреальлекне ачыклау аша башкарыла. Конфликт тыныч тормыш һәм сугыш чынбарлыгы, бурыч һәм намус, яшәү һәм үлем арасындагы кискен каршылык булып төгәлләшә. Хикәяләрдә тыныч тормышның матурлыгы портрет алымы белән көчәйтелә. Ә.Еникинең «Бала» хикәясендә (1941) җыелма образ – бала портреты ярату, үз итү тойгысы уята. М.Әмирнең «Сыерчык» нәсерендә сыерчыкның тышкы рәвеше баланыкын хәтерләтә: «күгелҗем нур уйнатып елкылдаган түш каурыйлары, нечкә, нәни тәпиләре» хикәяләүчене үткәндәге матур тормышка алып кайта. И.Газинең истәлек формасына тартымрак «Малай белән эт» хикәясендә малайның тойгы портретына милли төсмер өстәлә. «Кап-кара күзле, озын керфекле, түгәрәк йөзле чибәр генә татар малаеның» берүзенә «туры килгән» алты-җиде кешелек ярату аның үлеме фаҗигасен көчәйтеп бирергә ярдәм итә. Бала белән

бәйләнештә бирелгән ана образы ил анасы архетибына туры килә. И.Газинең «Ана» (1942) хикәясендә зәңгәр күзле газиз улын югалткан ананың партизаннарга ярдәм итүе тасвирлана. Сугыш чорында язылган хикәяләрдә даими кабатланып килүче карт образы – сугыш дәвере прозасын XX гасыр ахырында шартлы метафорик кимәлдә язылган проза белән бәйләп торучы образ. Карт образы намус һәм бурыч каршылыгына корылган хикәяләрдә олы җанлылык, сабырлык, хакыйкать мәгънәсен символлаштырып килә. Ф.Хөснинең «Түбән оч» хикәясендә (1943) киң сакаллы, калын кашлы, зур гәүдәле, мәһабәт бер карт улына бирелгән җәзаны ишетүгә юк була. Аны кайчандыр үлем тырнагыннан йолып калган егеткә ике пот арыш урлаганы өчен җәза биргән Зәйнәпнең күз уңыннан югаламы, суд залыннан чыгып китеп юк буламы – автор ачыклык кертми. Образлар бирелеше, үз чоры өчен типик тормыш вакыйгасының сайланышы карт образына салынган яшәп килүче системага карата автор позициясен билгеләргә ярдәм итә. А.Шамовның «Дустым кабере янында» хикәясендә (1945) разведкага китеп югалган дусларының кабере янына алып килүче шактый иске кара эшләпә, өстенә кара пиджак кигән чал чәчле, киң сакаллы, яланаяклы, урта буйлы карт ата вазифасын башкара: «Аның тулган ай яктысында көмештәй җемелдәп күренгән чал чәчендә, юка һәм кыска сакалында бераз калкып торган бөкресендә тел белән әйтеп, аңлатып булмаслык ягымлылык, картларча күркәмлелек бар. Мин аңа карап, чал чәчле әтиемне һәм Шәйхетдиновның атасын хәтерлим». Әйтергә кирәк, сугыш чоры хикәяләрендә лейтенант, полковник образларына да еш кына шул мәгънәви йөкләмә салына. Ә.Еникинең «Бала» хикәясендә (1941) лейтенант баланың әтисе һәм Зарифның командиры кебек кабатлана. Ф.Хөснинең «Солдат хикәясе»ндә (1942) полковникның үлеме фаҗигасе тасвирлана.

30 нчы еллардан башлап прозаны торгынлыкка китергән соцреализмдагы метажанр, стиль доминантасы буларак фольклор формаларын алга кую – сугыш чоры прозасының бер ягы буларак тамгалана.

***Икенче юнәлеш*** XX гасыр башы татар фәлсәфи прозасында милләт мәсьәләсенә игътибар иткән күпмәгънәле, күпкатламлы текстларның сугыш чорында әдәби иҗат эшенә аңлы рәвештә алынган яшь язучыларга йогынтысы нәтиҗәсендә калыплаша. Бу юнәлеш Әмирхан Еники исеме белән бәйле. Әдип иҗатында “гомумкешелек – милләт – шәхес” чылбыры алга куела. ***Яшәеш фәлсәфәсен күрсәтүче хикәяләрдә*** үлем, өметләр өзелү, яшәүнең мәгънәсен җую хакында сүз барганда ***автор*** бер төркем ***символларга мөрәҗәгать итә***.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Бөек Ватан сугышы татар прозасы нинди ике юнәлештә үсә?
2. Соцреализм нигезенә салынган концепцияне билгеләп куегыз.
3. Бу иҗат агымы татар прозасында нинди үзенчәлек белән оеша?
4. Бу дәвердә нинди эпик жанрлар өстенлек ала?
5. Кайсы әсәрләрдә фәлсәфи бинар оппозиция текст структурасын оештыра?

**Әдәбият исемлеге.**


1.Гайнуллина Г.Р.1940-1980 еллар татар прозасы тарихы (тексттагы мәгънәләрне табу): Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Казан дәүләт университеты, 2009.– 100 б.

2. Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Юсупова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Беренче китап: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.


## Тема 5. Сугыш чоры хикәяләрендә фәлсәфи катлам. Ә.Еникинең (1909- 2000) сугыш чоры хикәяләре. “Бала”, “Бер генә сәгатькә” хикәяләре

**Лекция 1**

**Аннотация.** Лекциядә Ә.Еникинең сугыш чоры хикәяләрендә яшәеш фәлсәфәсе бирелеше, “Бала” хикәясендә көчле позиция, хикәяләүче образы,

символлар аша аңланган эчтәлек, төп геройның хис-кичерешләр хәрәкәте бирелеше, хикәянең сюжет структурасы өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** көчле позиция, хикәяләүче образы, символлар аша аңланган эчтәлек, сюжет структурасы.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**

1. Ә.Еникинең сугыш чоры хикәяләрендә яшәеш фәлсәфәсе бирелеше.
2. Ә.Еникинең “Бала” хикәясендә көчле позиция, хикәяләүче образы, символлар аша аңланган эчтәлек.
3. Хикәядә төп геройның хис-кичерешләр хәрәкәте бирелеше.
4. Хикәянең сюжет структурасы.

Ә.Еники сугыш чорында дистәдән артык хикәя, нәсер иҗат итә. Алар күңел кичерешләре бирелеше ягыннан ачыш хикәясе таләпләренә туры киләләр.

Ә.Еникинең “Бала” хикәясе (1941) сугыш чоры прозасының иң матур үрнәкләреннән санала. Текст “Сөекле кызым Резедага багышлыйм” дигән ***эпиграф*** белән башланып китә. Бу өлеш әсәргә куелган исемне, әсәрдәге кыз персонажны бәйләп килә.

Хикәяләүче укучыны “лейтенант Иванов ротасы” белән сынаулар аша үтү юлы кебек шәрехләнгән урман юлына алып керә. Биредә хикәяләүче исеменнән авторның укучыны “зур саклык белән алгы позициягә” алып бару омтылышы әйтелә. Юл хронотобы урман пространствосы белән янәшә бирелү сынау юлының катлаулы булуын искәртә. М.Бахтин аңлатуына караганда, геройның билгеле бер вакыттагы хәрәкәтен тәэмин итүче шәхси юлы булырга тиеш. Геройның хәрәкәте күпмедер дәрәҗәдә алдан билгеләнгән: юл буш түгел,

димәк,  шәхси дип кабул ителгән сынау юлы кабатланган, аны үтү өчен канун-кагыйдәләр дә табылган. Шуңа күрә юл хронотобы геройның шәхси юлы булудан өстен. Биредә гөнаһсыз сабый образына салынган эчтәлекне билгеләп үтү зарур. Әсәрнең исеменә, эпиграфка – көчле позициягә чыгарылган бала геройны сынау алдында калдырган персонаж. Теләсә кемне ***уйланырга мәҗбүр итә алган бердәнбер хакыйкать белдерелеше булган бала*** белән очрашу ***кешенең үз намусы, вөҗданы белән очрашу, бер эзгә басу*** эчтәлеген ала. Автор кешедәге ***шәхси юлның башы – үз намусың – илаһи башлангычың белән “сөйләшү”гә,  гармониягә –  күңел тынычлыгына омтылуга ихтыяҗ туу,*** ди.  Хикәяләүче укучыга тулы дип тасвирлаган юл  әлегә “мәкерле тыныч, буш”. Димәк, ***буыннар сызган юлның кайтавазы кеше күңелендә яңгыраш тапканчы шәхси тормыш юлы буш һәм яшәү тәртипләре турындагы мирасны кабул иткәнче ул мәкерле тыныч, ягъни бер сынауны үткәндә кылган ялгыш  икенче – күпкә катлаулырак сынауны әзерли.***

Урман пространствосын тасвирлау –  сынау юлының эчтәлеген ачу кебек укыла. Сынау юлы – “урман, үз-үзен тыңлагандай, хәрәкәтсез һәм тып-тын”. Бу – кешенең уйлану, олы гамь алдында калу мизгеле. Үз-үзен –  намусын тыңларга чакырылган укучы әлеге хәрәкәтсезлек, ягъни гамьсезлек халәтенең сурәтен укый. Хикәяләүче укучыга бу халәтне тынлык – нәрсәдер көтү мизгеле дип тасвирлый. Илаһи мәхәббәт символы  кебек кабул ителгән нур образын кояш чыккан вакыт – таң вакыты образы белән янәшә куеп, хикәяләүче укучыга кеше күңелендә  уяну, үзгәрешләр булачагы, бу халәтне мәхәббәт хисе билгеләргә тиешлеген искәртә. Укучыны шул яңа халәтне тоярга әзерләү дәвам итә.  Көмеш яфракларның сөенә-сөенә уйнавы укучыны тынлык артында көтелгән илаһи серле рәхәтлек барлыгына ышандыра. Әлегә “ачык урыннарда, җиргә таба сыгыла төшеп, хәрәкәтсез ак томан ята”, “тән ниндидер бер җиңеллек, күңел исә шул җиңеллектән гамьсез бер рәхәтлек тоя...” ***Гамьсез бер рәхәтлек – хәрәкәтсезлекнең эчтәлеге, ягъни кеше күңелендә әлегә гамь булып оешмаган, аның гамәлләренең башлангычы булып тормаган,***

***ниһаять, кешенең күңел төпкеленә яшерелгән, ләкин әлегә табылмаган үз асылы.***

Шул рәвешле, укучыны төп геройның үзе белән таныштырганчы, автор иң элек аның эчке халәтен сөйли. Укучы геройның әлеге халәтен үзе аша үткәрә, хәтта уйлана ук башлый. Автор хикәяләүчесе исеменнән уй-гамәлләрнең һәркайсы алдагы гамәл белән сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә икәнлеген гел искәртеп тора: “...эзләр, яшькелт-кара тасмадай, артта сузылып кала.”

Укучы Зариф янына хәзер инде “ротаның артсы рәтенә” урнаштырыла. Зариф йөзендәге “тыныч ваемсызлыкны” укучы гамьсезлек чагылышы дип бәяли, шуны төгәлләштерү өчен бирелгән портрет детальләренә, хәрәкәт аталышына салынган эчтәлекне укый. Зариф уйларының эчтәлеген сөйләр алдыннан хикәяләүче гамьсезлекнең җимергеч олы көч икәнлеген искәртә Авторның фикер юнәлеше гамьсезлекне яшәеш юлы дип кабул иткәннәргә борыла. Гамьсез-вафасыз яшәү, башкалар артыннан салмак кына атлап бару – күпләрнең тормыш-юлы, яшәеш кагыйдәсе. Алар аны бәхетле булу юлы дип саный, чөнки башкалар дөньясында үзеңне шулай табу уңайлы, җайлы, кемнеңдер чынбарлыгына үтеп кергән башка сыймас хәсрәтләр борчымый, бүгенгесе һәм үзеңнеке кыйммәт. Гамьсезлекне яшәеш юлы иткәннәр алданучан, ди автор, биредә үлем төшенчәсе килеп керү дә очраклы түгел. Бу урында **яшәү-үлем** проблемасы куела, хикәя шул проблеманы яктыртуга корыла.

Хикәяләүче тасвирлаган бәхетле-тыныч тормыш сурәте - Зариф идеал иткән чынбарлык – кеше яшәешенең иң гади, әмма һәркайчан сагынып теләгән мәгънәсе икәнлеге белән укучы берсүзсез килешә. ***Яшәүне һәм үлемне мәгънәле итүче бердәнбер хакыйкать ул – туган ил, торган җир, сөйгән яр, бала***. Әмирхан Еники иҗатын иңләгән әлеге тема бу хикәядә шул хакыйкатьне аңлауга килү проблемасы төсендә яңгыраш ала.

Автор биредә **пространство үзгәртелү** аша кеше күңелендә әзерләнгән үзгәреш турында сөйли. Туган ил сурәте – күңелнең иркен-рәхәт чагы тасвиры

(зәңгәр урманлы, киң кырлы), авыл сурәте – таныш, димәк кадерле, үз, якын дигәнне белдереп килә. Урам күпере, басу юлы, иген кыры әлеге чынбарлыктан китү, башка – таныш булмаган чынбарлыкка күчү сурәте. Ләкин уйлары Зарифны үзе якын иткән чынбарлыкка тарта.Ә.Еники ике чынбарлык чиген төгәл билгели. Әлеге араны кеше үзенә таныш чынбарлыктагы кануннарга буйсынып үтә. Командирның “Һава!” дип кычкыруы аны һич көтмәгәндә үзгә чынбарлыкны кабул итәргә мәҗбүр итә. Үзе өчен чит булган әлеге чынбарлыкта Зариф югалып кала, лейтенантның командасын ишетми, бары иптәшләре артыннан урыныннан кузгала. Димәк, Зарифта әлегә чит чынбарлыкта да үзе булып калырлык рухи ныклык җитешмиме? Юк, ләкин таныш булмаган яңа дөнья кешедән күпмедер күләмдә буйсынуны таләп итә. ***Рухи ныклык, ышанычлы әхлакый нигез булу чит чынбарлыкта да үзеңне табу мөмкинлеген булдыра***.

Вакыйгаларда Зариф идеал иткән чынбарлык хакыйкате – мәхәббәт раслана. Төенләнештә укучы Зарифның кыз образына салынган илаһи матурлык белән очрашу мизгелен укый. Кызның ялгызлыгы, ярдәмгә мохтаҗ булуының укучыда кызгану хисе уятуы табигый.  Вакыйгаларда кыз түгел, яшәүне мәгънәле итүче бердәнбер хакыйкать туган ил, торган җир, сөйгән яр, бала, дип ышанган Зариф сынала. Димәк, ул тыныч-тигез тормышның нигезен белә, ләкин шул тормышны саклый-яклый белү – ***сынаулар килгәндә намусны алга кую ул.***  Автор укучысына ***сүз һәм гамәл берлеге турында*** – намусның яшәү кагыйдәсе булырга тиешлеге хакында сөйләргә алына.  Шул рәвешле, бала-намус Зарифны яшәү юлына алып чыгачак, аның рухын какшамас итәчәк.

Укучы Зарифның юлда бала  белән очрашуын җентекләп күзәтә. “Өч-дүрт яшьлек кыз баланың басып торганын күреп, бер адым да атларга өлгермәгән килеш ихтыярсыз тукталган” Зариф кызның ялгыз булуына бик гаҗәпләнә. Укучы кызның портретына салынган эчтәлекне укый – “озак елаудан күз төпләре шешенгән, кечкенә кулына берничә бөртек каен җиләге учлаган, шуны кабарга хәзерләнгән җиреннән туктап, зур соры күзләре белән Зарифка исе китеп карап торучы бала” ярдәмгә мохтаҗ. Кызны тагын да матуррак сурәтләү

мөмкин түгелдер. Ләкин авторның уе кызның матурлыгы аша укучыда хис тәрбияләүгә юнәлгән. Укучы Зарифның кызның камиллеге аша бирелгән матурлыкны һичшиксез коткаруын көтә. Ләкин герой ике юл чатында: "...аңарда кузгалган беренче теләк баланы тизрәк күтәреп аласы килү теләге булды. Шул ук вакытта ул ротадан аерылып калырга һич ярамаганлыгын да уйлап алды." Герой бурыч үтәү ягына борыла - буйсына : "беренче хәрәкәте аның ротасы артыннан китү өчен юлга таба борылу булды". Ләкин хәрәкәт булмый кала: "...ул, бер адым да атламастан, кинәт балага таба кире борылды, ашыгып кына янына барды да җитез генә күтәреп алды". Дөресрәге, Зариф әлегә үзе дә абайламыйча, алга юнәлгән кискен хәрәкәт ясый: "Зариф, баланы кысып тоткан килеш, аяк астында аунаган чыбыкларга, агач төпләренә абынмас өчен сикерә-атлый, ашыгып юлга чыкты." Арткы рәттә салмак кына барган Зариф каршылык тудыручы башка шартларны сикереп үтеп (аяк астында аунаган чыбыклар, агач төпләре детальләре). Укучы Зарифның бу хәрәкәте эчке ярсу омтылыш белән бәйле икәнен сизә. Зариф башкача булдыра алмаганга, үз җанын тыңлап, шулай эшли. Ләкин "сыңар кулы белән мылтыгын уңайлый төшеп, кызу-кызу атлавы" аның күңелендә борчу барлыгын сиздерә.

Баланың Зарифка мөнәсәбәте бирелеше аша укучы гүяки Зарифның эчке тавышы белән сөйләшүен укый. Алдан беркадәр ятсынган бала (Зарифның битеннән этәреп, аякларын селкеп елавы) – Зарифның беренче хәрәкәтенең – ротасы артыннан китү өчен юлга таба борылуының кабатланышы. Алдагы "сөйләшү"дә Зариф баланы, бала Зариф биргән шикәрне күкрәккә кыса. Шул урында Зарифның үз кызы Фәридәгә мәхәббәте әйтелә. Газиз баласын уйлау Зарифта "дулкын булып күтәрелгән сөенечле бер ярату" хисен көчәйтә, "бәлки ул шул минутта үз баласы белән бу бала арасында аерма тоймыйдыр". Димәк, автор Зарифтагы ярсу омтылышны нигезли. Бу адымга ирне йөрәгендә яшәгән ярату хисе этәргән булып чыга. ***Мәхәббәтнең эчтәлеге булып торган җаваплылык хисе*** ирдә үзенә бәйсез рәвештә яши. Бу хисне бернинди шартлар да үзгәртә алмый. Ләкин бу хиснең киеренке шартларда өстенлек алуы кешене үзгәртә. ***Кеше үзендәге җаваплылык хисен аң төпкеленнән аң өлешенә***

***күчерә, башка гамәлләрен шул хисне аңлы рәвештә алга куеп башкара. Хис торган саен көчәя – кешенең рухы ныгый, мәхәббәткә мөнәсәбәте алышына. Ярату дөньядагы иң олы көч буларак танылa һәм яшәү рәвешенә әверелә. Һәркем алдында торган бурыч әнә шул.***

Укучы Зарифның яшәү ягына чыгуын аңлый, күз яшьләре ир күңелендә урнашкан мәхәббәтнең ныклыгын раслап куя: "Әтиең, әниең бармы? – дип сорады Зариф, һәм аның тамак төбе кытыкланып, күзләре дымланып китте".

Зариф белән бала арасындагы алдагы сөйләшүдә укучы ике туганның бер булып яшәвен күрә ("бала, тарсынмыйча, әүвәл бер кулындагы ике бөртек *җиләг*ен капты, соңра икенче кулындагы *шикәр*ен суыра башлады"). Бала теле белән кеше өчен иң кадерле булган кыйммәтләр хакыйкать буларак кабатлана. Кәҗә детале гаилә, тормыш бөтенлеген искәртеп килә. Тик тагын бер хакыйкать Зариф өчен әйтелгәндәй укучыга ишеттерелә. Әти кеше – баланың таянычы, горурлыгы, саклаучысы икән (баланың горурланып әтисенең лейтенант икәнлеген әйтүе). Димәк, ярата белү – башкалар горурланырлык кеше була алу, ди автор.

Ләкин укучы Зариф күңелендә урнашкан, аңланган җаваплылык хисенең әле сыналачагын көтә. Чөнки Зарифны бәхетле иткән ярсу омтылышы аның киләчәк гамәлләренең дә башлангычы булып ныгырга тиеш. Иң мөһиме – Зарифның бу юлдан китмәячәгенә укучы ышанырга, ахыр килеп, бу юлны үз яшәү юлы итеп кабул итәргә тиеш. Артиллерия атышы пространствода шомлы тынлык урнаштыра. Укучыда геройларны борчыган сорау туа: нишләргә? Зариф та бала кебек менә-менә югалып калыр сыман. Укучы хисләрнең киеренкеләнгәнен сизә, Зариф баланы юата алырмы? Иң мөһиме – Зариф моңа үзе ышанмый. (баланы юатканда аңа "үз тавышы баз эченнән килгәндәй тонык, саңгырау булып ишетелә"). Биредә автор укучыдан яратуны җиңә алырлык бердәнбер җимергеч көчне – курку хисен таптыра.***"Без кая барабыз?"*** – хикәяләүче укучыга шулай эндәшә, юл башында гел куелырга тиеш сорау икәнлеген искәртә.

Бу өлештә бала образы тулысынча укыла. Баланың җитди итеп: “Әбиләргә кунакка,” – дип җавап бирүе укучыны елмаерга, шул ук вакытта уйланырга мәҗбүр итә. Юл башында җаваплылык хисе тора икән, бу сорауга җавап әзер, ул катгый, бер һәм үзгәрә алмый торган хакыйкать кебек. Бала бер юлны гына белә, намуслы кеше дә нәкъ шулай. Биредә автор кешенең эчке тавышын җитди яңгырата кебек (“Зариф хәзер чыннан да аптырашта калды. Нишләргә?”) Укучы Зарифны намусы кушканча эшләргә этәргән ярсу омтылышның салкын исәп белән алышынуын, Зарифның курка төшүен сизә (“Дөресен әйткәндә, ул һич туктамастан ротасын куып җитәргә тиеш”). Шул рәвешле, ***автор кешеләрне исәп-хисап колы иткән хисне атый – курку.***

Укучы Зарифны башка юл сайласа, гафу итмәс иде. Әмирхан Еникинең осталыгы да шунда. Ул укучысын **герое пространствосында** – аның күңел кичерешләре “тозагында” тота. Зариф әле җаваплылыкны аң өлешендә урнаштырып, яшәү кагыйдәсе итмәгән икән. Югыйсә, аңарда икеләнү булмас иде. Укучы Зарифның җаваплылык һәм курку хисе белән билгеләнгән **ике яшәү юлында** калуын укый. Мондый вакытта кеше соңгы өмет белән, чакырып илаһияткә, башкаларга мөрәҗәгать итә. Асылда кеше үз намусына – илаһи башлангычына эндәшә. Бу – <u>кешенең илаһи башлангычы белән элемтәгә керү омтылышы мизгеле.</u> Башкача, намусның эндәшүе (“Бала, Зарифның нәрсә уйлаганын сизенгән шикелле, зур булып ачылган күзләре белән аңа бик җитди карап тора”). Хәзер инде Зариф, никадәр авыр булса да борылмаячак, чөнки автор укучысына шулай гына тиеш икәнлеген раслады. Зариф илаһи башлангычын таба (“Бу караш Зарифның икеләнүен өзде...”)

<u>Станциянең платформасы</u> – Зариф сайлаган юлның башы, <u>тимер юл</u> – аның турылыгы белдерелеше. Ана – кеше өчен намуслылык бизмәне. Әнисен тапкан бала кулыннан төшеп киткән шикәр деталенең мәгънәсе – рухи ныклык – тормыш юлында иң җитди таяныч дигән эчтәлек ачыла. Шул урында Зарифның күңелендә урнашкан какшамас хакыйкать укыла: ул “ана белән баланың кавышу мизгеленә соклану тулы караш кына ташлый алды”.

Биредә Зарифның илаһи башлангычы белән якынаю мизгеле тасвирлана. Шул халәттә автор аны <u>чит тоелган дөньяга</u> алып керә (ул мылтыгын иңеннән кулына ала), ул лейтенант белән сөйләшә.

Текстта кабатланган <u>лейтенант образы</u> җаваплылык хисен яшәү кануны иткән бердәнбер образ кебек укыла. Зариф тагын үз юлының дөреслеген тикшерү алдында кала. Тик бу юлы аңа кешедән өстен торган хакыйкать үзе эндәшә: "***Сез зур изгелек эшләгәнсез***". Димәк, ***зур изгелекләр кыла алу - җаваплы була белү кешене гел алгы позициядә тота.*** Шуңа күрә автор әйткән, бала тарафыннан кабатланган ***яшәүне һәм үлемне мәгънәле итүче туган ил, торган җир, сөйгән яр, балага карата зур изгелекләр кылу турындагы бердәнбер хакыйкать*** лейтенант образына салынган эчтәлек аша көчәйтелә.

Соңгы өлештә авторның укучысына әйтергә теләгән сүзе укыла. Чын сугыш кыры дип рәхимсез яшәеш пространствосы атала. Димәк, кешенең яшәве ***үз-үзенә ышанудан башланырга тиеш.*** Шул вакытта кеше Илаһиятнең – "олы алмазның бөтен сыйфатларын үзендә саклый. Ул каты… һәм нурлар чагылдыра."

Укучы Зариф белән бергә <u>тынлык артында яшерелгән илаһи серле матурлыкны</u> – "аңлавы читен булган бер <u>тынычлыкны</u> тоя". <u>Гамьсез тынлыкны</u> Зариф омтылган "кояшлы иртә тынычлыгы, нурлы иртә матурлыгы" кебек <u>күңел тынычлыгы, гармония</u> алыштыра. Хәзер ирнең муенында – җаваплы булырга чакырып торган мәхәббәт назы – кул җылысы. Үлем тормышың мәгънәле булганда куркытмый ("ул пуля тисә, бары тик чеметеп кенә алыр кебек"), дип фәлсәфи проблеманың чишелеше табыла.

Ә.Еники зур саклык белән укучыны ***мәхәббәтнең илаһи асылына*** төрә, ***җаваплылык хисенең*** кешене "***алгы позициядә***" тотучы, ***чит*** чынбарлыкта ***үзең булып калырга*** ярдәм итүче ***буыннар тарафыннан расланган*** бердәнбер ***юл*** икәнлегенә төшендерә.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1.Ә.Еникинең “Бала” хикәясендә юл хронотобының урман пространствосы белән янәшә бирелүе нинди мәгънәгә ия?

2. Хикәянең сюжет структурасы.

3. Текстта кабатланган лейтенант образы нинди мәгънәне алып керә?

4. Әсәрдә психологизмның кайсы алымы кулланыла?

5. Көчле позициянең укылышын аңлатыгыз.

**Әдәбият исемлеге.**

1.Гайнуллина Г.Р.1940-1980 еллар татар прозасы тарихы (текстагы мәгънәләрне табу): Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Казан дәүләт университеты, 2009.– 100 б.

2.Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

## Лекция 2

**Аннотация.** Лекциядә Ә.Еникинең “Бер генә сәгатькә” хикәясендә көчле позиция, төп геройның хис-кичерешләр хәрәкәте бирелеше хикәяләүче образы сюжет структурасы сугыш чоры хикәяләрендә яшәеш фәлсәфәсе бирелеше өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** көчле позиция, хис-кичерешләр хәрәкәте, хикәяләүче образы, сюжет структурасы, яшәеш фәлсәфәсе.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**

1. Ә.Еникинең сугыш чоры хикәяләрендә яшәеш фәлсәфәсе бирелеше.

2. Ә.Еникинең “Бер генә сәгатькә” хикәясендә көчле позиция, хикәяләүче образы.
3. Хикәядә төп геройның хис-кичерешләр хәрәкәте бирелеше.
4. Хикәянең сюжет структурасы.

Ә.Еникинең “Бер генә сәгатькә“ (1944) хикәясендә вакыйгалар барган урын “авылдан ике километр ераклыктагы сөзәк сырт буйлап үткән тимер юл” белән бәйле рәвештә бирелә. Хикәядә тимер юл – бер юнәлешле юл, сөзәк сырт сакраль үзәк буларак гел кабатланып килә. Хикәяләүче вакыйгаларны күзәтүче позициясендә торучы автор карашын – әдип күңелендәгесен әйтеп барачак “Галимҗан абзый тәрәзәсеннән” бәяләргә чакыра һәм укучыны аның “авыл очындагы йортына” алып керә. Укучыга кешенең барган җирдән тукталып уйланган мәле һәм шул мизгелдәге кичерешләренең хакыйкатьне аңлауга алып чыгачагы турындагы төп эчтәлек **пространство бирелеше** аша искәртелә. Юл хронотобына кеше күңеленең тулган чагы да, вафасыз, битараф чагы да булырга мөмкин дигән эчтәлек салына. Бушлык – битарафлык хисе – кеше күңеленең “тупик”та икәнлеге, гүяки юлда барганда онытылып, югалып калганлыгы билгесе. Күңелдәге хисләр кешене ниндидер гамәлләр кылырга – хәрәкәт итәргә чакыралар, ***яшәешне шул хисләр бәйләме оештыра.*** Хисләрнең буталган чагы кешене барган җирдән тукталып уйланырга, борчылырга мәҗбүр итә. Хисләрнең тәртипле хәрәкәте, уйланган-үлчәнгән белдерелеше генә тормышның чынлап та алга баруын билгелиләр. Хисне йөртүче “ерактан бик сылу, дәртле, кыю булып күренгән” чынбарлык (кара паровоз) яшәештәге кеше кылачак сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендәге һәрбер кечкенә генә тоелган гамәлне билгели (“һавага бер-бер артлы тезелешеп киткән кечкенә ак болытлар тарата”).

Хикәяләүче хакыйкатьне эзләү юлында калган Мәрьям абыстай белән таныштыра. Аның әлеге кичерешләре үзе өчен яңа, көтелмәгән, чөнки үзендә моңа охшаш теләкләр барлыгын ул хәтерләми. Шул рәвешле, Мәрьям абыстайның кичерешләрендә үзгәрешләр барлыкка килүе “эчке һәм тышкыны,

җирне һәм күкне, кешене һәм Илаһины тоташтыручы” тәрәзә символы аша билгеләнә. Хикәяләүче инде “тәрәзәдән карап торырга гадәтләнгән” ананың кичерешләрен хәзерге даими халәте итеп тасвирлый.

Хикәядә өч улын сугышка озаткан ана образы аша яшәү-үлем фәлсәфәсе аңлатыла. Элек “авылның башка хатын-кызлары белән бергәләшеп станция каршына йомырка, сөт, май алып барып, сатып кайтуны” яшәү тәртибе иткән Мәрьям абыстай исәбенчә, тормыш – бер үк хисләрнең үзгәрешсез кабатланышы. Хикәя Мәрьям абыстайның әлеге “фәлсәфәсен” бәяләүгә, үзгәртүгә корылган. ***Ананың хәзерге даими халәте – үз теләкләренең үтәлүен көтү, тормыш-яшәешкә шул теләкләрнең чынга ашу-ашмау ноктасыннан бәя бирү*** (станция буш вакытта, өметсезлеккә бирелеп, тәрәзәдән китүе, озын эшелоннарны күрүгә, өметсезлекнең шул ук дәрәҗәдәге өметкә алышынуы). Автор кешене ярсу теләкләре үтәлергә мөмкин булган мизгелдә тасвирлый. Кеше сагынып көткән теләкләрнең үтәлү мизгеленә озак килә, шул сәбәпле аның күңеленә шушы өметләр һичшиксез дөрес, башкача булырга мөмкин түгел дигән ышаныч кереп урнаша. Теләкләрнең үтәлү мәленә якынлашу кичерешләрне киеренкеләндерә, әлеге мизгел якынлашкан саен кеше гүяки шул теләкләрендә эри, югала, аның теләсә кайсы гамәле шул максатка хезмәт итә башлый. Чынбарлыкның үзе белән очрашу мизгеле – хисләрнең иң киеренке чагы (күз яшьләре мотивы). Ярсу (тавышлы) теләкләргә чынбарлыкның битараф (тавышсыз) булуы кешене өметсезлек чигенә җиткерә. ***Тормыш-яшәешкә үз теләкләренең чынга ашу-ашмау ноктасыннан гына бәя бирергә гадәтләнгән кеше өметсезлек хисенә бирелеп, еш кына шул теләкләренең колына әверелә, үз яшәешен ямьсезли.Теләкләрнең үтәлмәве гомернең бетүенә тиңләнә.***

Укучы Мәрьям абыстайның яшәү мәгънәсен җуйган мизгелен укый. Бу халәткә җиткән аң гадәтләнгән бәхетле яшәү тәртибен шик астына куя. Иртә торып, “килене белән картының тышкы эшләрне бетереп керүләренә чәй урынын хәзерләп куярга” гадәтләнгән Мәрьям абыстай “кәефе ничек булуына карамастан” тәртипне бозмый, ләкин күңел биреп тә эшләми, өметсезлек

китергән халәт аны тозакта тота. Ихлас чакырып теләгән теләк чынга аша, “саңгырау хәлсезлек шаулап торган” ананың колагына: “Әни!” – дигән тавыш ишетелә”. Тик бары шул теләкне генә идеаль чынбарлык сурәте кебек кабул иткән кеше аның чынга ашу мизгелен якынайтып арыган, йончыган хәлдә була. Улының тавышын ишетүгә сискәнеп куйган “Мәрьям абыстайның бөтен тәне буйлап кискен калтырау йөгерде, ниндидер бер саташулы төштән котылырга теләгәндәй, ихтыярсыз башын чайкап куйды һәм авырайган күз кабакларын ачты. Мәрьям абыстайның күзләрендә бер секундка саташулы курку кабынган кебек булды”. Ананың психологик портреты, елау – аның кичерешләренең иң киеренке ноктасына җитүен хәбәр итә.

Шул урында хикәяләүче Галимҗан абзыйның психологик портретына игътибар иттерә. Ике портретның янәшә бирелүе очраклы түгел. Мәрьям абыстайның кичерешләре – ана кичерешләре дип кенә бәяләсәк, хикәя шул урында тәмамланырга тиеш иде. Ана кичерешләрен сынау әле дәвам итә. Галимҗан абзый портретына авырлыклар алдында югалып калмаска көч тапкан ир сыйфатлары салына. Карчыгын, киленен юатуы – башкаларны кайгыртуы Галимҗан абзыйның ***фәлсәфәсен*** ачып бирә: “ ***Сабыр бул!***” Автор карашларын әйтеп бирүче ата улыннан күпмегә кайтуын белешә. Укучы яңа кичерешләр дулкынына кинәт керә. Һәркемгә шатлык алып килгән Гомәрнең кайту ***вакыты бер генә сәгатьлек*** икәнлеге ачыклангач, конфликт башлана. Геройларның кичерешләре – “ят, ямьсез бер тавышка” – хәсрәтле, кырыс чынбарлыкка мөнәсәбәтләре төсендә яңгыратыла. Хисләрне үз урынына утырткан чынбарлык һәр геройның яшәешкә мөнәсәбәтенең белдерелеше кебек укыла. Гомәрне елап каршылаган Камилә аптырашта – “үзе дә сизмәстән елавыннан туктады”. Мәрьям абыстай тагын өметсезлек чоңгылына чума – “яңадан хәлсезләнде, әлеге бушлык аны янә үз эченә йота башлады”. Бала Зәйнәп барысының да теләген кычкырып җиткерүче: “Юк, юк... Китмисең, абый, китмисең!” Туктап калган вакытны Галимҗан абзый хәрәкәткә китерә: “...***Кешенең минутлары санаулы***”. Ә.Еники хакыйкатьне яшеребрәк белдерергә ярата, укучыны сискәндереп куя. Автор биредә ***кешегә санаулы минутлар – бер генә сәгать***

***авыр хисләр колы булып яшәр өчен түгел, ә якты хисләрне үстерер өчен бирелә*** дигән хакыйкатьне җиткерә кебек. Камиләнең килен буларак нәсел утын саклау гамәлен җиренә җиткереп башкаруы соклану уята. Нәсел-ыруны саклап тору билгесе кебек укылган учак образы Ә.Еникинең башка хикәяләрендә дә кабатлана. Бередә "улыннан ерак китәргә курыккан шикелле, һаман өстәл тирәсендә әйләнгән, кулына алган әйбере белән баскан урынында туктап калган, нәрсә эшләргә кирәклеген оныткан кебек, уйланып торган" ананың кичерешләре Галимҗан абзый тарафыннан бәяләнә, ул "үзе торып чәй хәзерләргә керешә". Автор авыр хисләр белән яшәп, кеше үзе кылырга тиешле гамәлдән ераклаша, ди. Иң мөһиме – ***авыр хисләр колы булып яшәү якыннарны уңайсызлый, читкә этәрә, бәхетсез итә, гомерне кадерсез итә*** дип кабатлый авылга "әтиемне, әниемне, барлык туганнарымны шатландырырмын, бәхетле итәрмен" дип "ашыгып, тирләп-пешеп, йөгерә-атлый кайткан" Гомәр бәясе аша. Автор сабырлык фәлсәфәсен татар кешесенең яшәеш фәлсәфәсе кебек тамгалап куя, соңрак ана белән ул күрешеп саубуллашу вакыйгасында кабатлый ( "татар улларына хас тыйнаклык белән, бары күрешмәкче" генә булса да, "әнисенең шундый тирән бер газаплы мәхәббәт белән сүзсез караган яшь тулы күзләрен очраткач, ирексездән аның кечкенә, җиңел гәүдәсен күкрәгенә кыса") .

Сабыр булырга чакырган тирәлек кешенең ярдәмчесе дә, шатлыкны бүлешергә килгән авыл малайлары-кызлары арасында туган бәхәс шул хакта. Биредә Мәрьям абыстайның улына ышаныч белдерүе, аның белән горурлануын сиздерүе  үзен кулга алуы турында сөйли. Бу халәттә ана улына чиксез көч өсти, аны мәхәббәт дөньясына алып чыга. Биредә Гомәрнең күз яшьләре аның хисләре яктыруы турында хәбәр итә. Димәк, ***чын мәхәббәтне һәр мизгелдә тоеп яшәү генә кешене авыр хисләрдән алып чыга, коткара ала,*** ди автор ана һәм ул образлары эчтәлегенә салып. Ә.Еники хикәяләрендә еш кабатланган бергәләп чәй эчү – автор, хикәяләүче, укучы, геройлар хисләренең бер дулкынга урнашуы турында сөйли. Биредә Гомәр гадәтләнгән сөенечле чынбарлыкка кайта (әтисе белән әнисенең таныш бәрелешүләре, аңа аларны

килештерелек сүз табарга кирәк булуы, әтисенең халыкара хәлләр белән кызыксынуы, әнисенең гаиләнең эчке сәясәтенә күбрәк игътибар бирүе). Ләкин, “санаулы минутларның үтеп китүе” һәммә кешене борчуга сала. Автор Галимҗан абзыйдан әлеге кырыс дөреслекне әйттерә дә, геройларның шул аерылу мизгеленә мөнәсәбәтен яшәешкә мөнәсәбәте кебек тамгалый. Гомәр “тыштан ничек тә тынычлыгын сакларга тырыша”, Мәрьям абыстай исә елый башлый, Галимҗан абзый сабыр булырга чакыра, Мәрьям абыстайның агасының улы Шәрифулла солдат барысын да киләчәккә ышанырга – көтәргә чакыра. Бу мизгелдә һәркем елый. Ана <u>күз яшьләренә мәхәббәт мәгънәсе</u> салына һәм әлеге мәхәббәт тудырган <u>илаһи хис – матурлыкны тою</u> тамгалана. Димәк, ***ана мәхәббәтенең мәңге сүнмәс җылысы матурлыкны тою өчен изге бер чишмә булып тора.*** Мәрьям өч тапкыр елый. Соңгысында аның мәхәббәт белән тулы эчке дөньясы ачыла.

Гомәрне озату – шул хисләрне сынау вакыйгасы буларак тәкъдим ителә. Автор гүяки ***тормыш кешене каршылау – килү, кунак итү – кунак булу, озату – китү кебек бер сәгатькә исәпләнгән өч вакыйгадан тора***, дип искәртә кебек. Автор Гомәрнең иңбашына юл капчыгы аса, ул капчыкта “оекбашлар, сөлге, яулыклар, азык-төлекләргә” төреп салынган хакыйкать – ***мәхәббәтнең мәңге сүнмәс җылылык бирүе буыннардан килгән мирас икәнлеге*** тамгалана. Кешенең гомере дәвамында шул хакыйкатьне аңлауга килүе – “торып киткән җирләренә кайтып, йөргән эзләренә яңадан басып йөрүе үз гомерендә кабатлана торган нәрсә” икәнлеге әйтелә. Хисләре үзгәргән Галимҗан абзый (иске кырпу эшләпәсен бүрегенә алыштырып кигән) бу хакыйкатьне раслап куя. Кара сатин тышлы билле бишмәтен киеп, кечкенә мамык шәлен беләгенә салып Мәрьям абыстай шул хакыйкатьне кабул итәргә әзерләнә. Е.Н.Бохонная фикеренчә, <u>шәл-яулык</u> халык авыз иҗатында ике дөнья арасындагы чик мәгънәсендә укыла. Ак яулыгын кулына алып поезд артыннан баргшан Заһидә дә ике дөнья чигенә куела.

<u>Җиңел тарантаска җигелгән туры ат образы хәрәкәтнең башына мәхәббәтне тою салына</u> дигән эчтәлекне укырга ярдәм итә. Шул урында автор

укучысын яңа рухи үргә әзерли. Яңа сулыш белән яши башлар өчен мәхәббәтне тою кирәк.

***Бер сәгатьлек гомерне мәхәббәт кенә илаһи матур, мәгънәле итә,*** дип автор шул хакыйкатьне солдатлар, Заһидә образы аша да раслап куя. Станция платформасында очраган солдатлар “эти-әниләре белән бәхетле күрешүгә өмет итүчеләр кебек” – шуны аңлаган кешеләр буларак тамгалана. Майор исеменнән хакыйкатьне аңлаганнар - горурланырлык кешеләр, дигән фикер җиткерелә. Биредә Мәрьям абыстайның ана буларак эчке кичерешләре – тынычлануы әйтелү дә әлеге карашны раслап кую өчен кирәк.

Аерылышу мизгелендәге иң авыр хисләрне кичерүгә укучы инде әзерләп куелды. Һәркемгә газаплы булган бу мизгел гүя кыска вакытлы тормышның кадере, шуңа күрә гел алга карарга, “бирешмәскә кирәклеген” искәртә кебек. Ана “бөтен сыны белән вагон ишегенә йотлыгып карый”. Гүяки Гомәргә бәйле чынбарлык “тоташ кызыллык эчендә югала”. Ахырда бу кызыллык, сыегаеп, чуар бер шәүләгә әйләнү, поезд артка таба чапкан кебек тоелу – мәхәббәт матурлыгы белән тудырылган яңа  хисләр чынбарлыгы ул.

***Мәхәббәт матурлыгы кешене яшәү юлына алып чыга, аны ярсу теләкләренең колы булудан азат итә.*** Кеше өмет белән яши башлый, ләкин бу өметне башка беркайчан да өметсезлек алыштыра алмый. Ана бу хакыйкатьне башкаларга җиткерергә бурычлы икәнен аңлый. “Җәйге пальтосының югары төймәләрен ычкындырган, башындагы ак яулыгын кулына алган, кыска толымнары сүтелә төшеп, чәч бөртекләре җилдә очкалаган, кыр җиленнән һәм кояштан янып каралган киң маңгаена, борын очына тир бөртекләре чыккан” Заһидә бу хакыйкатькә килү юлына чыгарыла. Әлегә ул ярсу теләкләре белән көрәшә, чынбарлык тудырган хисләр аның гамәлләрен билгели. Шул мизгелдә очраган туры ат детале кызны яңа юлга алып чыгачак яңа хисләр әзерләнүе турында искәртә. Бу хисләр дөньясына кызны “йомшак тавыш белән ата булып” Галимҗан абзый алып керергә тели: “Кызым, Заһидә, утыр безнең янга!” Ләкин Заһидә әле җир белән якынлыкны тою кирәклеген белә (юл буена чирәмгә утыра), чынлыкны аңлауга килү өчен хисләрнең дөрес

түгелен алып ташлау кирәклеген сизә.  Елау аны башка хисләр дулкынына күчәргә әзерләнгәнен хәбәр итә.

Хикәяләүче өметле яңа чынбарлык хөкем сөргән пространствога игътибар итә. Мәрьям абыстай улыннан калган портсигарны һәркемгә күрсәтеп, исән кайтуга өмет тудырганнан соң, яшереп куя, берөзлексез матур мизгелләрне хәтерендә яңарта. Галимҗан абзый "буе-сыны белән өлгереп җиткән, акылга утырган, холкы күркәм булып камилләшкән, чын ир булыр күренгән" улының киләчәге, гаилә корачагы турындагы хыялларны күңел төпкеленә яшерә. Камилә исә "өзелеп сагынган Фатихын ничек каршы алуы, нинди сый-хөрмәт күрсәтүе, нинди назлар белән куштанланып сөюе турында уйлаудан тыела алмый иде". Шул рәвешле, һәркем күңеленә мәхәббәт тудырган матур, якты, бераз хыялый, серле, әмма шулкадәр бәхетле чынбарлык кереп урнаша. Ана бу чынбарлыкны җуюдан курка, чөнки хыялда тудырылган хисләр кешене яшәтә, юлга алып чыга, тынычландыра бит. Аның " Кайтыр, күз нурым, кайтыр!" дип үзалдына әйтүе "өметләнергә кирәк, өмет хыялдагы хисләрне чынбарлыкка күчерә" дигән авторның укучыга мөрәҗәгате кебек укыла. Пейзаж кабатланышы ***мәхәббәтнең идеаль чынбарлык тудырырга сәләтле көчен хакыйкать*** итеп раслап куя. Станция буш, тимер юл тыныч. " Һәм күңел әнә шул нурлы томан артына китеп югалган яшел кырлар түреннән ерактагы поездның дәртле кычкыртып килеп чыгуын тоеп тора". Автор кешенең яшәешен аның хисләр бәйләме билгели дип кабатлый һәм әлеге хисләрнең һичшиксез якты булырга тиешлеген дәлилләп уза. ***Мәхәббәт яңа чынбарлыкка - өметле, бәхетле, ышанычлы хисләр дөньясна алып чыга, курку катыш ярсу теләкләрне юк итә, кыска вакытлы гомерне мәгънәле итә,*** ди Ә.Еники.

Ә.Еникинең сугыш чорында язылган хикәяләре яшәеш фәлсәфәсен тәкъдим итү ягыннан бер яктан, XX гасыр башы татар прозасының фәлсәфи канатының матур дәвамы булып торсалар, икенче яктан, 60-80 елларда прозаның үсешен билгеләгән тенденцияләрне нигезлиләр.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Ә.Еникинең “Бер генә сәгатькә“ хикәясендә юл хронотобына нинди эчтәлек салына?

2. Мәрьям абыстайның кичерешләрендә үзгәрешләр барлыкка килүе турында хәбәр итү өчен кайсы символик образ кулланыла:

3. Татар кешесенең яшәеш фәлсәфәсе кебек тәкъдим ителгән сабырлык фәлсәфәсе кайсы образ тарафыннан әйтелә?

4. Мәрьям абыстайның, Заһидәнең шәл-яулыгы дип бирелгән деталь халык авыз иҗатында нинди мәгънәгә ия?

5.. Җиңел тарантаска җигелгән туры ат образы нинди мәгънәгә ия?

6. Хикәянең сюжет структурасы.

**Әдәбият исемлеге.**


1.Гайнуллина Г.Р.1940-1980 еллар татар прозасы тарихы (тексттагы мәгънәләрне табу): Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Казан дәүләт университеты, 2009.– 100 б.

2.Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.


## Тема 6. Сугыштан соңгы елларда (1945- 1964) татар прозасы.

**Лекция 1**

**Аннотация.** Лекциядә сугыштан соңгы елларда (1945- 1964) татар прозасына гомуми күзәтү ясала, роман жанрының актуальләшүе, соцреализм иҗат агымы кысаларында язылган романнарда аерым шәхеснең кыйммәтенә игътибар арту, сугыштан соңгы татар әдәбиятында шәһәр прозасы (Г.Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романы) өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** роман, соцреализм иҗат агымы, шәһәр прозасы

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың

үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**

1. Сугыштан соңгы елларда (1945- 1964) татар прозасы. Гомуми күзәтү.
2. Роман жанрының актуальләшүе (Г.Бәширов, Г.Әпсәләмов, Ф.Хөсни, М.Әмир һ.б.).
3. Соцреализм иҗат агымы кысаларында язылган романнарда аерым шәхеснең кыйммәтенә игътибар арту (Г.Әпсәләмов, Г.Ахунов һ.б.).
4. Сугыштан соңгы татар әдәбиятында шәһәр прозасы (Г.Әпсәләмовның "Ак чәчәкләр" романы)

Сугыштан соңгы елларда (1945- 1964) татар прозасының **беренче юнәлешендә** соцреализм иҗат агымын ныгыту бара, **сугыш, хезмәт** темасы үзәк урынны били. Бу дәвер – XX гасырның беренче яртысына караган тарихи вакыйгалар, хезмәт темасын алга алган күләмле **романнар** язылу чоры. Г.Бәшировның "Намус" (1948) романында сугыш вакыты, тылдагы авыр хезмәт тасвирлана. Романда ике сюжет сызыгы – иҗтимагый – авыл кешеләренең икмәк өчен көрәше, ягъни хезмәт хакындагы; шәхси – Нәфисәнең бәхет өчен көрәше сызыклары аерыла. Әсәрнең төп темасы – тылдагы тормышны сугышка кадәрге дәрәҗәдә сакларга омтылыш. Романда яшьлекнең, хезмәт белән яшәүнең матурлыгы күрсәтелә. Кешедәге ил мәнфәгатьләрен өстен кую сыйфаты калкытып куела. Нәфисә образы ил анасы архетибы буларак билгеләнә. Инкыйлаб, аңа кадәрге һәм аннан соңгы вакыйгалар турында сөйләгән К.Нәҗминең "Язгы җилләр" (1948), Ф.Хөснинең "Җәяүле кеше сукмагы" (1958), И.Газинең "Онытылмас еллар" (1949-1966) романы сыйнфый көрәш темасын алга ала. Батырлык фәлсәфәсен тулы яктырту максатында татар язучылары биографик материалны сәнгатьчә югары дәрәҗәдә үзләштерергә омтылыш ясыйлар. Сугыш батыры Г.Гафиятуллин язмышы Г.Әпсәләмовның "Газинур"(1951), каһарман шагыйрь М.Жәлилнең һәм аның дусларыннан батырлыгы Ш.Маннурның "Муса" (1959-1964) романнарында гәүдәләнә.

Шулай итеп, Ватан сугышына багышланган әдәбиятта документ, тарихи факт, биографиянең әһәмияте арта бара, документаль юнәлеш көчәйгәннән-көчәя. Сугыш һәм сугыштан соңгы вакыйгаларны тасвирлаган М.Әмирнең “Ялантау кешеләре” (1954), “Саф күңел” (1959) романнары намуслылык темасын үткәрә. Һәр романда бәхет, әхлак темалары табыла. Бу чорда язылган әсәрләрдә төп кимчелек – идеология йогынтысында образларны уңайга-тискәрегә бүлеп сурәтләү. Геройлар сыйнфый (“Онытылмас еллар”), әхлакый (“Намус”, “Ялантау кешеләре”, “Саф күңел”) каршылыкка керәләр. Алар хезмәтләре, шәхси тормышлары, әхлакый сыйфатлар ягыннан сурәтләнә. Романнар реализм иҗат агымында языла. Бу дәвердә хезмәт темасын алга алып иҗат ителгән романнар белән беррәттән (А.Расихның “Дустым Мансур” (1955), И.Газинең “Гади кешеләр” (1955), Г.Әпсәләмовның “Сүнмәс утлар” (1958) һ.б.) күп кенә хикәя, повестьлар да ( А.Шамовның “Миңнур карт” (1946) хикәясе, Ф.Хөснинең “Җәй башы” (1950), “Авыл өстендә йолдызлар” (1954) повестьлары һ.б.) соцреализм куйган таләпләргә буйсына.

Шул ук чорда рус прозасында 1970-90 нчы еллар рус постмодерн әдәбиятына җирлек булдырган сугыш турындагы хикәя-повестьлар, аеруча «яңа дулкындагы» «окоп прозасы» яисә «лейтенант прозасы» башланып китә (бу дулкын рус прозасында Ю.Бондаревның «Батальоны просят огня» (1957) повесте белән башланып китә дип исәпләнә). 1940-50 еллар аралыгында иҗат ителгән А.Чаковский, К.Симоновларның сугыш манзарасын киң яктырткан романнарына сугыштан соңгы елларда кыска хикәя, повестьлар алмашка килә. Аларны билгеләүче төп стиль үзлекләре булып урын ягыннан вакыйга барган кыр, бер бүлем җир, тар окоп сурәтләнеше, катнашучы төсендә бер-ике герой килүе, әсәрләрнең истәлек формасында язылуы күрсәтелә. О.Богданова 50-60 нчы елларда язылган сугыш турындагы әсәрләрдә сугыш вакыйгаларының 20-30 нчы еллар белән бәйләнештә тасвирлана башлавын, хыянәт, дезертирлык, әсирлек кебек мәсьәләләрнең яңа яктан ачылуын да билгели, аларның нигезләрен тоталитар системаны фаш итү якларына нисбәтләү очракларын да әйтеп үтә. Шул рәвешле рус прозасы фашизмны совет системасы белән янәшә

куя башлый, сугышның күләгәдә калган якларын тасвирлап, постмодерн дәверенә аяк басу өчен алшартлар әзерли. В.Войновичның алдан Франциядә басылган (1975), 1988-1989 елларда гына Россиядә нәшер ителгән «Жизнь и необычайные приключения солдата Ивана Чонкина» романы моның ачык мисалы булып тора, дип нәтиҗә ясый әдәбият галиме.

Татар прозасында да охшаш юнәлеш күзәтелә. 1956 елда язылган Ф.Хөснинең “Малай белән солдат”, Ә.Еникинең “Кем җырлады?” хикәяләрендә яшәешне үлем ноктасыннан бәяләү омтылышы моңа дәлил булып тора. Димәк, ***икенче юнәлеш*** – сугыш чорында калыплаша башлаган юнәлешнең дәвамы. Әлеге юнәлеш ***Ф.Хөсни, Ә.Еники, М.Юныс хикәяләрендә*** куәтләнә.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Сугыштан соңгы дәвер прозасының беренче юнәлешендә

1) иҗат агымы:

2) тема:

2. Бу дәвердә кайсы жанр һәм нинди үзенчәлекләр белән үсеш кичерә?

**Әдәбият исемлеге.**

1. Гайнуллина Г.Р.1940-1980 еллар татар прозасы тарихы (тексттагы мәгънәләрне табу): Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Казан дәүләт университеты, 2009.– 100 б.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

## Лекция 2

**Аннотация.** Лекциядә сугыштан соңгы дәвер прозасында икенче юнәлеш – яшәеш фәлсәфәсе турындагы хикәя һәм повестьлар, аларда фәлсәфи мотивларның алга чыгуы, Ф.Хөснинең “Малай белән солдат” хикәясендә яшәү-үлем фәлсәфәсе гәүдәләнеше, М.Юныйсның “Безнең өй

өянкеләр астында иде…” әсәре жанры, сюжет структурасы, хикәяләүче образы, поэтика җәһәтеннән өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** хикәя, повесть, яшәү-үлем фәлсәфәсе, жанр, сюжет структурасы, хикәяләүче образы, поэтика.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**

1. Сугыштан соңгы дәвердә икенче юнәлеш – яшәеш фәлсәфәсе турындагы хикәя һәм повестьлар.
2. Сугыштан соңгы еллар татар хикәясендә фәлсәфи мотивларның алга чыгуы.
3. Ф.Хөснинең “Малай белән солдат” хикәясендә яшәү-үлем фәлсәфәсе гәүдәләнеше.

3. М.Юнысның “Безнең өй өянкеләр астында иде…” әсәре: жанры, сюжет структурасы, хикәяләүче образы, поэтикасы

Сугыштан соңгы елларда татар прозасының ***икенче юнәлеше*** – сугыш чорында калыплаша башлаган юнәлешнең дәвамы. Әлеге юнәлеш ***Ф.Хөсни, Ә.Еники, М.Юныс хикәяләрендә*** куәтләнә.

***Ф.Хөснинең“Малай белән солдат”(1956)*** хикәясе рухи таяныч эзләп юлга чыкканнар халәтен сөйләп бирә. Наил пространствосы белән башка – малайга билгесез чынбарлыкны урман-яшәеш аерып тора. Әти-таяныч - яшәеш хәрәкәткә килсен өчен кирәк рухи кыйбла. Кеше үзендәге рухи таянычны тормыш юлына аяк атлагач – күперне чыккач, каланча-хәбәр алгач, аның “тире толып кигән” юлдаш Галәви абзыйны очратып киңәшләшкәч, тимер юл – туры юлга баскач, калай түбәле кызыл станцияне үтеп, билгесез булганга куркыныч

(кар басып киткән кыр, куян белән тулган урман) чынбарлыкка чыккач таба. Рухи таяныч эзләү – кешене гел борчып, бимазалап торучы хакыйкать (әти урман артында мәңгелеккә калырга тиеш түгел). Үзең ясаган чаңгы – тормыш юлына япа-ялгыз басып юл ярып карау. Юлда очраган тәҗрибәле дус – синең киңәшчең, синең дөньяңа-рухыңа якын кеше (Мүкле-күл түгел, безнең авыл; син безгә кайтмыйсыңмыни) – рухи таяныч, кыйбла күрсәтүче, ярдәм итүче кебек кабул ителә. Наил зурларныкы кебек чаңгыга – зурларныкына охшаган үз дөньясына сөенә, бу ышаныч аны беркайчан да ташламаячак. ***Автор кеше тормыш юлын үзе сыза, рухи таяныч аның эчке потенциалында яши, ярдәм итүче игелекле кеше шул рухны*** (йолдызлы бүрек, бил каешы, шашка уены) ***бары кузгатып кына җибәрә ала, ди. Тормыш-яшәешнең "буран котырган", куркыныч янаган - "эт өргән" шомлы мизгелләрендә кешенең рухи халәте ышанычлы булса гына*** (җиделе лампа януы)***, ул сынауларны кичә ала, ятимләнеп-өметен җуеп калган чынбарлыктан җылы якты дулкынга көйләнә ала, ди әдип.*** Ана елавы – рухи таяныч эзләүче кешенең сызлануы кебек укыла.

1959-1964 елар аралыгында татар хикәяләрдә ***фәлсәфи теманың милли мотивлаштырылуы*** күзәтелә. Ә.Еникинең "Туган туфрак" (1959), М.Юнысның "Безнең өй өянкеләр астында иде" (1964) хикәяләре – ***сугыштан соңгы татар прозасының өченче яңа юнәлешен*** билгелиләр.

***М.Юнысның "Безнең өй өянкеләр астында иде…" (1964)*** әсәре жанры ягыннан новелла дип билгеләнә. Әсәр автор үзе катнашкан бер вакыйганы тасвирлау рәвешендә язылган. Ч.Хәбибуллина хикәянең биографик җирлеген билгеләп үтә: "...Автор вакыйгаларны үзгәртми-нитми генә бәян кылырга ниятли: карчык сөйләгәннәр сүзгә-сүз бирелә, очрашу урыны, вакыты, зиратта бергә булган диңгезченең әйткән сүзләре дә шул ук кала, бары карт мөһаҗирнең генә үлеме уйлап чыгарылган монда. Чынлыкта исә ул кораб офыкка күмелеп күздән югалганчы, сыгылган хәлдә причалга басып кала".

Вакыйгалар Габдрахман Бәкерович исеменнән сөйләнә. Габдрахман Рахманкулов – авторның күп әсәрләрендә даими кабатланып килүче үзенә

якынайтылган образ. Әсәрнең башлам өлешендә Рәсәй диңгезчеләренең Генуядагы атаклы Стальено зиратында Италия халык герое исемен яулаган Рязань тимерчесе Федор Полетаев каберенә мәҗбүри төстә чәчәк кую вакыйгасы бәян ителә. Новеллада автор үткәргән төп идея штурман Маркин исеменнән әйттерелә: “Кабер бизәү – кеше заты үлгәч тә кадерен югалтмый дигән сүз. Гуманизм кагыйдәсе җир йөзендә безгә кадәр яшәгән кешеләрне дә хөрмәтләргә куша. Адәм баласы исән чакта гына түгел, дөнья куйгач та бәясен югалтмый дигән сүз бу.” Композицион кабатлау алымы ярдәмендә идея кат-кат искәртелә, хикәянең лейтмотивы буларак кабул ителә. Галереядагы һәйкәл детальләренә салынган мәгънә ярдәмендә автор яшәү-үлем фәлсәфәсен ачарга тырыша. Беренче – чалгы күтәргән скелет – яшь кызны алырга килгән үлем образы аша автор мәңгелек агышында кеше гомеренең кыскалыгы турында әйтә һәм, фикерен дәвам итеп, фани дөньяда яшәү шарты буларак “киләчәкнең иминлек китерүенә ышаныч” кирәклеген искәртә.

Ваемсыз, гамьсез, “кул белән тотып карарлык нәрсәне генә сизә, аңлый торган” кочегар Тракка яшәү фәлсәфәсе аңлашылмый. Автор-хикәяләүче тыныч гомер сөрүгә омтылуның күзләрен курку баскан яшь кызга гына түгел, диңгездә батып үлгән яшь малайга һәм “күңелендә яшәү өмете, тереклекнең мәңгелегенә ышану” барлык кешеләргә дә хас сыйфат икәнлеген искәртә. Һәйкәлгә карап, М.Горькийның “Кыз һәм үлем” поэмасын язуы һәм постаменттагы Италия шагыйре Торквато Тассо сүзләре укучы тарафыннан яшәешнең чиклелеге турындагы фикерне көчәйтү алымы булып кабул ителә.

Новеллада шулай ук гомер буена Генуяның Гарбо исемле ярлылар кварталында вак-төяк иске-москы сатып, үзенә һәйкәл салдыру өчен акча җыйган, ләкин үз гомерендә акчаны туплап бетерә алмаган карчык сыны турында сүз бара. Автор, иминлек турындагы фикер белән бергә, үлемнең котылгысызлыгы, аны табигый кабул итәргә кирәклеге турында кабатлый. Рим папасы образы атап үтелү үлемне табигый дип кабул итүне дин фәлсәфәсенә нисбәтли. Бу өлештә автор, карчыкның ярлылыгы турында әйтеп, мәдәни-иҗтимагый мотивлашкан мәсьәләгә басым ясый.

Әсәрнең төенләнеш өлеше – Стальено зиратында татар карчыгы белән очрашу вакыйгасын карчыкка салынган һәйкәл детале әзерли. Автор ике карчык образын янәшә чагыштырып, төп проблемага фәлсәфи юнәлеш бирә. Зиратны сурәтләү, пейзаждагы таулар, моңсу кипарислар автор фикерен тирәнәйтеп, көчәйтеп җибәрә. Бередә улы Пьетроны югалткан ананың үксегән кебек ишетелгән, зират шартларында тагын да аяусыз, катырак яңгыраган тавышка каберләр тынлыгының каршы куелуы гасабилы, борчу-хәсрәтле яшәеш-көнитешнең бер мизгелдә туктап калуы һәм аның билгесезлеккә барып тоташуы кебек аңлана. Автор үлемнең котылгысызлыгы турындагы фикерләрен хикәяләүченең сызланулары аша укучыга публицистик яңгырашта да җиткерә.

Сюжет агышында грекча гына аңлый торган Пьетроның әбисе татар икәнлеге ачыклана. Бу – конфликтның көчәйгән урыны. Автор карчыкның хис-кичерешләрен сурәтли һәм шуның аша туган туфракны юксыну, җирсенү проблемасын куя. Әбинең фаҗигале язмышы төсендә инкыйлабтан соң сәүдәгәрләрне, урта хәлле игенчеләрне сөргенгә озату, туган илдән куу мәсьәләсе татар әдәбиятында беренче тапкыр күтәрелеп чыга. Туган туфрагыннан куылган гаилә фаҗигасе хикәядә милләт фаҗигасе булып яңгырый. Карчыкның портреты ярдәмендә автор милли проблеманың катлаулылыкларын көчәйтеп күрсәтүгә ирешә. Самара губернасы Бөгелмә өязе Карамалы авылыннан күчеп киткән карчык фаҗигасенең тирәнлеге психологик портрет ярдәмендә тирәнәйтелә, төгәлләштерелә. Икенче бер урында психологик портрет персонажның хисләрен көчәйтеп күрсәтү буларак кабатлана.

Әсәрдә туган туфрак образын үз эченә алучы әдәби детальләр булып пейзаж элементлары, авыл кешеләренең йола-гадәтләре тора. Туган җиреннән аерылган татар өянкеләрне, Ык тугаендагы ап-ак шомыртларны, бәләкләп кер чайкауны, Сабантуй, җыен, каз өмәләрен, өй юу гадәтләрен өзелеп сагына икән, моның сәбәбе җитди. Автор әсәр башында ук кеше яшәешенең шарты иминлек булу турында очраклы гына искәртми. Бу проблема илдә иминлек бетү мәсьәләсе белән бәйләнә.

Идеологиягә кизәнү буыннар арасындагы рухи бәйләнеш өзелү мәсьәләсенә алып чыга. Бу фикерне автор татар карчыгыннан әйттерә. Өянке образы – әсәрдә туган йорт, җир, татар җире символы булып яңгырый. Карчыкның хис-кичерешләре катламында автор бу әдәби детальне кабатлый, әсәрнең исеменә чыгара. Димәк, яшәешнең төп мәгънәсе – туган җирендә, үзенә, рухыңа якын кешеләр арасында, тыныч, имин гомер сөрү, үзеңнән соң милли хисен җуймаган, үткәннәргә ихтирамлы сәламәт, матур буын калдыру. Автор чит җирдә яшәү тормышның матурлыгын тоюны киметә, ә кайвакыт юкка да чыгара, аның мәгънәсез итә, дигән фикерне хикәяләүченең төш күрүе аша раслый.

Чишелештә татар карчыгының яшерен төстә корабка үтеп керүе һәм трюмда һәлак булуы яшәү-үлем фәлсәфәсен фаҗигале мисал белән төгәлләштерә. Иминлек, тынычлык булмаган илдә яшәү мәгънәсе җуела дигән фикер хикәядә ул чор идеологиясен инкяр итү дә булып яңгырый. Ч.Хәбибуллина фикеренчә, хикәядә кораб – китеп баручы өмет символы. Автор, әбинең сөякләре “бабаларыбыз яшәгән туган ил туфрагында – Кырымда ята” дип, мәдәни-иҗтимагый мәсьәләне милли яссылыкта хәл итә, әбинең каберен туганнары, кан-кардәшләре генә бизи ала дигән фикер укучыга җиткерелә.

“Безнең өй өянкеләр астында иде…” исемле новелла аша чит илләргә китәргә мәҗбүр ителгән кан кардәшләребез турындагы тыелган мәсьәлә алга алына. Бу хакта М.Юныс үзе болай сөйли: “Узган гасырның алтмышынчы елларында “татар” сүзен “Кырым” сүзе белән янәшә кую да партиянең һәм Совет хөкүмәтенең сәясәтенә, рәсми идеологиягә каршы баш күтәрү санала иде. Татарның Кырымнан сөрелгән чаклары. Бу җинаятьне искә алу тыелган. Карчыкның Кырымга – “туган җиренә” кайтарып күмелүе вакыйгасы белән киная аша булса да кырым татарларына карата булган геноцидны укучыга җиткерергә теләдем. Кырым татарларын искә алу ул чакта татар әдәбиятында юк иде әле. Фин татарлары соңрак: “шул хикәя аша татарларның безне онытмаганлыгын аңладык һәм хикәяне күз яшьләренә тыгылып укыдык”,– дип

сөйләделәр”. А.Хәлим «совет басымының иң әшәке елларында урыс һәм дөнья әдәбиятының прогрессив витаминнары белән азыкланып торган М.Юныс татар әдәбиятында үзенең сирәк каләмдәшләре белән гыйсьянчылык агымын тудыруга йөз тота һәм аны саклап кала алды» диюе белән хаклы.

Шул рәвешле, сугыштан соңгы татар прозасында соцреализм кысаларында язылган романнар белән янәшә 60-80 нче еллар татар прозасының төп үсеш юлларын билгеләгән милли фәлсәфәне алга алган хикәяләр дә пәйда була.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1.Сугыштан соңгы дәвердә икенче юнәлешне, шул юнәлешкә нисбәтле әдипләрне атагыз.

2. 1959-1964 еллар аралыгында татар хикәяләрендә  фәлсәфи теманың милли мотивлаштырылуы кайсы әсәрләрдә күзәтелә?

3. Сугыштан соңгы татар прозасында фәлсәфи хикәя жанры. Бу хикәягә нигезләнеп психологизмның аң агышы алымы турында сөйләргә.

**Әдәбият исемлеге**


1.Гайнуллина Г. Кереш сүз / Г.Р.Гайнуллина / Юнысов М.З. Әсәрләр / Миргазиян Юныс. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б.5-17.

2. Гайнуллина Г.Р. 1960-1980 еллар татар прозасы тарихы (II кисәк): Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Ихлас, 2012. – 80 б.

3. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

4. Мәһдиев М. Секстан белән йолдызлар үлчәргә /М.Мәһдиев  // Казан утлары – 1977.- № 5.- 148-152 б.

5. Миңнуллин Ф. Романга ни булды? / Ф.Миңнуллин / Миңнуллин Ф. Балта явызлар кулында: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. (Т.Галиуллин кереш сүзе). – Казан: Татар. кит.нәшр., 1994. – Б.87-96

6.Мостафин Р. Табышлар һәм югалтулар / Р.Мостафин // Казан утлары. – 1980. – №9. – 162-164 б.
7. Р.Рахмани Кыйблабызга тугрылык / Р.Рахмани / М.Юныс. Әсәрләр. Алты томда. I том. – “Рухият”, 2003. – Б.5-38
8.Хәлим А. Сагыну гамәле / А.Хәлим // Мәдәни җомга. – 1998, 9 гыйнвар.–9 б.

## Тема 7. Сугыштан соңгы татар прозасында документаль повесть жанры

**Лекция 1**

**Аннотация.** Лекциядә ХХ гасырның 50-60 нчы еллар татар әдәбиятында документаль прозаның үсеш алуының алшартлары, мемуар-автобиографик жанр калыплаша башлау, сугыш темасына нисбәтле мемуаристика өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** документаль проза, мемуар-автобиографик жанр.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**

1. ХХ гасырның 50-60 нчы еллар татар әдәбиятында документаль прозаның үсеш алуының алшартлары.
2. Мемуар-автобиографик жанр калыплаша башлау.
3. Сугыш темасына нисбәтле мемуаристика.

ХХ гасырның 50-60 нчы еллар татар әдәбиятында документаль прозаның үсеш алуы Ватан сугышыннан соң илдәге катлаулы вакыйгалар белән бәйле. 1941-1945 еллардагы сугышта җиңгәннән соң, 1937-1938 елгы фаҗига – Сталин репрессияләре янәдән колач җәя. Төрмә-лагерь газапларын кичергән, Ауропа илләрендәге тормыш-көнкүрешне үз күзләре белән күргән кичәге солдат илнең яшерен сәясәте барлыгын аңлый. Рәсми хакыйкать янында яшерен рәвештә кешеләр аңында чын хакыйкать яши башлый.

60 нчы елларга кадәрге әдәбиятта билгеле сәяси сәбәпләр аркасында чын хакыйкать яктыртылмый. Әдәбиятның төп темасы булып Ватан сугышы фаҗигасе тора. 1945 елдан соң хәрби-документаль материалларга нигезләнгән әсәрләр иҗат итүгә аерым игътибар бирелә.

Язучы Ф.Хөсни "Бер мәсьәлә тирәсендә" мәкаләсендә документаль юнәлешнең үсешен "бик вакытлы күренеш" дип билгели һәм аның сәбәпләрен түбәндәгечә аңлата: "Беренчедән, буыннар белән буыннар арасындагы багланышның тоташа баруы, бүгенге буынның яшәп киткән буыннар тәҗрибәсеннән үрнәк алырлык якларны үзенә күчерергә омтылышы гәүдәләнә монда. Икенчедән,... берәүдән дә яшерен түгел, берара аерым язучылар тарафыннан халыкка хезмәт дигән төшенчәне үтә дә шәрәләндереп аңлап, ялган пафоска, риторикага авышу фактлары да булмады түгел. Бу факт укучыларда яки аларның бер өлешендә әдәбияттан беркадәр суыну, аңа ышанып җитмичәрәк карауны китереп чыгарды. Шуның антитезасы рәвешендә укучы документаль материалга нигезләнеп язылган әдәбиятка ташланды. Хәрби полководецларның зур тиражлар белән чыгарылган мемуарларының тиз арада таралып бетүе шуны күрсәтә торган фактларның берсе түгелме соң! Аерым алганда, безнең татар әдәбиятында Гани Сафиуллин, Фатих Булатов кебек генералларның публицистик әсәрләре дә шундый ук бәхетле язмышка тап булды, дисәк тә хата түгел. Өченчедән, ә бусы иң әһәмиятлесе булса кирәк, халык үзенең тарихка эз салып киткән улларын онытырга теләми, аларны һәрдаим барлап тора һәм киләчәктә дә барлап торыр"

Бу елларда әдипләр үз әсәрләрендә тормыш фажигасенә әверелгән хакыйкать темасын ачуны да максат итеп куялар. Рус әдәбиятында шәхес культы фаҗигаләре яктыртыла башлады (Е.С.Гинзбургның "Текә маршрут", А.И.Солженицинның "Иван Денисовичның бер көне", "Гулаг архипелагы", А.Рыбаковның "Арбат балалары", А.Кестлерның "Сукырайткыч караңгылык", В.Шаламовның "Колыма хикәяләре" һ.б.)

Афәтне үз башларыннан кичергән Х.Туфан, И.Сәлахов кебек язучылар фаҗигане бөтен тулылыгында яктыртырга омтылыш ясыйлар. Алар үзләре

яшәгән заманны аңлап, үз күзләре белән күргән вакыйгаларга гадел бәя бирергә тырышалар. И.Сәлаховның 1957 елда язылa башлаган “Колыма хикәяләре” роман-хроникасы шәхес һәм ил фаҗигасен гаять эчтәлекле, документаль төгәллек белән тасвирлауга омтылыш булып тора.

Шул рәвешле, 60 нчы елларга ил сәясәтендә, шуның белән беррәттән әдәбият мәйданындагы үзгәрешләрнең күпчелеге И.Сталинның үлеме белән бәйле. Шәхес культы тиешле бәясен алганнан соң, сәяси тоткыннарның күбесе гаепсез дип табыла. Шуңа карамастан рәсми хакыйкатьтә җитди үзгәрешләр күзәтелми. Илнең зыялылары, фән эшлеклеләре, үз хезмәтләрен намуслы башкаручы  зур төркем кешеләр ямьсез юллар белән эзәрлекләнә. Чор сәясәте ифрат каршылыклы, бер яктан, кичәге тоткыннар чын хакыйкатьне ачу мөмкинлеге алалар, бу максатка бөтен көчләрен, егәрләрен багышлыйлар. Икенче яктан, идеологиягә каршы чыгучы һәркем төрле ысуллар белән халыктан читләштерелә, юк ителә.

Шул рәвешле, бу дәвер әдәбиятында хаклык, хакыйкать темасының иң актуаль тема булып торуы очраклы түгел. Хаклыкны ачыктан-ачык сөйләргә ярамаган бу елларда да әдипләр үз сүзләрен әйтергә жаен таптылар. Идеологиягә каршы чыгу булмаса да, аны кабатлаудан качу юлларының  берсе-үткән заман вакыйгаларын язу иде. Әлеге шартлар язучыларның документаль жанрга мөрәҗәгать итүләренә сәбәпче булды. Мисалга, Н. Дәүлинең “Яшәү белән үлем арасында”(1957) повесте –документаль характердагы повесть үрнәге.

Татар әдәбиятында сугыш темасын мемуар жанрга салып яңа күзлектән сурәтләгән зур күләмле әсәрләр арасында  –  Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» повесте иң тәүгеләр рәтенә керә. НДәүлинең нәкъ шушы әсәре белән татар прозасында Бөек Ватан сугышының яңа материалын үзләштерү, сугышның әле моңа кадәр яктыртылмаган якларын чагылдыру башлана. “Яшәү белән үлем арасында” повестеның журнал варианты – 1957 елда “Совет әдәбияты” журналында (№ 6,7,8)  чыккан беренче басмасы киң катлам укучыга “Тормыш белән үлем арасында” дип тәкъдим ителә. Повестьны 1958 елда

аерым китап итеп чыгарганда автор аның исемен үзгәртә. "Яшәү белән үлем арасында" мемуаристик повесть-хатирәдә яшәү һәм үлем фәлсәфәсе сюжет, композиция, хронотоп, образлар бирелешендә ачыла.Автор-хикәяләүченең субъектив хронотобы аның тоткын дусларына, шулай ук фашистларга, яшәү һәм үлемгә мөнәсәбәте үзенчәлекләрен ача. Повестьта яшәү һәм үлем фәлсәфәсе үзәктә тора. Ул "яшәү", "үлем","үлемсезлек" төшенчәләренең үзара бәйләнешләре нәтиҗәсендә туа. Әдипяшәешне ике чиккә аерып, яшәү үлем каршылыгын ача. Яшәүгәмөнәсәбәтле берничә фәлсәфи мотив аерып билгеләнә ала. Беренчесе яшәү - киләчәккә өмет баглауда, ирекkә чыгасына ышануда, үз-үзеңне раслап алга баруда дигән фикер белән бәйле. Бу юлларда яшәү – көрәш дигән фикер калкып чыга. Икенче мотив азатлыкка, ирекkә, туган илгә омтылыш яшәүне тәэмин итә дигән фикер аша уздырыла. Яшәүгә мөнәсәбәтле сүзләр яшәү бәхетенең туган илне, туган якны чиксез яратуда, туган илгә мәхәббәттә икәнлеген әйтү белән тәмамлана. Повестьта үлемне котылгысыз күренеш дип аңлаудан кешене тоткынлык газабыннан азат итү мөмкинлеге дип аңлауга кадәр үстерелә. Кешенең көче, горурлыгы сыналу чорында да, җиңелгәндә һәм үлем каршында да куәтле яңгырашка ия булырга тиеш дигән фикер кабатлана. Икенче яктан үлем – әсир исемен аклау ноктасы.

Бу дәвердә документаль повесть жанрының мемуар-автобиографик дип исемләнгән канаты калыплаша башлый. 60-80 елларда бу жанрда Фатих Хөснинең “Минем тәрәзәләрем” (1962-1964), Ибраһим Газинең “Малайлыкта кунакта” (1966), Гомәр Бәшировның “Туган ягым-яшел бишек” (1965-1968), Рафаил Төхфәтуллинның “Җиләкле аланнар” (1969), Салих Батталның “Баштан үткәннәр” (1972), Шәйхи Маннурның “Агымсуларга карап” (1970-1973), Мирсәй Әмирнең “Без бәләкәй чакларда”, “Үсә төшкәч”, “Казан” (1978-1979), Ә.Еникинең “Соңгы китап” (1981) повестьлары языла.

**Сораулар һәм биремнәр.**

XX гасырның 50-60 нчы еллар татар әдәбиятында документаль прозаның үсеш алуының алшартларын атагыз.

1. Мемуар-автобиографик жанр калыплаша башлау (Г.Бәширов, Ш.Маннур, М.Әмир, Р.Төхфәтуллин, Ә.Еники һ.б.)
2. Сугыш темасына нисбәтле мемуаристиканың үзенчәлекләре.

**Әдәбият исемлеге.**


1. Гайнуллина Г.Р. 1960-1980 еллар татар прозасы тарихы (II кисәк): Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Ихлас, 2012. – 80 б.

2. XX гасырның 60-70- нче елларында татар автобиографик прозасы үсеше. Монография. – Казан: Ихлас, 2012. – 104 б.

3. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

4. Юзиев Н. Проза / Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.5: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989.– Б.297-324.


## Тема 8. Сугыштан соңгы повестьларда тәнкыйди катлам.

**Лекция 1**

**Аннотация.** Лекциядә XX гасырның 50-60 нчы еллар татар әдәбиятында тәнкыйди прозаның үсеш алуы, Ә.Еникинең “Рәшә” повестенең сюжет структурасы, символлар аша аңланган эчтәлек өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** тәнкыйди проза, сюжет структурасы, символлар аша аңланган эчтәлек.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың

үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**

1. XX гасырның 50-60 нчы еллар татар әдәбиятында тәнкыйди прозаның үсеш алуы.
2. Ә.Еникинең “Рәшә” повестеның сюжет структурасы, символлар аша аңланган эчтәлек.

XX гасырның 50-60 нчы еллар татар әдәбиятында тәнкыйди прозаның үсеш алуы Ә.Еники, А.Гыйләҗев исемнәре белән бәйле. Ә.Еникинең “Саз чәчәге” (1955-1957) повесте киң җәмәгатьчелектә шактый төрле фикерләр, кызыклы бәхәсләр уята. Берничә елдан соң 1962 елда А.Гыйләҗевның “Өч аршын җир”, Ә.Еникинең “Рәшә” повестьлары язылу татар прозасының торгынлык чорына нокта куелу турында хәбәр итә.

***Ә.Еникинең “Рәшә” повестена (1962)*** карата язылу-басылу дәвереннән башлап һәм әдәбият белгечләре, һәм тәнкыйтьчеләр әледән-әле мөрәҗәгать итә. 1964 елгы мәкаләсендә Ф.Миңнуллин болай яза: “Әмирхан Еники әсәрләре безнең тәнкыйтькә кызу бәхәсләр, капма-каршы фикерләр кузгатып килде. Аның фикеренчә, “Рәшә” – Зөфәрләр турындагы повесть.

Ә.Еники үзе Зөфәр Сабитовны Сез кайдан, ничек табып алдыгыз? дигән сорауга болай җавап бирә: “Зөфәр Сабитовны табуы читен булмады. Алар бар иде һәм хәзер дә беткәннәре юк, минемчә. Ләкин Зөфәр кебек кешеләр бары сәүдә-тәэминат тирәсендә генә йөриләр дип уйламаска кирәк... Хикмәт бит профессиядә түгел, ә кешенең фәлсәфәсендә...”

Повесть тирәсендә 60 нчы елларда барган бәхәсләр “норматив тәнкыйть тарафдарлары һәм иҗади тәнкыйть вәкилләре арасындагы фикер һәм караш аермалыклары”[ формасын ала. “Задача Амирхана Еникеева – не просто разоблачить жулика и тунеядца, ловко скрывающего свое истинное лицо. Он ненавязчиво, с терпеливой обстоятельностью вскрывает истоки эгоистической

философии сабитовых и выносит им бескомпромиссный приговор . Повестьта “чын совет кешесе образын” эзләүче К.Фасеев Р.Мостафинга җавабында болай яза: “Получилось не разоблачение, не “вынесение приговора”, а искуственное раздувание темных, мрачных сторон жизни и морально уродливых персонажей, отсуствие образов, олицетворяющих цвет нашего общества, определяющих сущность социалистических отношений.

Повестьта вакыйгалар вакыты 1945 елның тугызынчы мае дип тарихи билгеләнеш ала. Хикәяләүче укучыга Бөек җиңү иртәсендә “уяныргга” тиешле Зөфәр Сабитовны тәкъдим итә. Геройны эчке халәтен сөйләп бирү өчен кулланылган төш алымы белән автор укучыны сюжетка керергә әзерли. Геройның ят бер дала буйлап ялгызы каядыр китеп баруы аның күңел кичерешләренең үзе өчен таныш булмаган билгесезлек халәтенә керүен хәбәр итә. Укучы Зөфәр күңелендәге битарафлык, гамьсезлек халәтенең аның даими халәте икәнлеген аңлый: “Дала буш, дала тын, үзе тип-тигез, очсыз-кырыйсыз”. Бу хиссезлек шулкадәр озакка сузылган ки (“үләннәре саргаеп кипкән”), хәтта кеше тормышында үзгәреш китерә алырлык кичерешләрнең нигезе юк (“кара туфрагы, чатнаган чуендай, яргаланып беткән”). Геройның тормышында аңа таныш түгел башка хакыйкать белән очрашу әзерләнә: “ Бик эссе, бик коры, төпсез күктән кызган тимердәй ап-ак кояш аның күзенә туры карый...” Укучы Зөфәр күңелендә туган ят халәтнең аңлатылышын таба: ирне **үзгә чынбарлык белән очрашу котылгысызлыгы борчый** икән ( тере кояш... берөзлексез яндыра, көйдерә, имеш. Шул ук вакытта ул бу халәтеннән (“котсыз дала”) котылуны тизләтергә ашыга: “Кая бара ул, мәгърипкәме, мәшрикъкәме – ачык кына белми дә, имеш, ләкин барырга кирәк, бармыйча ярамый, чөнки монда туктап калу һич мөмкин түгел”. Хикәяләүче бу урында аның ялгыз гына чыгып китүенең сәбәбен үз бәхетен табу омтылышы белән бәйли, Зөфәрнең үз фикер-халәте буларак җиткерә. Шул урында авторның һәркем үз бәхетенә юлны үзе эзли һәм таба дигән карашы укыла: “Һәм берәүгә дә әйтмичә, берәүне дә ияртмичә ялгызы гына чыгып китүе дә бары шуның өчен генә, имеш”.

Хикәяләүче укучы Зөфәр халәтендәге әлеге үзгәрешнең инде озак вакытлар әзерләнеп килүен кояш образының эчтәлегенә салып сөйли. Зөфәр әлеге үзгә чынбарлыкны таный ( ул аңа “юлдашка эт шикелле ияргән гамьсез кояш” кебек), ул хәтта шул пространствода хәрәкәт итмәсә дә, гамәл кыла, гамьсез генә яши дип бирә : “Баштарак аңа тигез дала буйлап атлавы бер дә күңелсез, авыр булып тоелмады. Киресенчә, бу иркенлектә, бу тынлыкта бару рәхәт тә кебек иде”. **Гамьсезлек – кешенең матур хисләрен үле хәлгә китерергә сәләтле халәт**, тора-бара ул шом тудыра, ди автор Зөфәр сайлаган юлның дәвамын тасвирлап (“Ләкин тора-бара очы-кырые күренмәгән үлек дала аны борчый, шомландыра башлады”). Хакыйкатьне кабул итәргә Зөфәр әлегә әзер түгел. Үзе битараф булган булган чынбарлыкның тик торганда күңелен борчый башлавы Зөфәрне нәфрәтләнергә мәҗбүр итә: “Тагын шоп-шома күктән шым гына ияреп барган “юлдашы да” бик мәкерле, явыз булып чыкты. Хәзер ул Зөфәрнең нәкъ менә баш түбәсен кыздыра, шундый кыздыра, әйтерсең, юри кайнатып чыгарырга тырыша...”. Автор ирнең чарасызлык хәлендә калуын - сусавын тасвирлый: “ Атлаган саен көчәя барган бу сусауга һич кенә дә түзәрлек түгел иде, коточкыч авыр иде, чатнап кара янган иреннәре бертуктаусыз: “Су... су... су... !” – дип үзлегеннән кыймылдый иде”. Димәк, яшәү символы кебек укылган су элементы ярдәмендә автор Зөфәрдә туган яңа омтылышны – башкача яшисе килү теләген тасвирлап бирә. Күл – “шашарга җиткән” Зөфәр каршында пәйда булган, ул теләп чакырган яңа чынбарлык гәүдәләнеше: “ ... кинәт җем-җем уйнаклап яткан түп-түгәрәк, зур бер күл ачылды... Бу шулкадәр чын иде, шулкадәр якын иде, гүя менә суның йомшак дымы аның йөзенә килеп тигәндәй булды.” Биредә автор гел тәкъдим итеп килгән яшәү фәлсәфәсе укыла: **өметсезлек алдында калган кешегә тормыш-яшәеш һәрчак үзгәрү, дөрес юлга чыгу мөмкинлеге бирә.** Хикәяләүче ирнең бу чынбарлыкка сусаган, аңа кабул итәргә әзер икәнлеген психологик портрет алымы аша көчәйтә (чатнап кара көйгән иреннәре, томаланган, шашарга җиткән күзләре, салкын суны көлә-көлә, елый-елый эчәргә теләве). Өмет/өметсезлек чиген үтәргә әзер ир өчен **идеаль чынбарлык - үз, якын** ( “күл бик якын

кебек иде”), **торган саен матурая баручы** (“тигез җирдән үк башланып киткән сай читләре агарып, ә эчтәрәк, тирәнрәк урыннары зәңгәрләнеп тора кебек”), **ләкин иң матур серләрен тирән яшергән “сихри дөнья”** (“Тик аның аргы чите генә ачык күренми; анда биек камышлармы, текә ярлармы бар кебек, ләкин алар барысы да күз үтә алмаслык күгелҗем томан белән өретелгән иде”).

**Кешегә табигать тарафыннан идеаль чынбарлыкны кору мөмкинлеге бирелгән, көч салынган, ләкин әлеге потенциалны эшкә җигәргә комачалаучы җимергеч көч тә бар**, дип автор сүзне сюжет сызыгына бора, укучы күңеленә урнашырга тиешле хакыйкатьләрне раслый. Биредә өн/төш оппозициясе төп геройга мөнәсәбәтле чынбарлык/хыял, идеаль каршылыгы кебек оеша, укучы Таибә абыстай образына салынган эчтәлекне табуга вакыйгаларны “алдан укый”: “Төш кинәт өзелде, Зөфәр сискәнеп күзен ачып җибәрде. Бу ни хикмәт, кем болай дөнья җимерә? Ул ни дә булса уйлап өлгергәнче, залда яткан әнисе Таибә абыстай торып тәрәзәгә барган иде инде.” Шул рәвешле хикәяләүче Зөфәрнең “илаһи белән сөйләшүендә” Таибә абыстай юлын дәвам итәчәген алдан сиздереп куя. Әни кешегә бәя бирү өчен җиңү иртәсенә абыстайның карашы җиткерелә: “...Тордылар да бәреләсугыла чыгып чаптылар. Күк капусы ачылганмыни, - диде Таибә абыстай, азрак сукранып...”

Билгеле, ана шартын китереп улы каршында абыстайлыгын мондый очракта гадәти әйтелә торган сүзләр белән раслап куярга да онытмый: “Йа рабби мәүләм, бу көннәрне дә күрергә насыйп иттең, рәхмәтеңнән ташламадың бәндәләреңне...”

Укучы Зөфәр Сабитов белән шулай таныша. Зөфәрнең җиңү бәйрәменә сөенүен аның сугыш башланганнан бирле “сәүдә кешесе, сәүдә бүлегенең мөдире” булуы билгели , “бу көнне көтеп складларда саклап тоткан” азык-төлекне чыгарыр вакыт җитте бит, “сәүдә точкаларына шалтырата башлауга” “ бәйрәм настроениесе гүя тышта торып кала”. Шунда ук ул сайлаган кием укучыны үз эчендә каршылык яткан яңа эчтәлекне кабул итәргә әзерли: “Эшкә барса да, бәйрәмчә булсын дип, чиккән якалы ак күлмәген, элүдә генә торган соры костюмын, җәйге туфлиләрен киде. Барысы бер төстән, бер иштән

диярлек, тик менә зәңгәр кепкасы гына күренешне боза иде. Ярый инде, баштанаяк бертөследән киенер вакытлар алда әле...” Зөфәр күңеле белән нидер көтә. Ләкин үз рухы, җаны белән бәйле түгел, күбрәк тышкы дөнья белән бәйле үзгәрешләргә өметләнә.

Укучы Зөфәр дөньясының икегә – үзенеке һәм “капкадан чыкканнан” соңгыга бүленгәнен аңлый. Шул рәвешле чит/үз бинар оппозициясе Зөфәр чынбарлыгының асылын билгели. Зөфәр ягымлы матур сеңлесе Хөршидне ярата, Зариф абыйсын, аның хатыны Сәкинә җиңгине якын итә. Хикәяләүче Зөфәрне бәйрәм иртәсендә “капкадан чыккач” якын кешеләре белән очраштыра. “Сыңар кулы белән кочып алып” абый кеше сеңлесенә карата күңеленең бер өлешендә яшәгән кайгыртучанлыгын сиздерә. “Хатыннар уртасында иңенә шәлен салып, башын кагып басып торучы”, ире Зарифның исән кайтуын ышанып көтүдән “йөзе тәмам нурланып, алсуланып киткән” Сәкинә җиңгине ихтирам итүен хикәяләүче Зөфәр теле белән сөйли. Чит дөнья дип билгеләнгән башкалар дөньясына ирнең мөнәсәбәте ачык: “бүгенге көннән ул берәүдән дә шүрләмичә, һәркемнең йөзенә туры карап йөри алачак”. Димәк, Зөфәрнең күңел халәтен билгеләү өчен кирәк булган эчтәлек табыла. Укучы ирнең башкалар дөньясыннан “шүрләвен”, үзенекләрне ихлас кайгыртуын белә. Куркуның сәбәбе – “бөтен кеше тегендә, ут эчендә, ә ул тап-таза килеш монда йөргәнгә” “башкаларның ят итеп, дошман итеп караулары”. Кешеләр “кыю, бәйсез” кулсыз майор Симаковны якын итә, “мәтәлдереп чөя”, “аңа авып китә”. Зөфәрдәге курку аны әлеге “кулсыз”ларны үз итә торган чит тирәлек белән сак булырга өнди, ул үзенә (киеменә) төс булмаган  “зәңгәр кепкасын күтәрә төшеп, баш иеп узуны” мәслихәт күрә яисә “кулсыз майор белән очрашуларны яратмаганга” (дөресе,  кирәк санамаганга), әйләнеп уза.  Кабатлау композицион принцибы  ярдәмендә хикәяләүче Зөфәр Сабитов “түбәнчелек белән кулын сузган” чынбарлык турында әйтеп уза. Ләкин әлеге чынбарлык  аның өчен әлегә ышанычлы түгел. “Таза гәүдәсенә иркен кара пальто, башына яхшы хәрби фуражка кигән завод директоры” “кулын бирсә дә”, Зөфәргә “тиешле” игътибар күрсәтми: “Менә директор да аның белән рәсми коры гына исәнләшкән булды.

Ә бит ул Зөфәрсез – сыңар кулсыз!” – дип ризасызлык белдерә заводның эшчеләр тәэминаты бүлеге идарәсендә “үз исәбе” булган Сабитов.

Укучы Зөфәрдәге куркуның тирән кереп оялаганын аның кичерешләрен күзәткәндә ачачак. Хикәяләүче “кешегә ияреп кабынырга, очынырга, ...экстазга бирелеп китәргә яратмый торган, хиссият мәсъәләсендә дә үлчәү-чаманы” белә торган Зөфәр теле белән кешедәге чын шатлык хисен сурәтләп, аны башка кичерешләр дулкынына күчерә: “... зур урамга чыккач, Зөфәр тагы да ныграк гаҗәпләнә калды... Бу чыннан да халыкның бернинди чакырусыз, өндәүсез, үзеннән-үзе туган, шуңа күрә сафларга тезелмәгән шатлык демонстрациясе иде”. Биредә “сафларга теземәгән шатлык” детале Ә.Еникинең яшәп килүче идеологиягә карашын тамгалый. Әдип идеологиянең “кулдан язган лозунглар, юлбашчыларның май демонстрациясеннән калган портретларын күтәргән” халыкның аңына үтеп кергән чынбарлык булуына борчылуын сиздерә.

Халык агымына иярүне тиеш тапкан Зөфәргә ихлас сөенә белү хәләте ят: ир “бу мәхшәрдән тизрәк ычкынырга теләде”. Шул халәттә автор Зөфәрне үзгә дөнья – бик үз дә, шул ук вакытта чит итү дөресрәк тоелган Рәшидә белән очраштыра. Укучы Зөфәрне ихлас яратучы икенче бер “балаларча чын гаҗәпләнә белә торган” беркатлы чынбарлыкның “егетнең муенынннан кочып алуын” аңлый. Биредә автор уртак саналган шатлыкка ике капма-каршы мөнәсәбәтне тасвирлый. “Бәхетеннән бөтенләй онытылган” Рәшидәне әлеге олы шатлык үз гамәлен тагын да җаваплырак башкарырга канатландыра (“без бүген халыкка җырлап йөрибез”), ә “үзенә артык рәхимле, юмарт булып чыккан” – “башын да аяган, малын да биргән, өстәвенә сөйгән ярлы да иткән” тормыш бетү бәйрәмен күңеле аша үткәрә алмаган “акыллы” Зөфәр өчен бу - түбән хисләр уятучы “мәхшәр” генә (“Көне, көне – шатлыгын, мәхәббәтен, рәхәтен дигәндәй, икәүдән-икәү генә татый торган көн ич бу!..”). Зөфәрнең “бәйсез, иркен, мул” булырга тиешле киләчәк тормышына мөнәсәбәте ачыклана: аны “...акчаны малга әйләндерү ягъни йортмы-квартирамы сатып алу; ... аңа терәк һәм теләктәш булырлык әйбәт кенә кызга өйләнү” борчый.

Кыскасы, анының максаты - үз чынбарлыгын сакларлык тыл булдыру. Шул рәвешле **укучы күңеленә курку хисе кешедәге иң матур тойгыларны җимерә алучы, аны түбән тойгыларга таба боручы көч,** дигән **хакыйкать** урнаша.

Икенче бүлектә хикәяләүче укучыны яңа яшәешкә – серле-сихри Рәшидә Сафина дөньясына алып керә. Сөйләү Зөфәрнең бу хакта искә төшерүе кебек оештырыла. Вакыйгалар башланган вакыт 1943 нче елның үтә салкын январь ахырлары дип тарихи вакыт буларак тамгалана. Зөфәр-Рәшидә очрашуын кабул итәргә әзер укучыга Зөфәрнең “салкын, караңгы, котсыз, буш” пространствода - вокзал эчендә очраткан дүрт кешегә мөнәсәбәте инде гайре табигый тоелмый. “Яхшы пальто, күн түбәле каракүл бүрек, эт тиресеннән озын кунычлы унты кигән һәм бер беләгенә зәңгәр тышлы бәрән толыбын салып, икеннче кулына кара чемодан тоткан, бик тук кыяфәтле, таза егетнең” “өсләре бик чуар, бик иләмсез”, тәпән шикелле юан, сырган чалбарлы, киез итекле, кайсы шәл уранган, кайсы малахай бүре кигән бу кешеләрне чит итүе – “нәфрәтләнеп кул селтәве” укучыга гаҗәп түгел. Берсе түгәрәк, икенчесе какча битле кызларның балаларча беркатлылыгы һәм аларның “башында эче-тышы мех малахай бүрек, өстендә калын тышлы, сырган эчле, каракүл якалы пальто, аягында зур соры итек кигән, бүрегенең колакларын төшереп бәйләгән, якасын торгызган, билен тар каеш белән ныгытып буган” хуҗаларының дәртле-көчле булырга тырышуы “бер читтәрәк торган” Зөфәрне аптырашта калдыра. Автор бик төрле кешеләрне берләштергән яктылык, матур тойгылар читтән күзәтеп, шүрләп яшәргә күнеккән кешеләргә ят икәнлеген кабатлый. Буш пространствода очрашкан “кием-салымнары таза гына” әлеге ике ирне: “Юк, бирешмибез әле!” – дигән ышану берләштерә. Ләкин Яруллин бу халәткә кешеләргә якты мөнәсәбәт аша ирешсә, Сабитов исә кешеләрдән качу, саклану юлын өмет китерә дип саный. Ләкин Зөфәрнең ямьсез, катып калган, гамьсез, үзгәрергә теләмәгән чынбарлыгының сурәте кебек кабул ителгән “шадраланып тайгак-шома, пычрак кар каткан” бусагалы, “ярыкларына бәс утырган” тупсалы пространствоның юньләп ябылмый торган зур ишеге артында очраган дүрт

кешеле пространствоны хикәяләүче бер якка бора. Турайга бару турында һәркем кабатласа да, егет “кечкенә коңгырт күзле, олырак, озынрак, өс-башы пөхтәрәк” Рәшидәне генә “ишетә”: “ Зөфәр бер мизгел аңардан күзләрен ала алмыйча торды. Әллә ничек менә, кызның бер үк вакытта диярлек бик туры-җитди каравы һәм матур-сөйкемле итеп елмаюы аны гаҗәпләнеп югалып калырга мәҗбүр итте”. Зөфәр Рәшидәнең “беренче караштан ук бик самими һәм бик табигый тоелган” дөньясын  үз итә. Монысы укучы өчен беркадәр яңа эчтәлек. Зөфәр кебек кешеләрдә иң кимендә кызгану катыш көлке хисе уятырга тиешле чынбарлык матур дип бәяләнә, якын ителә. Димәк, **күңеленә курку хисе кереп оялаган кешеләр асылда үзләрендәге бу хисне күралмый, аның табигый түгеллеген белә, хөрлеккә, бәйсезлеккә ирешү юлларын эзли.** Зөфәр сайлаган “**матди һәм рухи бәйсезлек**” юлын **автор яклый**. Ләкин **күңелендә  курку хисе йөрткәннәр  матди һәм рухи бәйсезлеккә ирешә алмый, үзләре туплаган малның колына әверелә, дигән хакыйкатьне җиткерә.**

Хикәяләүче Зөфәргә “ат табу вазифасын” йөкли, аның мөмкинлеге бар, ди. Хәрәкәт асылда Зөфәр күңелендә, аның чынбарлыгында булырга тиеш. Автор Рәшидә исеменнән **кешегә үзгәрер, дөрес юлга чыгар өчен бирелгән мөмкинлек турында кабатлап әйтә**: “Сез табарсыз, әгәр теләсәгез”. Рәшидә образына салынган матурлык эчтәлеге авторның фикерләре кебек кабул ителә. Кызның беркадәр катгый, көтелмәгән, шул ук вакытта үтә дә гади сүзләреннән гаҗәпкә калган, уйланырга мәҗбүр булган Зөфәрнең беренче уе гадәти: “...кирәк микән болар белән юлдаш булырга? Үзе дә аңлап җитмичә, нәрсәдәндер, ни өчендер бераз гына шүрли кебек..”  Янында торган күшегеп беткән җаннарга караш ташлап, Рәшидә биргән кыюлыкны, ышанычны тотып алып, **ир кеше борыла, үз юлына чыга**: “Әйдә, миннән бер изгелек булсын! Эш белән йөриләр ич, мескеннәр!.. Һәм аңарда кинәт гаҗәеп бер энергия, кыюлык уянган кебек булды.” Димәк, **кеше үзенә салынган көч,  энергия, кыюлыкны изгелек  юлына чыккач таба.**

Хикәяләүче Зөфәр күңелендә башкалар турында ихлас кайгырту хисе тудырган үзгәрешне пространство алышынуы белән дә тамгалый: “...Киң, буш урамнан салкын карны шыгырдатып атлый-атлый, Зөфәр вокзалда көтеп калган артистлар турында уйлап барды”. Ир әлегә аларның “җыр кайгысы” белән йөрүләрен бәяли алмый, укучы ашыгып нәтиҗә ясарга тиеш түгел. “Сыкрау-сыктануны” белмәгән кешеләрне аңлавы - изгелекнең башы. Димәк, **изгелек үзең кебек түгелләрне аңлаудан башлана**, ди автор.

Иң үкенечлесе - юлга чыкканда ике ат таба алган Зөфәр гадәтләнгән яшәеш тәртибен үзгәртә алмаячак, борылачак. Повесть үзләрендә изгелек юлына чыгарлык көч тапканнан соң аңардан аңлы рәвештә баш тартканнарның фаҗигасе турында. Хикәяләүче сөйләмне шул дулкынга көйли. “Берсе җиңел кошевка, икенчесе киң үрәчәле чана” ирне яңа хисләр дөньясына алып бара. Артлы чанада ул Рәшидә янында шул чынбарлык тудырган җылылыкка сихерләнеп, аны югалтмас өчен бар көчен куеп тырышып бара (“аның өчен борчылып, әледән-әле башын сузып, алга карый”). Укучы төш эчтәлегенә кертелгән күл образына бәйле таныш текстны укый: “Бик якын, янәшә генә бит!.. Бу тою аңа тансык, рәхәт, ул аны гүя эчтән җылыта һәм кызга отыры якынайта кебек...” Ләкин аңын томалаган курку хисе күңелен “җилбегәй ачып җибәрергә” мөмкинлек калдырмый (көне буе “валчык та капмаган” артистларга “валчыгы да калмаячак” дип чемоданындагы ризыгын чыгармый), әлеге хис ирне гел сыный, богауда тота - “астыртын суык битне-борынны өшетеп ташлар дип курка” .

Зөфәр торган саен үз итәчәк чынбарлыктагы күңел җылысын автор детальләп тасвирлый (кунакларны каршы алырга тәрәзәсе сап-сары Гыйззәт картларның йорты, кара-каршы салынган өйләр).

Өченче бүлек Зөфәрдәге хисләрнең гоумәһәмиятлелеген раслап килү өчен аерып куела. Пространство бирелешенә (“клуб дигәннәре урамга кырынрак утырган, манарасы киселгән иске мәчет бинасы”) автор яшәп килүче идеологиянең Зөфәрләр фаҗигасе өчен җаваплылыгы эчтәлеген сала, проблема иҗтимагый ясылыкка күчерелә.

Гыйззәт картның болдырлы өе белән чагыштырмача бирелгән болдырсыз клуб ике дөнья - күңелендә бабаларыбыздан килгән җылылык хисен йөртүче кайгыртучан кешеләр һәм саксыз кагылып юкка чыгарырга әзер торган миһербансыз чынбарлык бирелеше кебек укыла. Күңелләрдә сакланган җылы шулкадәр көчле ки, иң рәхимсез чынбарлык та аны сүндерә алмый - "бозланып каткан кечкенә тәрәзәләрдә зәгыйфь яктылык, сары тап булып, тонык кына чагыла", "түрдәге тәбәнәк кенә сәхнәнең нәкъ алдында бердәнбер асылмалы калай лампа яна". Шул яктылык берләштерә, хәсрәтне киметә, шатлыкны зур итә, тормышны гамьле итә. Кешеләрнең артист чыгыш ясаганнан соң кул чапмаулары шул гамьне тою белән бәйле.

Авыл көе тексты – кешеләр өчен уртак булган хәсрәт хисе бирелеше. **Әлеге чынбарлык белән килешергә теләмәгән, ләкин килешергә мәҗбүр һәм яшәү тәртибен җайга салырга омтылганнар хәсрәте** гомумәһәмиятлелек төсен ала: "Җыр бетте. Караңгыда утырган халык бер мизгел тып-тын булып торды. Әйтерсең алар хыяллары белән бу иске мәчет эченнән бик еракка иң кадерле якыннарын, өметләрен, бәхетләрен эзләп киткәннәр иде. Һәм гүя әнә шул ерактагы фронтның карлы далаларына, бозлы сазлыкларына, кара урманнарына барып тапкан, кавышкан газиз якыннарыннан аерыла алмыйча, кире бу салкын ялгызлыкка кайтырга кодрәтләре җитмичә утыралар иде. ...Әйе, мондый хәлдә ду килеп кул чабу мөмкин дә түгел иде".

Җыр текстының эчтәлеге төрле халык биюләре детале аша кабатлана. Автор бу хиснең барлык кешеләр өчен уртак булуына басым ясый. Шул рәвешле фәлсәфи проблеманы иҗтимагый мотивлаштыра.

Текстта Зөфәр хисләре укучыны сәхнәгә Рәшидә алып менәчәк серне кабул итәргә әзерли. Хикәяләүче укучыга әлеге "караңгы, салкын" дөньяны оныттырырлык матурлыкны күтәреп кенә, ләкин бик җентекләп "күзләрен аера алмаслык" итеп тәкъдим итә. Зөфәрне "хисләр чагылышының" кызның һәрбер хәрәкәтендә сизелүе гаҗәпкә калдыра. Автор Рәшидәдәге матурлыкны татар кешесенең күңелендә сакланган серле моң белән бәйли. Кыз башлап татар халык көе "Тәфтиләү"не башкара, гүя кешедәге илаһи матурлыкның

аһәңен – башлангычын эзли: “Рәшидәнең    күзләре берьюлы уйчанланып, ничектер эчкәре киткәне кебек булды, йөзенә моңсу җитдилек чыкты – һәм менә һичкемне, һичнәрсәне күрмәс булып, саф, нечкә тавыш белән җырларга тотынды... ...Бу көйнең моңын һәм бу сүзләрнең мәгънәсен телдән генә әйтеп биреп бетерерлек түгел иде. Бу көйгә, бу сүзләргә бөтен бер зур халыкның гүя барлык йөрәк зары, саф вөҗданы, ачы нужасы, авыр хезмәте, кара бәхете, якты өмете, кырлары-яланнары, таулары-урманнары, күлләре-сулары, сандугач-былбыллары, караңгы көзләре, язгы таңнары – барысы-барысы бергә җыелган, бергә үрелгән, бер киң дәрьяга әверелеп ага да ага иде...” Укучы ихтыярсыздан шул көйне ишетә, “дөнья читлегеннән каядыр бик биеккә, бик еракка оча” кебек. “Гади елау түгел” дип бирелгән күз яшьләре “яшәешне камилләштерергә ихлас омтылыш символы” кебек укыла: “... бу күңелләр төбеннән күтәрелгән бик изге, бик кадерле олы бер хиснең саф чишмәдәй саркып чыгуы иде”. Димәк, автор татар **кешенең иң изге, матур, серле моңы - яшәешне камилләштерергә, яшәү тәртибен җайга салырга омтылышы ул,** дигән хакыйкатьне үзең аша үткәрергә чакыра. Авторның, хикәяләүченең, Зөфәрнең һәм укучының “күңелләре ни белән тулганын бик ачык әйтеп” була. Күңеле ачылган – моң серенә төшенгән кеше “рухлана, дәртләнә”, “тавышы көчәя, иркенәя” дип кабатлый автор Рәшидә җырлары аша соңрак.

Әлегә кыз башкарган икенче җыр Зөфәрне (укучыны) дулкынландырырга тиешле хис – “соңгы вакытларда халык арасына таралган һәм бик тиз арада күңелләрне биләп алган” юксыну турында. “Юксыну” җыры аша бирелгән потенциаль эчтәлекне Зөфәрләрнең үз рухларын юксынуы кебек кабул итү дөрес булмас микән? “Вакытның рухын, кешенең күңеленә тулганын әйтеп бирә белгән җыр” дип автор бәясе килеп керү дә шуны раслый кебек. Зөфәрнең хисләрен тасвирлау асылда имплицит укучыга мөрәҗәгать ителгән текст кебек укыла: “Хәтта Зөфәрне дә бу җыр тетрәтмичә калдыра алмады. Дөрес, аның юксыныр кешесе юк иде, сугыш китергән михнәт-газап аның күңеленә авыр таш булып ятмаган иде, әмма шулай да янындагы кешеләрнең тирән кичерешләре аңа да күчте булса кирәк - берара бугазы төбенә каты төер килеп

тыгылды”. Башкаларны тетрәткән әлеге хис һәркемнең аң төпкелендә яши, тик аны башка хис тыйган: “Ләкин бу төерне ничек тә йотарга тырышты”.

“Иң соңгы җырны аеруча бер ялкынлану белән башын артка чөя биреп, кулларын җәеп, аяк очына күтәрелә төшеп җырлап бетергән” Рәшидә кичерешләре әлеге хисләрнең укучы күңеленә һичшиксез кереп урнашачагына авторның ышанычы кебек укыла. Зөфәр хисләренә төреп, автор кешегә салынган гаҗәеп рухи көчнең ачылуы турында, шул көчне тоюдан туган шатлык, җаваплылык хакында сөйли: “Халык гүя ач булуын, ялангач булуын, нинди авыр михнәттә яшәвен тәмам онытты; елады, көлде ул, һәм иң гаҗәбе – тирән рухи бер канәгатьләнү алып, гүя эчләренә тагы да зур бер сабырлык, чыдамлык, батырлык җыеп таралды ул”. **Табигать тарафыннан идеаль чынбарлык кору өчен салынган көчне тою кешене бәхетле итә - илаһи башлангычына якынайта**, ди автор: “Чалт аяз күктә түп-түгәрәк һәм ап-ак тулган ай тора. Шундый якты-якын ул – өстендәге әлеге көянтә-чиләкле кызны хәтерләткән күксел шәүләсе ап-ачык күренә һәм, бик теләгәндә, шуңа ничектер менә барып җитеп булыр иде кебек тоела... Шыгырдап торган коры салкын... Авыл өсте зәңгәрсу-якты... Чатнап бүрәнә шартлаганны ишетеп кала... Салкын тешкә тия, өскә сылана, әмма эчкәре үтәргә бик ашыкмый кебек... Атлавы җиңел, аяклар үзләреннән-үзләре йөгерергә тотыналар”.

Илаһи башлангычын тою кешене тормышны ярату юлына алып чыга. Хәсрәте-михнәтенә карамый кеше үзенә бүләк ителгән гомерне кадерли башлый. Идеаль чынбарлыкны кору өчен тормышны ярату кирәк, ди автор Яруллин теле белән: “Халыкта тормышка мәхәббәт бик зур, менә аның сере нәрсәдә...” Текстта автор фикере Рәшидә исеменнән җөпләнә: “...нинди генә җырны алма, ул барысыннан да бигрәк кеше күңелендә тормышка мәхәббәт уята, кешедә яшисе килү теләген көчәйтә...” Табын артында әйтелгән **тормышны ярату гына хәсрәт-михнәтне кичкәндә юаныч була ала** дигән әлеге хакыйкатьне Мәликә әби раслап куя: “Авыл кешесенең юанычы ни шул җыру инде, белеп сөйлисез”. Үз тормышын хикәя иткән гомер кичкән карчык исеменнән “тормышның үзе кебек чын, гади” киңәше дә билгеләнеп куела: “

Көн итү авырга булса да, барына шөкер итеп торабыз әле, мондый чакта зарлану язык булыр, нишлисең инде!”.

Биредә хикәяләүче-укучы, автор-укучы бер дулкынга көйләнә. Рәшидә чынбарлыгы белән Зөфәр чынбарлыгы арасында аерма югала, ике матурлык бер-берсен тулыландыра. Кавышу мизгеле – шул матурлыкны тоюдан туган омтылыш, якынаю түгелме? Һич югында, үзеңдәге матурлыкны башка берәүдә күреп, рухи игезәгеңне табу мизгеле ул. Автор бу сүзләрне Рәшидәдән әйттерә: “Мин гүя кеше таптым, кешегә сокландым, шул кешенең үзе, җылы-йомшак мөнәсәбәте миңа тансык иде, миңа кадерле иде...” Ләкин түгел икән. Рәшидәнең күз яшьләре **ялгышуы – камиллеккә омтылып та, берара кешелек горурлыгы өчен җаваплылык хисен югалтканга көчсез хәлдә калуы** турында сөйли: “Кинәт үземне кызганудан күземә яшьләр килде, һәм йөрәгемә авыр бер төер утырып калды”. Чөнки, ни кызганыч, Зөфәр бары Рәшидә янында гына беренче һәм соңгы тапкыр илаһи башлангычына якыная: “...бүтән бервакытта да татырга туры килмәгән, бары чын матурлыктан, якты уйлардан гына килергә мөмкин булган аеруча тирән, олы бер бәхет кичергән кебек тә була иде ул...” Ирен югалткан, ачлы-туклы яшәү михнәтен өстендә тойган, ләкин матурлыкның үзе булып гомер итүче Рәшидәнең сынау алдында калачагын сизү тагын да кызганыч (алар аңлашып саубуллашкан көн “кояшлы, коры салкын көн иде”). Рәшидә чынбарлыгы өчен җаваплы Зөфәр чигенәчәк, кыз тормышта артлы чана булып торган **ышаныч хисен югалту ноктасына** җитәчәк. Укучы биредә тагын күл образына салынган эчтәлекне укый.

Зөфәр өчен тормышның Рәшидәле ягы рәшә генә, ди автор. Ирнең кыз китергән үзендәге хисне түгел, кызның ни дәрәҗәдә ышанычлы булуын сынавы укучыда ямьсез хисләр уята. Маркизет күлмәклекне кабул итмәгән кызның яшәү тәртибен, Зөфәр сүзләренә кушылып, автор хакыйкать буларак яңгырата: **“Мәхәббәт уртак булырга мөмкин, сыныкны уртаклашырга мөмкин, әмма кешелек горурлыгын урталай бүлеп булмый икән. Кешенең үзенә куйган бәясе бар – шуннан бервакытта да төшмәячәк ул!” Кешелек горурлыгы - үзеңә салынган көчне юкка исраф итмичә, вакланмыйча яши белү. Иң**

**мөһиме– ахырда үзеңне кызганырлырлык булмасын.** Хикәяләүче Зөфәрнең ваклыгын аның янәшәсендә яшәгән "үз кадерен, үз дәрәҗәсен бик белә торган горур-һавалы" "әйттем-бетте" Хәмит Рәшидәдәге матурлыкны билгеләү кебек бәяли: "Ул синең токмач белән йокыдан башканы белмәгән тормышыңа шатлык, матурлык, җыр, музыка алып керер иде".

Алдагы бүлек Зөфәрнең әлеге тормыш-яшәеш кануннарын үзгәртергә теләп күптән башка йорт алырга исәпләп йөрүе турына сөйләү белән башланып китә. "Ниндидер бик вак купецтан калган", "нигез өстендәге бүрәнәләре черегән" Сабитовларның Суконныйдагы йорты Зөфәрнең исәп-хисапка корылган чынбарлыгына туры килми – "борынгы заманга" нисбәтле чынлык аңа кирәк түгел. Шул исәпкә "борынгы интеллегентларча хәйлә-мазарсыз" Гайсә Курамшин, әнисе Таибә абыстай, Зариф та керә.

Алдагы Зөфәр-Ушаков, Сабитов-Симаков вакыйгаларында ирнең горурлыкны ялган юлы белән әйләнеп үтүе тасвирлана. Кыйммәтле мебель шыплап тутырылган пространствода Рәшидә матурлыгы чынлап та рәшә генә. Зөфәргә Рәшидә әйткән сүзләр шул турыда: " син вәгъдә иткән бәхетле тормыш ул минем өчен далада уйнаклап югалган кайнар рәшәгә әйләнер иде". Зөфәр табынган чынбарлык – "кешенең нигезсез, булмас өмете", ди автор һәм, төш эчтәлеген дәвам итеп, исәп-хисапка корылган тормышны, аңарга ачулы Сабитовны бәяли. **Кешелек горурлыгын әйләнеп үтәргә теләгән рәшә алдында калган кешегә тормыш-яшәеш үзгәрү мөмкинлеге бирми, ди автор.**

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. XX гасырның 50-60 нчы еллар татар әдәбиятында тәнкыйди прозаның үсеш алуы хакында сөйләргә.
2. Ә.Еникинең "Рәшә" повестеның сюжет структурасы, символлар аша аңланган эчтәлек.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Гайнуллина Г.Р.1940-1980 еллар татар прозасы тарихы (тексттагы мәгънәләрне табу): Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Казан дәүләт университеты, 2009.– 100 б.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

**Лекция 2**

**Аннотация.** Лекциядә XX гасырның 50-60 нчы еллар татар әдәбиятында тәнкыйди прозаның үсеш алуы, А.Гыйләҗевның "Өч аршин җир" повестеның сюжет структурасы, символлар аша аңланган эчтәлек өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** тәнкыйди проза, сюжет структурасы, символлар аша аңланган эчтәлек.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**

3. XX гасырның 50-60 нчы еллар татар әдәбиятында тәнкыйди прозаның үсеш алуы.
4. А.Гыйләҗевның "Өч аршин җир" повестеның сюжет структурасы, символлар аша аңланган эчтәлек.

***А.Гыйләҗевның "Өч аршин җир" (октябрь-ноябрь, 1962)*** повестеның язылу-басылу тарихы турында А.Гыйләҗев болай искә ала: "Өч аршин җир" романым "совет әдәбияты" журналы битләрендә дөнья күргәннән соң журналның мөхәррире Г.Мөхәммәтшинны антисовет рухындагы әсәр басканы өчен обкомга йөрттеләр. Үземнең кулъязмалырымны якын да

китермәделәр.Роман беренче тапкыр Мәскәүдә “Дружба народов” журналында дөнья күреп, махсус бүләккә лаек булганнан соң, Казанда бастырдылар”.

Әсәр поезд детален  тәкъдим итү белән башлана. Символик укылышта язмыш, тәкъдир,  үсеш мәгънәсендә  килгән әлеге образ текстта хәрәкәтнең башлангычын белдереп килүче буларак төгәлләшә. Поездның Ерак Көнчыгыштан килүче, унсигезенче номерлы дип тәкъдим ителүе дә эчтәлеккә кереп урнаша. Хәрәкәт әлеге поездның дүртенче вагонында бара: “Ерак Көнчыгыштан килүче унсигезенче номерлы поездның дүртенче вагонында ниндидер хәвефле, мөшкел хәл булуын пассажирлар барысы берьюлы белделәр”. Дүрт саны бөтенлекне, камил ритмны, гаделлек Алласын белдереп килеп, төп герой тормышының бөтен, камил оештырылачагын,  гаделлек юнәлешенә борылганлыгын хәбәр итә.  Әлеге **юнәлешне – башка берәүгә ярдәм кирәклекне**  поезд радисты “хәбәр итә”. Әсәрдә төп каршылык булып торган чит/үз бинар оппозициясе радист сүзләренә бәйле кертелә. Шул рәвешле, әсәрдә “бәйрәмчә тавышы шөбһәле сүзләргә ятышмаган” каршылыклы хис-кичерешләр турында барачак. “Кешелекле һәм тормышчан” хисләр кешене үзгә юлга алып чыга ( “аның тавышы шөбһәгә әйләнде”) дөрес юлга көйли. Радистны; оппозиөияне үтү юлы “медицинага берәр төрле мөнәсәбәте бар булган кешене” ашыктыру ” белән башлана.

Пассажирлар образларының үз-үзен тотышлары хәбәр ителү төп геройның шәхесе һәм аның тормышка карашын символлаштыра. Пассажирларны билгеле бер кичерешләр дулкынына радист көйли. Кешеләрне аптыраштa калдырган “тантаналы” хәбәр (“кешеләр берни дә аңламый калдылар”) шөбһәле тавыш белән кабатланганнан соң кызыксыну уята: “Купе, коридорларда гәп кузгалды: барысы да мәж килделәр”. Кешеләрнең сөйләшүендә аерып куелган прокурор һәм табиб **кешелеклелеккә мөнәсәбәт** кебек тамгалана

Врач (башкаларга ярдәм итүче) һәм “озын, кәпрәйгән прокурор гына” (тикшерүче, башкаларга гаеп салучы) булган кешеләргә мөнәсәбәт автор

карашының белдерелеше кебек укыла. Димәк, яшәеш “юлында очраган төрле маҗаралар”да үз-үзеңне тоту тормышка карашыңның нинди булуына бәйле.

Сүзне тормышка табиб күзлегеннән караучы кешенең дәвам итүе – авторның укучыны яңарырга – үзгәрергә тиешле чынбарлыкка алып керү омтылышы. Борынгыларда унике саны бербөтенне аңлатып килә, унөч саны яңа циклның башлангычы – үлем символы кебек укыла. Шул ук вакытта унөч саны яңару эчтәлеген дә аңлата. Табибә ханымның карашы символик укылышта табигатьнең яңаруы, ел фасылларының алышынуы кебек аңланган “тәрәзә артында тезелешеп калган яшь, купшы наратларга” юнәлтелүе бу эчтәлекне көчәйтә. Авторның укучыда табибә образына ихтирам тәрбияләве аңа ханым дип эндәшүдә үк башлана, ханымның үз гамәленә мөнәсәбәтен һәрбер хәрәкәтен бөртекләп тасвирлау аша дәвам иттерелә. Хәбәрне ишетүгә ярдәмгә ашыккан табибә (“ханым аякларын төреп утырган җәймәне шактый җитез бер якка алып ташлады, җәлт итеп идәнгә сикереп төште”) аның җылысына мохтаҗ кеше белән очрашуга кабаланмыйча сак кына әзерләнә (“элгечтән ап-ак яулыгын алып бәйләде, көзгегә күз салды, ашыкмыйча гына изүен рәтләде”). Тормыш юлына атлаган кызның омтылышы аша автор үз карашын әйтеп бирә, табибә образында кешелеклелек идеалын тасвирлавын һәм башкаларның мондый кешеләргә карашын белдерә: “Урта мәктәп бетереп, Казанга укырга керергә баручы кыз бик кызыксынып һәм сокланып аңа иярмәкче булган иде, юлдашлары аны туктаттылар” .

Шул урында әсәргә “кыен чакларда да үзеннән түбәннәргә аны-моны сиздермәскә күнеккән” поезд бригадиры образы килеп керә, автор аңа төп герой Мирвәли образын алып керүне йөкли – ул иргә сүз ката. Символик укылышта бригадир (контролер) гаделлек булдыручы, күңел тынычлыгын тәэмин итүче кебек аңлана . Шәмсегаянны төшереп калдырырырга күндерү вакыйгасында бригадирның бу ир алдында физик көчсезлеге әйтелә (“буйлары бер чама булса да, бригадир бу сәер кеше янында чебештәй зәгыйфь, көчсез кеше икәнлеген тойды”). Ләкин “нык тәнле, каты куллы” Мирвәлине гаделлек ягына алып чыгу бурычы әлеге персонажга йөкләнә.

Шунда ук коткы таратучы, мәгънәсез киеренкелек тудыручы проводник образы җәмгыятьтә куркып-куркытып, ярашып-буйсындырып, яла ягып көн итәргә күнекккән радист, пассажирлар образларын кабатлый. Автор әсәргә "туры юлдагыларның әмир-хөкемдарын" ир дип олылып кертеп җибәрә. Шул рәвешле Мирвәлигә алдан ук сак карарга – аның гамәлләрен кабаланмыйча бәяләргә чакыра кебек. Хикәяләүче аның исемен укучыга ихтирам белән җиткерә: "Ирнең исеме Мирвәли иде" , бригадирның аның белән сөйләшергә теләве укучы өчен юлын югалтканнарга мөнәсәбәт өлгесе булып тора. Повестьның мифопоэтик структурасын Чура батыр дастаны белән бәйләп өйрәнгән галимә М.Хабутдинова хаклы: "А.Гыйләҗев әхлакый нигезләр какшый башлауның тамырларын геройның характерына, ул яшәгән дәвердәге вакыйгаларга түгел, ә халыкның иреге, мөстәкыйльлеге юкка чыгарылган 1552 елгы вакыйгаларга бәйли. Герой язмышын автор Мәңгелек контекстына куя".

Мирвәлинең башкаларга нәфрәтле, ачулы булуы, читләшүе ("җыелганнарның чыр-чуын зәһәр мыскыллау белән иреннәрен чалышайтып тыңлый, артык якын килеп кычкыра башласалар, суол кулы белән колагын томалый иде" ) - асылда аның дөреслек эзләве, кимсенеп яшәргә теләмәве ул. Автор табибә ханым, бригадир, Шәмсегаян, яшь Мирвәли образлары ярдәмендә **кимсенергә гадәтләнгән, ләкин һич тә алай яшәргә теләмәгән үзең кебек кешеләр арасында алардан читләшү мәгънәсезлек, киресенчә, бер-bereңә сак, игътибарлы булу тиешрәк** дип гел кабатлап тора. Мирвәли башкалар дөньясында үзен алдан ук чит позициягә куя, асылда гаепләүләрдән шулай саклана. Хатынына – үзе өчен күпмедер якын булган кешегә мөнәсәбәте бу читләшүнең никадәр көчле икәнлеген раслый. Билгеле, Мирвәлигә болай яшәү әлегә уңайлы, аны бу хәлдә дә үз итеп торучы кеше бар бит. **Автор Шәмсегаянның Мирвәлине аңлавы, кабул итүе, сак кына үзгәртергә тырышуы белән укучысына түземлелек сорап эндәшә**.

Шәмсеганны әсәргә табибә ханым алып керә. Мирвәлигә мөрәҗәгать итеп, "кирәкле җавапны ала алмаслыгына төшенгән ханым көч белән ишекне тартып ачты" – автор укучысын "бер халәттән икенчесенә - үзгәргән яңа

чынбарлыкка”шул рәвешле кертеп җибәрә. Әлеге чынбарлык сурәте – Шәмсегаянның портреты татар кешесенең җуела башлаган асылы, үлемгә хөкем ителгән якты “кояшлы- шәмсегаянлы” әхлагы кебек укыла. Кешенең игелекле, якты ягын символлаштыручы чәч детале әсәр текстында кабатланып килә. **“Шау-шулы, авыр һавалы купе”– тормыш-яшәеш татар кешесенең шәмсегаянлы ягын күптән какшаткан (“димәк, ул күптән авырый”), хәзер татарның якты ягы “дөнья өчен ачылырга тели (“тәрәзәне ачасы иде” ), тик бүгенге яшәештә дә иркен сулыш алырга - ачылып китәргә мөмкинлек чамалы (“ачарлык түгел шул, паровозы бик әшәке төти”).** Әйтергә кирәк, аның исеме соңрак әйтелә, автор проблемага гомумәһәмиятлелек өсти.

Әлеге иҗтимагый хәлдә – поездда кинәт “тормозга басу” да көткән нәтиҗәне бирмәячәк: “Кемдер тормозга бастымы, шәп кенә барган поезд бер секундка гына тартылып алды. Авыру һуштан язган иде. Тамыр “менә туктыйм,, менә туктыйм” дигән кебек өзек-өзек кенә тибә иде”. Иң куркынычы – моннан соң нидер үзгәртергә теләү нәтиҗәле булмаячак (“Тәрәзәне ачтым, барыбер хушына килмәгән”). Бу иҗтимагый яшәештә “өске полкадан зур салам эшләпә генә идәнгә тәгәрәгән”) кебек әллә ни мәгънәгә ия түгел омтылыш, болй эшләү рухи киеренкелек тудырачак (“...бригадир аптырап калган тирә-яктагыларга карады, нидер әйтергә теләгәндәй, тәрәзәгә, тәрәзә артында бер-берсен кочаклашып авып калган агачларга ымлады”).

Шәмсегаянны “Кыек Урман” станциясендә калдырырга мәҗбүрилекне әйткән табибә ханым Мирвәлинең карышуын “кыргыйлык” дип бәяли. Кыргыйлык – “туры юл/кыек юл оппозициясен” үткәндә сайлаган юлның автор тарафыннан бәяләнүе. Кыек Урман тукталышына – билгеле бер юлның соңына килеп җитүен сизгән Мирвәли ихтыярсыз бәргәләнә, чөнки кыек бит, чынлап та бу юлны сайлау кыргыйлык булган ләбаса. Багаж – юлның соңына алып килгән тормыш итү рәвеше, тупланган тәҗрибә. “Күңел капкасын ачып, кешеләргә үзен күрсәтергә яратмый торган” Мирвәлине биредә туктарга мәҗбүрилек уңайсызлый – асылда үзе сайлаган юлның соңы аңа кирәксез.

“Мирвəлинең багажының дəү булуы – күңелендə йөрткəн кирəкмəс йөк  кебек укыла.

Мирвəли аң төпкеленнəн килгəн юлның соңы белəн бəйле чарасызлык хисенə əзер түгел, аңы бу чынбарлык белəн килешүне, аны кабул итүне тыя: “Фельдшер исə Мирвəлигə əллə никадəр киңəшлəр бирде. Аның сүзлəре Мирвəлинең бер колагыннан кереп, икенчесеннəн чыга торсалар да, ул ризалашкан төс белəн ым кагып, башын селкеп торды” .

Символик укылышта хислəрне йөгəнлəү, үзеңне кулга алу мəгънəсендə килгəн ат образы (бу өлештə җирəн бия) Мирвəлине яңа чынбарлыкка – үзгə рухи халəткə алып китə: “Поезд белəн ат бер вакытта диярлек кузгалдылар, һəм күпмедер янəшə бардылар”.  Хəрəкəтнең башлангыч халəтенə нокта куела (“менə поезд үтеп китте, соңгы тапкыр яңгыратып гудок бирде, үргə менеп сулга борылды”) “тимер юл буена киң тасма итеп каен катыш сəрви агачлары утыртылган чуар кишəрлек” – хəсрəт белəн билгелəнгəн рухи яңарыш  юлы үтелде,  алда ирне сызланулар, əрнү-сыкраулар көтə (“рельслар озак кына гүелдəп, сызланып тордылар”). Юл дəвамында ирнең хислəре, аларның нигезе бəян ителəчəк, Мирвəли шул хислəрне тəртипкə салу өчен үз-үзе белəн очрашуга бара. **“Кая кайтасың?”** – бу сорауны ир үзенə беренче тапкыр куя.

“Əхлакый чистарыну кебек аңлашылучы рухи  юл” башы [3:54 ]итеп иң тəүдə арыш басуы – Мирвəлинең авылда яшəгəндəге рухи халəтен искə төшерер өчен сайлана: “Җирне кадерлəп, төпченеп, юлга кадəр үк китереп чəчкəннəр. Кырга нык куллы кешелəр хуҗа икəне күренеп тора”. Мирвəлинең хəзерге халəте – “күзгə күренерлек хата эзлəү”– элеккчə үз юлын акларга омтылыш кебек аңлана. “Аксыл кашлы, кызыл киң битле, зур күзле авыл егете” олаучы – бу өлештə автор карашын җиткерүче кебек тамгалана. Юлның тарлыгын – телəгəнчə яши алмауны сылтау иткəн “көтеп торганчы таптап китүне кулай күргəн  ярсу Мирвəлигə олаучы (автор сүзе) “киң урыннары да җитəрлек, юл сап” дип җавап бирə. **Димəк, Мирвəли танырга телəмəгəн яшəеш тəртибенең тəүгесе – түземлелек, үткəреп җибəрə белү, юл кую икəн.**

Автор биредә тавыш образын уйната башлый. Иң тәүдә укучысын бер мәлгә **тын** калырга – күңел төпкелендә урнашкан шул яшәеш тәртибе турында уйланырга чакыра. **Кешене “тилмереп үзенә авазлар, шау-гөр эзләү”– шау-гөр эчендә онытылырга теләү халәтеннән тын калып уйлану дөрес юлга чыгара, ди автор.** Автор проблеманы иҗтимагый (“ыжгырып барган поезд” тавышы) һәм милли (“бик ерактан – тегеннән” килгән өн) мотивлаштыра.

Мирвәлине үз-үзен аклый алмавы берөзлексез борчып тора, гадәтләнгәнчә ир бу хистән качып котылмакчы (“Юл туп-туры, кыр тип-тигез иде. Әнә шул тигезлек, турылык Мирвәлинең теҗкәсенә тиеп, ялыктырып , борчып тора иде”).

Шәмсегаянның “**рәхәт** итеп, **күкрәк тавышы** белән көлеп җибәрүе” **тургай тавышы** белән янәшә куелып, символик укылышта Илаһияткә сөенеп мөрәҗәгать итү кебек шәрехләнә. Әлеге тавышны Мирвәлинең дә ишетүе – Илаһият юлына борылуы ул (“Сайрый икән, берәү генә түгел, икәү, өчәү, бик күп!..” Олаучы – автор бу хакыйкатьне раслап куя (“Тургайлар мыж”). Символик укылышта яшәеш хәрәкәте турындагы фикерне белдерүче **арба тәгәрмәче шыгырдавы тавышы** – Шәмсегаян теле белән Мирвәли күңелендә хис-хәрәкәт кузгалуны тамгалап кую (“Тимә, шыгырдасын!”). Тавыш образы аша аңланган эчтәлекне **арыш исе** детале ныгыта (“Сулавы ук рәхәт!” назлылыкны белдерүче **күккүзләр** йомгаклап куя. Шул рәвешле, “сюжет нигезен кайту ситуациясе хасил итә” – **Шәмсегаян ихтыяры белән олаучы-автор Мирвәлине сөенеп яши торган, иркен сулышлы, назлы дөньяга алып кайтып бара.** Мирвәлинең күңеле бу чынбарлыкны ярата, үз итә, ләкин “колагы тонганлык” әлегә аңын тоткарлый. “Яргаланган кулларын аксыл кашлары өстенә куеп, ялгыз олаучы” (автор) шул “ят, чит ис тараткан” Мирвәли чынбарлыгына моңая.

Автор проблеманы фәлсәфи яссылыкка күчерә, Мирвәли образы яшәү/үлем оппозициясендә калдырыла. Тәгәрмәч шиннары ашарып шомарган аксыл машина – үлем, Шәмсегаян караган тәрәзәләр исә яшәүне символлаштыра. Үлем башкалар дөньясыннан аерылып китүне белдерсә

(хатыннар комачауламас өчен тәрәзәләрен ныклап ябалар), яшәү - шул аерылып киткән мәлдә кешеләр күңелендә уелып калырга тиешле сурәт (Шәмсегаянның әледән-әле тәрәзәләргә каравы). Автор шул хәрәкәтсез мизгелнең сурәтен тасвирлап, алда китерелгән **тын калып уйлану** детален кабатлый. Шул мизгелдә юанырлык җай тапмаган Мирвәли (тәмәкесе беткәненә ачулана) **"бик таныш, бик тәмле" ис** сизеп "күзләрен чытырдатып йома". Миләүшә-гөл, миләүшә-бала образы Мирвәли белән бәйле рәвештә символик укылышта бакчада, күлдә үсеп утыручы чәчәк образы мәгънәсенә - чынга ашкан эчке мөмкинлекләргә туры килә. Мирвәлидә тәүге тапкыр хатыны белән сөйләшү теләге уяна, ул үзенең чынга ашарга тиешле булган ягын тоеп сөенә дә, елый да, тик янына кергәч сүз таба алмый – "карый да ката". Шәмсегаянга сүзе күнегелгән тормышка кайту белән бәйле. **Мирвәлине куркытачак, уйга салачак хәл бер генә - Шәмсегаянның үлеме, автор вакыйгаларны шул якка бора, укучыга аның үләргә ятуын кабатлап, шулай булырга тиешлеген асызыклый.** "Кинәт аның башына саллы имән күсәк белән суккан кебек булдылар, ул берьюлы исәнгерәп, миңгерәүләнеп калды: Шәмсегаян үлсә?!" Бу хәбәрне Мирвәлигә "чынаяк тәлинкәсе кебек зуп-зур күзле" кыз сиздерә, **идән шыгыдаган тавыш хәвеф булачагын искәртә.** Ярым караңгы, салкынча коридор, тар ишек, кечкенә бүлмә, бердәнбер карават, иңнәре тар, җиңнәре курач ак халат Мирвәлинең үзе курыккан чынбарлыкка аяк атлавын белдерә.

Шәмсегаян шул урында яшь табибка сөйләгән кебек Мирвәлигә соңгы сүзен – васыятен әйтә, автор биредә җир, сабан тургае, Сабан туе образларын янәшә куеп укучысы белән сөйләшә. **Җир** мифопоэтик укылышта ана мәгънәсендә килә, җир – яңадан туу, рухи үсеш – яңарыш, үз асылыңа кайтуны символлаштыра. Сабан туе – үзәк бәйрәм, танышу-кавышу, очрашу көне, күңелнең ачылган мәле. Шул рәвешле, **кеше тормышының мәгънәсе - рухи камиллекә омтылу, гамәлләреңнен нигезен шул омтылыш белән үлчәү. А.Гыйләҗевның Шәмсегаяны шул васыятьне җиткерү вазифасын башкара. Мирвәли исә - үз асылына кайту юлына баскан татар ире-әмире.**

Мирвәли өч аршин җир сорап авылдашларына мөрәҗәгать итә, ир үз асылына кайтырга теләп, кардәшләреннән таяныч сорый.

Мирвәлигә үләчәген Шәмсегаян үзе әйтә. Яшел чемодан – тормышның тыныч, көйле мәле, яңа чалбар – шул яшәештә урын алу, буй-буй күлмәк – туры-тигез холык кебек аңлана. Шәмсегаян үткәндәге ризык-тормышка ихтирамлы булырга, “читкә ташламаска” өнди, якыннарга – ярдәм итәрдәй кардәшләргә таянырга куша (“атлары бардыр әле”). **Тормыш-яшәештә кешене тыныч-сабыр холкы, башкаларга ихтирамлы карашы гына бәхетле итә.** Автор “туган җир, тамырлар, нигез” турындагы хакыйкатьнең укучысы күңеленә барып ирешүенә өметләнә (Шәмсегаян Мирвәлидән авылдашларга үзе турында күп сөйләвен, ташка язган исеменең дә кеше күзенә күренеп торырлык булуын сорый, пәрдәне – яшерелгән хисләрне ачуны үтенә).

Мирвәли япа-ялгыз яңа дөньяга “канатлары талган карт бөркет” кебек өметләре киселгән, хисләре таралган ярым үле хәлдә аяк баса. Мифологик укылышта “теләсә кемгә баш бирмәс, кешеләрчә сөйләшә белә, үзенең хуҗасына акыллы киңәшләр бирә торган” Акбүз ат Мирвәлигә тапшырыла. Галәм сулышы – җил, илаһи башлангыч белдерелеше - төн миләүшәләре ярдәмендә автор укчысына Мирвәлинең юлын асылына кайту юлы кебек тамгалый (“Ишегалдын иңләп искән җил, миләүшә чәчәкләрен кочаклап, аларның хуш исләрен урамга таратырга чыга”). Сипкелле битле малай, борчак чәчәге төшкән бизәкле күлмәк кигән кыз елавы капка төбендә - сынаулар алдында калган Мирвәли кичерәчәк хисләрне – ирнең үзен тапкач елаячагын алдан укырга ярдәм итә. Әлегә Мирвәлинең ялгышлары, эгоистлыгы (күләгә образы), аның киләчәкле булуына өметен томалый (ап-ак казлар детале): “Ямь-яшел чирәмдә тезелешкән ап-ак казлар өстеннән Мирвәлинең дәү, кап-кара күләгәсе үтеп китә...”.

А.Гыйләҗев алдан ук укучысын юлның тәмамы белән таныштыра. Мирвәли күңелендә иң элек бәхетле, бөтен булырга тиешле тормышка керергә кыймау-куркып тору югалачак (“Иң элек урам-тыкрыклар ясап тигезле-тигезсез дә, аркылы-торкылы да сузылган киртә-корталар, башларына балчык

чүлмәкләр, бала чүпрәкләре, иске ураклар эленгән, колмаклар сарылган читәннәр күздән югалдылар”), аннары җәмгыятьтә барган үзгәрешләргә тулысынча бәйлелек кимиячәк ( “аннан уңган кызыл флаг эленгән, муртайган такталы янгын каланчасы һәм эше юклыктан моңаеп, терсәкләре белән яңагына таянып торучы пожарник күренмәс булды”), иң соңыннан – курку беткәч үз асылың белән очрашу – илаһи башлангычыңны табу көтелә (“иң соңыннан гына авылның төрле почмакларында – буа ярларында, күпер төпләрендә уйдык-уйдык утырган эре сөякле, юан кәүсәле тупыллар кичке дымсу рәшәгә уралып беттеләр”). Тупыл – дөнья үзәге, Күк һәм Җирне тоташтыручы, илаһи асылыңа омтылу кебек шәрехләнә. Әдәбият галиме Д.Заһидуллина Мирвәли күңелендәге курку хисен “әйләнеп кайтудан курку һәм үз-үзеңнән курку” икәнлеген әйтә. Әсәрдә бик эзлекле рәвештә шул ике төрле курку хисенең янәшә баруы бирелә.

Мирвәли “кемдер, көчле рухлы берәүнең” “дерелдәп торган җанын” борчуыннан курка. Тик ирдән “Кем син?” – дип сораучы юк. Димәк, Мирвәли **үзе уйлап тапкан үзеннән көчлерәк башка берәүнең барлыгыннан курка.** Автор илле сигез санының символик белдерелешенә Мирвәлидәге бу куркуның нигезен күрсәтә: “Бу сан күңелдәге бар уйларны, хисләрне кысрыклап чыгарды. Башын калкытты исә ул күз алдында уйнаган бишле һәм сигезле цифрларны гына күрде...” Символик укылышта бишле саны – Аллаһ һәм Галәм арасында торган кешене белдерә, бишле – кешенең физик асылы (биш хис, биш бармак, тәннең биш тигез өлешкә бүленүе). Сигезле – мисырлыларда космик тәртип саны, Кытайда дөнья корылышының нигезе һ.б., илаһи башлангычыңны табу өчен үз өстеңдә эшләүне дә символлаштыра.Димәк, күңелдәге курку хисен җиңү өчен кеше үзенең һәм физик, һәм рухи асылын җигәргә тиеш. **Курку хисен җиңү – үзеңнең башкаларга охшамаган хасиятеңне табу, тәртипкә-гармониягә ирешү ул, ди автор.**

Мирвәли образына салып А.Гыйләҗев кабаланмыйча курку хисе белән көрәшү юлын өйрәтә кебек. Иң элек бу хисне тану белән аның сәбәбе, башлангычы турында уйлану зарурлыгы туа: “Нигә артына борылып карарга шүрли соң ул? Кем сагалый аны?.. Нәрсә?.. Кайчан башланды соң бу курку?”

Әтисе аны шайтани хистән куркырга өйрәтә - иң беренче булып нигез булырлык шул вакыйга искә төшерелә.

“Үз-үзе белән беренче тапкыр очрашудан курыккан”. Мирвәли эчке рухи таянычына – Шәмсегаянга – үзенең шәмсегаянлы-кояшлы асылына эндәшә һәм “үз тавышын үзе танымый”. Биредә Мирвәли икегә бүленә: Шәмсегаянны яратып, иң бәхетле хатын-кыз иткән ир һәм Шәмсегаянны иң бәхетсез итеп яшәткән исерек, азгын. Башкаларга “Мирвәлинең беркемнән дә курыкмавын” раслаларга ашыккан ирдә бу хиснең оялавы гайре табигый кебек (өйләнүе, өеннән чыгып китүе, Таифә йортын тәртипкә китереп яшәп китүләре). Бу вакыта автор Мирвәли белән Шәмсегаянның тулы гармониядә яшәүләрен – бернидән курыкмыйча матур гамәлләр кылып яшәүләрен тасвирлый: “Иң элек карчыкның өен сипләделәр. Чуал буеннан бәрмәнчекле тал чыбыгы ташып өйалды үрделәр, аны кызыл балчык сылап җылыттылыр”. Бу истәлекләр куркудан өстен чынбарлык, чөнки аларда башка хис – якты мәхәббәт хисе яши. **Шул рәвешле автор биредә кешенең рухын җимерә алырлык көчкә - курку хисенә каршы торырлык икенче бер хисне – мәхәббәтне кеше табынырга тиешле кәгъбә  дип раслап куя.** Сөю хисе - “Карачураның иң сылу кызы, авыл егетләренең генә түгел, тирә-як егетләренең дә күңелләрен тартып торган кәгъбә”. Шәмсегаян күңеленең илаһилыгы. Яраткан кеше сөйгәнен үзе артыннан илаһи чынбарлыкка дәшә (Өч кое янында ал читле яулык бирүе), “чит дөньядан саклый” (шәлен бирү вакыйгасы), “һәрвакыт бердәй ягымлы, кече күңелле, мөлаем гына елмаеп, сабыр гынга көтеп тора” .

Мирвәлине чит чынбарлыкка алып кергән “шайтани тәкәбберлек  һәм җенләнеп акылдан язу” аның тегермәнгә эшкә урнашуы вакыйгасында да кабатлана (символик укылышта тегермән – шайтани башлангыч). **Мәхәббәттән баш тарту кешенең шайтани хасиятен ача** (тегермәнгә кемлеге белән кызыксынучы булмаганга урнаша), шул ук вакытта **мәхәббәт – иң олы көч - һәрвакыт барлыгын сиздереп, ымсындырып торучы чынбарлык** торучы : “Кыр исе килә иде бодайдан! Ындыр исе! Арбалар исе, ат исе!.. Көлтәләр, иген тузаны исе, көзге келәтләр исе аңкый иде аннан”. Мәхәббәт хисен искә төшерү

Мирвәлинең “сагыш тәбесендә тыпырчынган йөрәген парә-парә телә”– иманга китерә. **Курку хисен иманга килү – тормышка, кешеләргә, сөйгән ярга мәхәббәтне тану гына җиңә ала, ди автор.** Әтисе өйрәтеп калдырган хакыйкать шул икән (шунда Мирвәли шайтан җылысын куа, Шәмсегаян җырын-хисен искә төшереп беренче мәртәбә үрсәләнеп елый, сугышка алынмавына үкенә). Мирвәли өчен туган яңа көн – яңа хисләр Шәмсегаянның Карачура турында әйткәннәрен искә төшерү белән бәйле. Мирвәли һәм Шәмсегаян исеменнән автор аларның утыз еллык тормышын сукбайлыкта үткән гомер буларак бәяләтә. “Кеше күңеленең йомшак, әйбәт яртысында калу” (Шәмсегаян) “бер мәртәбә “кода” дип әйттер өчен дөнья малын, дуңгыз канын бирергә әзер Мирвәли” – әшәке сукбайлык халәтеннән коткаручы хакыйкать. **Димәк, туган җирдән, якын кешеләреннән баш тарткан, югалган кеше - сукбай гомере буе шул җылылыкны эзләп тилмерә икән.** Алар сукбайлыкка юл алган төнне “япан кыр уртасында, буран эчендә баш очында”калыккан Җидегән йолдыз – Җирнең үзәге, көч чыганагы турында искәртә. Мирвәлинең куркуын онытып Карачурага кайтып килергә ниятләве – югалткан көчне эзләү, игелекне явызлыктан аерырга омтылу (Мирвәли белән Шәмсегаянның аяк астындагы ак ташка карап торулары). Мирвәлинең рухи таянычны югалтып кайтып егылуы – аның Шәмсегаян белән бергә яшәгән гомеренең дәвамы – “әшәке сукбайлык”, дәвере, “яман шешле” чор. Урманда йомшак җирне казуы, кырмыскалар оясын кузгатуы, агач тамырларын тоюы – киресенчә, Мирвәлине үзендәге сукбайлык халәтеннән баш тартырга омтылыш – уйлану мәле. Уйлану аның куркуын тагын да көчәйтә, Мирвәли елый. Атның кузгалмавын – бер мәлгә тукталып торган хәрәкәтнең яңадан көч алып китәргә тиешлеге ул. Мирвәлине елаткан чынбарлык – аның кемлеген белешү. **Димәк, кеше һәрвакыт бер-берсен булган җылылыкка сусап яши, ярату кеше күңелен баета, иркен сулышлы итә, ди А.Гыйләҗев.** Автор җизни түгел, кода түгел – беркем түгел Мирвәлине “үз гаебенең зурлыгын миенә җиткерү өчен” тагын бер кат капка-сынау алдында калдыра. Хөкем сәгате – Мирвәлине тану сәгате якынлаша. Шул рәвешле, **автор атын җибәргән Мирвәлигә үз асылыңны**

**табу - өч аршин җиреңә лаек булу – синең Җир белән Күк арасындагы урыныңны тамгалау бары кешеләрне ярату көче белән генә чынга аша, ди.**

**Сораулар һәм биремнәр.**

1.А.Гыйләҗевның “Өч аршин җир” повестеның язылу тарихы.

2. А.Гыйләҗевның “Өч аршин җир” повестеның сюжет структурасы, символлар аша аңланган эчтәлек.

**Әдәбият исемлеге.**


1. Гайнуллина Г.Р.1940-1980 еллар татар прозасы тарихы (тексттагы мәгънәләрне табу): Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Казан дәүләт университеты, 2009.– 100 б.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

3..Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф.Заһидуллина, В.Р.Әминева, М.И.Ибраһимов.– Казан: Мәгариф, 2007.– 112 б.

4. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов, В.Р.Әминева.– Казан: Мәгариф, 2005.– 111 б.

5. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А – Г) / Фатих Урманче.– Казан: Мәгариф, 2008.– 303 б.

6. Хабутдинова М. Драгоценный камень А.Гилязова / М.М.Хабутдинова /Гилязов А.М. Повести: Три аршина земли; В пятницу, вечером / Аяз Гилязов. – Казань: Магариф, 2008. – С.233-258.

## Тема 9-10. Сугыштан соңгы татар прозасында повесть жанрының яңартылган реализмга сукмак салуы. Публицистик катлам.

**Лекция 1**

**Аннотация.** Лекциядә сугыштан соңгы татар прозасында повесть жанрының яңартылган реализмга сукмак салуы, Р.Төхфәтуллинның авыл прозасына караган “Авылдашым Нәби”, “Йолдызым” повестьлары, сугыштан соңгы татар прозасында публицистик катлам (“Җәяүле философ” һ.б.) өйрәнелә.

**Ачкыч сүзләр:** яңартылган реализм, публицистик катлам.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**

1. Сугыштан соңгы татар прозасында повесть жанрының яңартылган реализмга сукмак салуы.
2. Р.Төхфәтуллинның авыл прозасына караган “Авылдашым Нәби”, “Йолдызым” повестьлары.
3. Сугыштан соңгы татар прозасында публицистик катлам. (“Җәяүле философ” һ.б.)

1970 еллар чигендә СССР дип аталган территориядә яшәүче халыклар әдәбиятында социалистик реализм кысаларына сыешмаган әсәрләр күпләп языла. Милли һәм әхлакый кыйммәтләргә ия буларак авыл кешесен, җирдә эшләүчене сурәтләгәнгә, *авыл реализмы* дип атала башлый. Крестьян (авыл) реализмы шартлы рәвештә агым атамасы булып китә. В. Овечкинның «Район көнкүреше» (1952), Е. Дорошның «Авыл көндәлеге» (1954—1962) язмаларында, Ф.Абрамовның «Сугыштан соңгы прозада колхоз авылы кешеләре» дигән программ мәкаләсендә (1954), «Абыйлар һәм апалар» романында (1958 елда басыла), В. Астафьевның

беренче хикәяләрендә формалаша. А. Солженицынның «Матрена ишегалды» (1959), «Иван Денисовичның бер көне» (1962), В. Беловның «Күнегелгән эш» (1966), В. Астафьевның «Саубуллашу» (1957—1992), «Патша-балык» (1972—1975), В. Шукшинның «Кызыл балан» (1973), В. Распутинның «Соңгы срок» (1970), «Матера белән бәхилләшү» (1976) әсәрләре авыл реализмы кысаларында иҗат ителгән.

Авыл прозасы җир кешесенең көндәлек тормышын сурәтли, әхлакый кыйммәтләрне, гадәт-традицияләрне югары күтәрә. Гомумән, бу агымның традицион әхлакый кыйммәтләрне әдәбиятка кайтаруы иң төп сыйфатлардан санала (А. Солженицын алар-ны «әхлакчылар» дип атый). Кешенең рухи дөньясын, фикер һәм хисләр байлыгын үзәккә куеп, әхлакый кыйммәтләрнең югала баруына ачынып, әлеге хәлдән чыгу юлларын барлап язылган әсәрләр совет әдәбиятын иҗтимагый яссылыктан – кешегә, югары кыйммәт буларак кешене сурәтләүгә юнәлтә.

Бер үк вакытта агым социалистик реализмнан капма-каршы чиккә ташлану кебек тә кабул ителә. Шәһәр тормышын, мәдәниятен кире кагу, бары тик авылда гына чын тормыш бар дип санау, авылны халыкның рухи нигезләре сакланган урын итеп изгеләштерү күзәтелә. Илне тергезү, кешене рухи һәм әхлакый яктан таза-саф килеш саклау учагы итеп нәкъ менә авыл карала. Авыл реализмына хас сыйфатлар:

– Авыл тормышын чынбарлыкка охшатып, детальләрдә сурәтләү, авылны рухи байлык сакланып калган урын дәрәҗәсенә күтәрү;

– эшче сыйныфны идеаллаштыру урынына крестьян сыйныфын тарихи һәм эстетик идеал дип белдерү, тирә-юньнән дошман эзләү атмосферасын тергезү;

– гади, гадәти сөйләмгә лирик пафос бирү, гадәтине мәңгелек символлар ярдәмендә баяләү;

– интернационализм урынына милли идея белән чыгыш ясау, үткәнне мактау;

– үткәндәге әхлакый кыйммәтләрне, халык традицияләрен югары күтәреп, укучыны да шул йола-гадәтләр белән мөмкин кадәр тулырак таныштырырга

омтылу;
– шәһәр тормышын тәнкыйтьләү, иҗтимагый кануннарны шик астына алып, табигый кануннарны дөрес санау;
– җир кешесе, кечкенә кешенең бай рухи дөньясын, хисләр төрлелеген, характерын ачарга омтылу һ. б.

Авыл прозасы татар әдәбиятына 1960 елларда үтеп керә. Бу агым татар авылы хакында сөйләүне үзәк тема итеп күтәрә, җәмгыятьтәге барлык проблемаларны җир кешесе язмышына тоташтыра. Язучылар авыл хуҗалыгындагы кыен хәлне тулырак һәм дөресрәк гәүдәләндерергә, авылда барган иҗтимагый-психологик процессларны тирәнрәк чагылдырырга омтылалар. Торгынлык елларында ук бу агымга ияреп язылган әсәрләр, колхоз төзү вакытындагы кимчелекләр, «кулак» исеме астында кешеләрне читкә сөрү яки күчерүнең ялгышлыгы мәсьәләләрен үзәккә алып, авылдагы тәртипләр хакында сөйләгәндә, системаның аерым хаталарын да күрсәтәләр. Язучылар гади татар авылы чынбарлыгын бөтен ил тормышы белән бәйләп карыйлар. Шунлыктан авыл прозасына төп герой итеп җир кешесе, гади крестьян сайлана, уңай герой идеал дәрәҗәсенә күтәрелә. Аның, бөтен көчен куеп, колхозны аякка бастыру өчен көрәшүе, җәмгыять мәнфәгатьләрен шәхси бәхеттән өстен санавы тасвирлана. Авыл реализмы татар әдәбиятына халыкчан характерлар, милли әхлак традицияләрен, кабатланмас җанлы сөйләмне кайтарды. Халыкның рухи тамырлары, мәдәнияте саклаңган урын буларак авылны күтәрү аның үз йөзен югалта баруына бәйле үкенеч, сагыш белән өртелде. Үткәнне сөйләүче агым күпмедер күләмдә шуңа бүгенгене һәм киләчәкне каршы куйды. Татар әдәбиятында А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» (1974), «Берәү» (1965); Р. Төхфәтуллинның «Авылдашым Нәби» (1963), «Йолдызым» (1962); Н. Фәттахның «Артта калган юллар» (1965); Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» (1967); В. Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» (1968), «Күпер чыкканда» (1971), «Аккан су юлын табар» (1979); С. Рәфиковның «Авыл иртәсе» (1966), Г.Ахуновның «Чикләвек төше» (1971), Б. Камаловның «Күңел кыңгыраулары» (1971), «Ялыкмаслар» (1972) һ. б. күп кенә әсәрләр шушы агым таләпләренә җавап бирә. Кайберләрендә яшьләрнең

күпләп авылдан китүе, хезмәт кешесенең кадере булмау кебек күренешләр милләт язмышы хакындагы уйланулар белән үрелеп китә. Лирик, юмористик башлангыч әсәрләрнең тәэсирлелеген арттырырга мөмкинлек бирә. Соңрак, 1970 еллар ахырына, авыл темасына мөрәҗәгать иткән әсәрләрдә шул заман авылындагы әхлакый проблемалар, кеше психологиясе калку күрсәтелә башлый, тәнкыйди башлангыч көчәя. Моңа мисал итеп, А. Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән...» (1979), «Әтәч менгән читәнгә» (1980); М. Мәһдиевнең «Каз канатлары» (1976), «Исәнме, Кәшфи абзый» (1983); Ә.Баяновның «Тау ягы повесте» (1972) һ. б. күп кенә әсәрләрне китерергә була. Татар әдәбияты крестьян реализмы чикләрен уза.

Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым» (1962) повестен татар прозасында яңартылган реализм агымына юл салучы әсәр дип әйтеп була. Повестьта вакыйгалар якынча 1939нчы елдан башланып китә һәм 50 нче елларга кадәр вакытны колачлый. Әсәрдә төп сюжет сызыгы Гөлзифа һәм Мортаза каршылыгына корылган. Гөлзифа авыл мәнфәгатьләрен кайгыртучы образ буларак күтәрелә. Ул үзен-үзе аямыйча колхозны алга җибәрү өчен бар тырышлыгын бирә. Ә Мортаза исә үзе өчен яши, байлык туплау өчен төрле әхлаксызлыклар юлына баса. Гөлзифа һәм колхоз председателе Мортаза арасында барган кискен каршылык авыл мәнфәгатьләрен яклаучылар белән үз мәнфәгатьләрен кайгыртучылар арасындагы каршылык буларак тамгалана. Гөлзифаның пот ярым бодай мәсьәләсен тыңлап тору вакыйгасы сюжет сызыгында төенләнеш булып тора. Гөлзифа үз колаклары белән ишеткән, үз күзе белән күргән вакыйга турында сөйләргә районнан килгән Хәмдиев янына бара. Ләкин файдасыз. Колхоз җыелышында төп урын авыл мәнфәгатьләрен кайгыртучыларга бирелә. Гөлзифа, Җиһангир, хәтта гади сыер савучы Асия дә җыелышта үз сүзен торып әйтә ала. Димәк, авыл мәнфәгатьләрен кайгыртучылар саны арта, авыл үзгәрә.

Повестьта ярдәмче сюжет сызыкларын да аерып карау мөмкин. Беренче ярдәмче сюжет сызыгы булып Гөлзифа белән Давыт мөнәсәбәтләре тора. Гөлзифа — эш кешесе. Ул хезмәт өчен, авыл

тормышын алга җибәрү өчен эшли, яши. Давыт – шәхси мәнфәгатьләренең колы. Аларның икесенең дә уртак теләкләре бар. Ул – белем алып, Гөлзифа агроном, Давыт инженер булып, мул, рәхәт тормышта яшәү. Ләкин үз мәнфәгатьләренә ирешү юлларын алар икесе ике төрле күрә. Гөлзифа үз теләк-омтылышларын авыл белән бәйләсә, Давыт шәһәр тормышындагы уңайлыкка кызыга. Гөлзифа өчен бәхет – олы хезмәт нәтиҗәсе, Давыт бәхетле тормышны бәхетле очрак кебек аңлый, җаваплылык тоймый. Күргәнебезчә, алар арасындагы төп бәхәс – максатка ирешүдә юллар сайлауга бәйле килеп чыга. Беренче ямьсез төнне сурәте – ир белән хатын арасында мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе тасвиры. Давыт ул төнне бик соң кайта, Гөлзифага да «ничектер мескенләнебрәк» карый: «...Закон! Закон аларның үз кулында... Әйтәм ич, янәсе, мин эмтыес штатындагы механизатор түгел, мин прицепщик та ярдәмче комбайнчы гына. Ә кем ярдәмче, кем төп эшләүче булгандыр, аларның анда ни эше бар? Закон... Сиңа да тапканнар инде алар законны. Колхоз, тулаем алганда, план-йөкләмәләрен үтәп бетермәгән, шуңа күрә сиңа да өстәмә түләү тиеш түгел. Шулай ук күпмедер аванс алгансың, күпмедер ашагансың, шуңа хәер-догаңны укып битеңне сыпыр да моннан ары теш арасына кыстырмыйча да тук булырсың... Чабата башын ничә юкәдән үрәләр әле аны, Әптери агай, дип әйтте ди берәү...»–дип ачынып сөйли. Ул авырлыкларга, авылда хөкем сөргән хаксызлыкка түзә алмый, һаман да шәһәргә китү нияте белән яши. Шәһәрнең бай, рәхәт тормышына кызыга. Шунда икенче хатын янына китә. Аның шәһәргә китүендә Гөлзифадан үч алу нияте белән яшәүче Мортазаның да кул сузуы мәгълүм. Димәк, икенче ярдәмче сюжет сызыгы Давыт белән Мортаза арасындагы каршылыкка корыла. Давыт та үз гаебен таный, Гөлзифадан гафу үтенергә килә. Ләкин Гөлзифа гафу итми. Өченче ярдәмче сюжет сызыгы итеп Мөнир белән Гөлзифа мөнәсәбәтләре тора. Мөнир дә, Гөлзифа да авыл мәнфәгатьләрен кайгыртучылар итеп бирелә. Алар бер-берсенә ышаналар, бер-берсендә ышанычлы, чын, авыр чакта ярдәм кулы сузарга

торырга әзер дусны күрәләр. Дүртенче ярдәмче сюжет сызыгы Җиһангир һәм Гөлзифа мөнәсәбәтләрен иңли. Җиһангир Гөлзифага гашыйк. Ләкин бу берьяклы гына, җавапсыз мәхәббәт. Шулай да Җиһангир бирешми, сөйгән ярына берсеннән- берсе матур бай этәлекле хатлар яза. Әлеге хатлар Гөлзифага да авыр минутларда рухи яктан сынмаска ярдәм итәләр. Шул рәвешле, автор фикеренчә, авылны, җирне үз-үзен аямыйча хезмәт итүчеләр, авыл мәнфәгатьләрен кайгыртучы, хезмәткә ачык чырай белән караучылар яшәтә.

Әсәрнең тәнкыйди катламында ил белән идарә итү системасындагы кимчелекләр авыл тормышында хөкем сөргән кимчелекләр аша яктыртыла. Р.Төхфәтуллин Мортаза белән Хәмдиев мисалында җинаятьләрнең тиешле җәза алмавын күрсәтә. Хәмдиев тагы да югарырак урынга утыра, Мортаза исә, тире сату эше белән шөгыльләнә башлый. Үз мәнфәгатьләрен кайгыртучыларны автор Сәгый образында күрсәтә. Реалистик әсәрдә лирик катлам әсәрнең тәэсирлелеген арттыра. Мөнир белән Гөлзифа образларын автор идеаллаштып бирә. Мөнир Гөлзифада теләктәшлек күрә, ул аңа ярдәм итеп тора. Мөнир, Гөлзифа шикелле үк, романтик образ. Мөнир фронт истәлеге итеп ак бияләй саклый. Бу бияләй аның күңелендә саф, чиста хисләрне саклый. Нечкә күңелле, хыялланырга яратучы Мөнир бияләйдәге «Д.Г.» язуын төрлечә юрап карый. Гөлзифа, бернигә карамастан, Давытны ярата, аңа карата туган саф, чиста мәхәббәт аның күңелендә гел яши. Лирик катламны көчәйтү өчен автор әсәр ахырына өянкедәге тамга детален урнаштыра, Җиһангир сызыгын кертә. Повестьта Гөлзифа мисалында кеше кыйммәте асызыклана, автор Гөлзифаның авыл җире өчен йолдыз булуын күрсәтә. Романтик герой буларак билгеләнгән Гөлзифа, Мөнир һәм Җиһангир образлары соцреализмның уңай герой концециясенә туры килә.

Символ, билге һәм әдәби деталь әсәрдә зур урын биләмәсә дә, ул җаваплы вазифа – идеяне яктырту, ачыклау, характерларны тирәнрәк, тулырак ачу функциясен башкаралар. Эмоциональ тәэсирне көчәйтү хезмәтен

дә үти. «Йолдызым»да билгеләр булып өянке, миләш агачлары, Давыт сөяркәсе түшендәге зәбәрҗәт брошка, Давытка дип бәйләнгән, ләкин Мөнир кулына килеп эләккән ак бияләй тора. Символ булып исә, йолдызны күрсәтергә мөмкин. Гөлзифа өчен кызы Йолдыз караңгы тормышын яктыртучы, җир өчен Гөлзифа үзе йолдыз.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1Яңартылган реализмның авыл прозасы агымы: нәзари нигезләре, татар әдәбиятында калыплашуы.

2. Р.Төхфәтуллинның авыл прозасына караган "Авылдашым Нәби", "Йолдызым" повестьлары.

3.Авыл прозасы агымы чикләрен узган повестьларга кайсы әдипнең нинди әсәрләрен кертергә мөмкин?

4. М.Юныс прозасында публицистик катлам. "Җәяүле философ" хикәясе мисалында сөйләргә.

**Әдәбият исемлеге.**

1.Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 158-159.

2. Гайнуллина Г.Р. 1960-1980 еллар татар прозасы тарихы (II кисәк): Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Ихлас, 2012. – 80 б.

3. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

4. Миңнуллин Ф. Ил язмышы – ир язмышы / Ф.Миңнуллин /Миңнуллин Ф. Балта явызлар кулында: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. (Т.Галиуллин кереш сүзе) / Ф.Миңнуллин.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1994.– 190-206 б.

## Тема 11. Сугыштан соңгы елларда татар поэзиясе үсеше

**Лекция 1**

**Аннотация.**Лекциядә сугыштан соңгы еллар татар шигъриятенең төп үсештенденцияләре ачыклана, әдәби процесска хас үзенчәлекләр билгеләнә, мотивлар, идеологик миф үзгәреше, стиль тенденцияләре ачыклана.

**Ачкыч сүзләр:**лирика, мотив, тенденция, миф, образ, деталь.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. 1950 нче еллар татар поэзиясендә стиль тенденцияләре.
2. 1950 нче еллар татар поэзиясендә мифлаштыру күренеше.
3. 1950 нче еллар татар поэзиясендә героик-романтик пафос бирелеше.
4. 1950 нче еллар татар поэзиясендә тәнкыйди башлангыч.

Сугыштан соңгы еллар татар шигъриятендә үзенчәлекле ,катлаулы һәм каршылыклы чорларның берсен тәшкил итә. Бөек Ватан сугышының җиңү белән тәмамлануы, җәмгыятьтәге сугыштан соңгы халәт бу еллар татар поэзиясенә күтәренкелек алып килә, “окоп” поэзиясе тыныч тормыш шартларына күчә. Иҗтимагый һәм әдәби алшартлар әлеге дәвер шигъриятендә дүрт магистраль юлны, тенденцияне калкытып куя.

1) **Мифлаштыру күренеше**. Бу дәвер татар поэзиясе “социалистик мифлаштыру”дан читләшми, сүз сәнгате дәүләти мифларның рәсми резервуары, чыганагы булудан туктамый, шуңа бәйле берничә мотив урын ала. 1950 нче еллар шигъриятендә берничә мифологик мотив аерылып чыга(Ә.Давыдов, С.Баттал, С.Хәким, Ә.Ерикәй һ.б.).

“Социалистик мифлаштыру” күренешенә бәйле төстә чор шигъриятендә конфликтсызлык теориясе урын ала. Яңа чор шагыйрьләргә яңа бурычлар йөкли. Шуларның иң алдынгысы булып психологик функция тора, эстетик

фикернең шат күңеллелекне, куркусыз йөрәкне совет кешесенең характерындагы даими һәм үзгәрешсез сыйфат итүгә бәйле әлеге күренеш сүз сәнгатендә геройдагы эчке конфликтын, эчке фикерләр, хисләр көрәшен, эчке дөньясын, халәтен берьяклы сурәтләүгә китерә. Конфликт йомшаклыгы, берьяклылыгы, ясалма характерда булуы белән билгеләнә, психологизм йомшак. Әлеге теориянең нигезендә марксистик фәлсәфәгә буйсындырылган сугышта җиңүне, социализм җиңүне җиткерү, ассызыклау фикере ята. Конфликтсызылык теориясе “уңай” лирик геройга басым ясый.

Билгеле булганча, советчыл мифның үзәгендә архетипик образның төрле модификацияләре тудырыла: герой, дошман һәм “Акыллы карт” архетипик образлары. Агымдагы чорда совет мифының иң хәрәкәтчән, үзгәрүгә дучар образы – герой архетипик образы төрле модификацияләрдә тәкъдим ителә (С.Хәким “Дала җыры”, “Курск дугасы”, “Сары капкалы йорт” һ.б.), герой-корбан (М.Садри “Александр Матросов” һ.б.) Мондый юнәлештәге әсәрләрдәге дөнья сурәтендә вакытка бәйле үткән / бүгенге, сугыш / тыныч тормыш, якты киләчәк кебек оппозицион вариантлар үзәктә тора. Әлеге үзенчәлекләр Ә.Давыдовның “Чорлар чатында” (1961), “Йокысыз төннән соң” (1967), С.Батталның “Чирмешән якларында” (1934-70), “Олы юл буйлап” (1953) кебек зур күләмле әсәрләрендә ачык чагыла.

Ә.Давыдовның “Йокысыз төннән соң” романында жанр таләп иткәнчә, бик күп сюжет сызыклары ике төп сюжет сызыгы тирәсенә җыела. Аның берсе империалистик сугыштан башлап, гражданнар сугышы, коллективлаштыру, Бөек Ватан сугышы еллары вакыйгаларын илленче елларга кадәр китереп җиткерә. Икенче сюжет сызыгы Гайни карт шәхесе белән бәйле вакыйгаларны туплый. Сюжет сызыгын хәрәкәткә китерүче эчке конфликт ясалма характерда булуы белән аерылып тора: ул Гайни карт күңелендә байлык / ярлылык көрәшен чагылдырып килә һәм социалистик мифка хас төстә икенчесе файдасына хәл ителә. Әсрдә йорт һәм йокысыз төн образлары үзенчәлекле. Әсәр тукымасында йокысыз төн Гайни картның тормыш-яшәешен чагылдыручы метафора булыр төгәлләшә.

Әсәрдә пространство йорт образында төгәлләшә. Гомумән, XX гасыр татар әдәбияты йорт образына еш мөрәҗәгать итә, берничә мәгънәдә әсәрдән-әсәргә күчерә барып, лейтмотив дәрәҗәсенә күтәрә. Сүз сәнгате аны туган йорт – туган ил – дәүләт – идеология мәгънәләрендә куллана. Әлеге әсәрдә йорт образы, бер яктан, төп геройның хыялын, өметен чагылдырып килә. Өй бирелешендә детальләр әһәмиятле роль уйный, иң төп әдәби деталь буларак нарат бүрәнәләр аерып куела. Әсәр тукымасында ике йорт образы гәүдәләнә: берсе – иске һәм аңа капма-каршы Гайни карт хыялында яшәүче яхшы нарат бүрәнәле йорт. Бу антитеза әсәрнең буеннан-буена саклана. Карт гомере буе яхшы йорт хакында хыяллана һәм әсәр ахырында бу хыял тормышка аша. Шул ук вакытта ул, фикер призмасы аша үтеп, яңа эчтәлек, мәгънә белән дә өретелә. Икенче яктан өй яңа идеологияне дә чагылдырып килә, аның тормышка кереп урнашуын, бүрәнәләр аның ныклыгын ассызыклый. Әлеге фикерләр, мифлаштыру сыйфаты С.Батталның “Чирмешән якларында” шигъри романында да саклана.

Әдипнең “Олы юл буйлап” шигъри повесте үзенчәлекле. Әсәр сюжеты Сәфәрнең бер аягын өздереп сугыштан кайтуы, Фазыл белән конфликты, якты киләчәк өчен көрәше кебек вакыйгаларны туплый. Повестьта эчке конфликт бердән, Фазыл күңелендә бара һәм байлыкка омтылу белән систематаләп иткәнчә яшәүне иңләгән фикер көрәшен ача, совет идеологиясе хисабына хәл ителү белән тәмамалана. Ясалма характердагы эчке конфликт Сәфәр күңелендә дә бара һәм ул герой-яңа тормыш төзүче архетипик сыйфатларын үзенә беркетә. Ләкин әсәр тукымасында тышкы каршылык алга чыга, аның *герой – герой* кебек формасы чагылыш таба. Төп конфликт Сәфәр белән Фазыл арасында бара һәм уңай финал белән тәмамалана. Повестьта образ-детальләр үзенчәлекле. Әсәрнең башламында кертелгән табигать күренеше әсәргә метафора хезмәтен үти. Көн-төн каршылыгы, таң ату күренеше, яктылыкның җәелә баруы Фазыл һәм Сәфәр йөзендә чагылыш тапкан ике идеология көрәше, совет идеологиясенең алга чыгуы кебек кабул ителә. Сюжет барышында “таң ату” күренеше һәр совет идеологиясен кабул итмәгән герой

тормышында, аңында бара. Буа образы да шундый ук мәгънә калыбында урын ала.

2)героик-романтик пафос көчле. Бу юнәлештәге әсәрләр “социалистик миф” кысаларыннан чыгып китә, бу үзенчәлек иң беренче чиратта туган ил, туган җир образының бирелешендә күзәтелә. Мәсәлән, Ә.Фәйзинең “Яратам мин сине, туган илем”, Ә.Фәйзинең “Җәйнең аяз таңнарында”, З.Нуриның “Кыр чәчәге”, М.Хөсәеннең “Идел таңнары”, М.Садриның “Тормышка ода”, М.Ногманның “Безнең яз” һ.б. шигырьләрдә туган ил төшенчәсенең чикләре киңәя, мәгънәсе үзгәрә. Ул “Кызыл республика” булудан туктап, ата-баба җире, яклап кан түгелгән җир, яшәү көче бирүче сакраль үзәк төсендә күзаллана.

Әлбәттә, сугыш темасы да актуальлеген югалтмый. Ә.Давыдовның “Ана кабере”, М.Садриның “Мин Берлинны алдым”, Ш.Маннурның “Дуслар рухына”, Г.Латыйпның “Сугышларның яңа беткән чагы” һ.б. шигырьләре сугыш вакыйгаларындагы солдат кичерешләрен, дошман тылындагы көрәшкә бәйле хис-тойгыларны, тоткын язмышын чагылдыра. Бу юнәлештәге шигырьләр җиңүче солдатны югары күтәрә, тыныч тормышны данлый, лирик герой җиңүгә өлеш кертүе белән горурланучы, тоормышны яратучы буларак чыгыш ясый.

3) шушы чор шигъриятендә калку билгеләнә торган өченче тенденция – психологизм.

Тормышны яратып, данлап язган әсәрләр белән янәшәдә поэзиягә яшерен, олы гамь иңә. Илнең эчке фаҗигасе белән күзгә-күз очрашканнар яисә шәхес культы нәтиҗәләрен аңлый-күрә алучылар иҗатында бу гамь ил, милләт киләчәге өчен кайгыруга әверелә. Мондый эчтәлектәге шигырьләрдә “яралы йөрәк”, “таланган ил”, “таланган җан” сурәте калка. Чор шигъриятендәге лирик герой модификацияләренең берсе буларак үткәндәге сугыш вакыйгаларыннан газапланучы герой алга чыга. Мәсәлән, С.Урайскийның “Син кайтмадың”, “Сугыш бетте”, С.Хәкимнең “Сары капкалы йорт”, Ә.Фәйзинең “Сайладым”, Ә.Ерикәйнең “Төннәр буе йоклый алмый ятам”, Х.Туфанның “Якыная бара”, “Сабыр буламы соң сагыш” һ.б. шигырьләрдәге сагыш, кайгы хисләре,

моитвлары иҗтимагый сәбәпләргә, яки шуларга бәйле шәхес фаҗигасенә тоташа. Кеше язмышы – ил язмышы чылбыры иҗатчылар тарафыннан яңа яссылыкта аңлана башлый. Җимерелгән язмышлар ил киләчәгенә бәйле күзалална: һәр кеше бәхете – ил бәхете, һәр кеше кайгысы ил кайгысы дәрәҗәсенә күтәрелә (Ә.Фәйзи "Кырык яшь", "Сайладым" һ.б.).

4) тәнкыйди рухның урын алуы. Бу чор әдәбияты 1970-80 нче елларда күтәреләчәк көчле тәнкыйди башлангычка җирлек әзерли. Әлеге тенденция агымдагы чор поэзиясендә, иң беренче чиратта, юмористик, сатирик шигърияттә күзәтелә. Шушы еллар аралыгында татар сатирик шигърияте яңа тип лирик герой – кимчелекләрне күреп тә әйтә алмау газабын кичерүче тибын тудыра. Мондый тип герой Ә.Фәйзинең "Әпкәлимев", Г.Афзалның "Мыек борам", Ә.Исхакның "Аю яңа урында", С.Батталның "Ачык авызлар", З.Мансурның "Сәнди Мәндиев" һ.б. әсәрләрендә урын ала. Әлеге тип герой поэзияне аллегорик образлылык, киная, шартлы алымнарга баета.

Бу чор шигъриятендә жанрлар төрлелеге күзәтелә. Лирик шигырь жанры, гражданлык лирикасы, күңел лирикасы актив, лиро-эпик төрара форма үсеш кичерә. Поэма жанры белән янәшәдә татар поэзиясенә яңа тип жанрлар килеп керә. Авторлар зур күләмле жанрларга мөрәҗәгать итүнең ачык мисалы буларак шигъри повесть (С.Батталның "Олы юл буйлап") һәм шигъри роман (С.Батталның "Чирмешән якларында", Ә.Давыдовның "Йокысыз төннән соң") иҗат ителә.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Сугыштан соңгы еллар татар поэзиясенә нинди үзенчәлекләр хас?
2. Сугыштан соңгы еллар татар поэзиясендә нинди мотивлар урын ала?
3. Сугыштан соңгы еллар татар поэзиясендә нинди стиль тенденцияләре урын ала?

**Әдәбият исемлеге.**

1. Заһидуллина Д. Көлдә чәчәк аткан гөлләр / Д.Заһидуллина // Гөлләр үсә көлләрдә. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.410-413.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

3. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.5: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. – Б.175-509.

## Тема 12.Сугыштан соңгы елларда татар драматургиясенең төп үсеш тенденцияләре.

**Лекция 1**

**Аннотация.**Лекциядә сугыштан соңгы еллар татар драматургиясенең төп үсештенденцияләре ачыклана, әдәби процесска хас үзенчәлекләр билгеләнә, мотивлар, жанрлар үзгәреше, стиль тенденцияләре ачыклана.

**Ачкыч сүзләр:**драматургия, мотив, тенденция, жанр.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. 1950 нче еллар татар драматургиясендә жанр төрлелеге.
2. 1950 нче еллар татар драматургиясендә “конфликтсызлык теориясе” күренеше.
3. 1950 нче еллар татар поэзиясендә тематик төрлелек.

Сугыштан соңгы елларда татар драматургиясе яңа күтәрелеш кичерә. Шушы еллар сәхнә әдәбиятына хас төп үзенчәлекләр:

1) ***Жанрлар төрлелеге***. Сугыштан соңгы елларда тарихи-биографик, тарихи-революцион драма, фольклористик либретто жанрлары активлаша.

(Ә.Фәйзи «Пугачев Казанда», Х.Вахит «Гомер сере», Р.Ишморат «Үлмәс җыр» һ.б.). Шулай ук комедия жанрына игътибар көчәя. (Г.Насрый «Кушамат», «Яшел эшләпә», Г.Зәйнашева «Көйсез кияү» һ.б.).

2) ***Төп темалар*** буларак сугыш, кыенлыкларны җиңү өчен көрәш, эшчеләр һәм зыялылар тормышы, кеше бәхете һ.б. аерылып чыга.

3) Шушы еллар поэзиясендәге кебек үк, драматургиядә дә конфликтсызлык теориясе алга чыга. Ясалма конфликтка нигезләнгән әсәрләрнең күпләп язылуы күзгә ташлана.

4) 1950 нче елларның икенче яртысыннан башланган үзгәрешләр сәхнә әдәбиятына да йогынты ясый. Яңарыш, төп геройны сурәтләүдә күзәтелә башлый. Заман героен ничек сурәтләргә дигән сорау алга куелып, шул юлда башланган үзгәрешләр сәнгатьчә камилләшүгә алып килә.

5) Драматургия төрендә яңарыш, икенчедән, яңа көчләр килү белән бәйләп аңлатыла (А.Гыйләҗев, Ә.Баянов, И.Юзеев, Т.Миңнуллин һ.б.). Әлеге авторлар иҗатында хөкем сөргән тәртипләргә, заманга объектив бәя бирергә омтылыш көчәя (Ш.Хөсәенов "Әни килде", А.Гыйләҗев "Көзге ачы җилләрдә", И.Юзеев "Янар чәчәк" һ.б.

6) Интеллектуаль драматургия аналитик фикерләү, иҗтимагый-фәлсәфи уйланулар, кешенең җәмгыятькә каршы тора алу мөмкинлекләре мәсьәләләре аша җәмгыятькә бәя бирергә омтыла. Әлеге омтылышлар, әдәби тәнкыйть фикеренчә, геройның эчке дөньясын ачып бирүдә психологизмның көчәюенә китерә.

7) 1950-60 нчы еллар чигендә драматургия синтезлыкка омтыла. 60 нчы елларда ул, иң беренче чиратта, жанрлар синтезында чагылыш таба. Комедия һәм драма жанрларына хас сыйфатларны бер бәйләмгә туплаган әсәрләр мәйданга чыга (Т.Миңнуллин "Нигез ташлары", Ю.Әминев "Уҗым бозавы", "Сатучылар" һ.б.).

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Сугыштан соңгы еллар татар драматургиясенә нинди үзенчәлекләр хас?

2. Сугыштан соңгы еллар татар драматургиясендә нинди жанрлар урын ала?

3. Сугыштан соңгы еллар татар драматургиясендә нинди стиль тенденцияләре урын ала?

4. Сугыштан соңгы еллар татар драматургиясендә конфликтсызлык теориясен аңлатыгыз.

**Әдәбият исемлеге.**


1. Арсланов Г. Борылышлар чоры драматургиясе / Г.Арсланов // Гөлләр үсә күлләрдә… - Казан: Мәгариф, 2006. – Б.403-409.

2. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.160-1611.

3. Әхмәдуллин А. Күңелләрне уятыр / А.Әхмәдуллин. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.5-31.

4. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

5. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.5: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. – Б.393-457.


**Фәнни хезмәтләр, уку-укыту әсбаплары, методик кулланмалар һәм информацион чыганаклар**

**а) Төп әдәбият (основная литература):**


Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

Галиуллин Т. Шигърият баскычлары / Т.Галиуллин. – Казан: Мәгариф, 2002. – 229 б.

Галиуллин Т. Шәхесне гасырлар тудыра / Т.Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – 192 б.

Галиуллин Т., Йосыпова Н. Басынкы елларның дәртле шигърияте / Т.Н.Галиуллин, Н.М.Йосыпова // Татар шигрияте: 1960-80 нче еллар. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.3-26.

Даутов А. Илдар Юзеев шигъриятендә романтизм / А.Даутов. – Казан: ”ИНТЕЛПРЕСС” нәшр., 2002. – 152 б.

Закирҗанов Ә. Яңарыш юлыннан / Ә.Закирҗанов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. – 303 б.

Заһидуллина Д., Закирҗанов Ә., Йосыпова Н., Гыйләҗев Т. Татар әдәбияты. Теория. Тарих / Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Н.Йосыпова, Т.Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2006. – 364 б.

Заһидуллина Д. Яңа дулкында / Д.Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.107-123.

Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

Лейдерман Л., Липовецкий М. Современная русская литература: В 3-х кн. Кн.2: Семидесятые годы (1968-1986): Учебное пособие / Л.Лейдерман, М.Липовецкий. – М.: Эдиториал УРСС, 2001. – 288с.

Литературная энциклопедия терминов и понятий. – М.: НПК «Интелвак», 2001. – С.159-161.

Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.6: 60-90 еллар әдәбияты. – Казан: “Раннур” нәшр., 2001. - 544 б.

Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская поэзия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.118-123.

Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская драматургия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.124-133.

**б) ярдәмче әдәбият (дополнительная литература):**

Әхмәдуллин А. Күңелләрне уятыр / А.Әхмәдуллин. – Казан: Мәгариф, 2007. – 223 б.

Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә / А.Әхмәдуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. – 239б.

Галиуллин Т. Шагыйрьләр һәм шигырьләр / Т.Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1985. – 208 б.

Галиуллин Т. Дәвамлылык / Т.Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1987. – 168 б.

Галиуллин Т. Безнең заман— үзе җыр / Т.Галиуллин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.— 208б.

Галиуллин Т. Илһам чишмәләре. Монография / Т.Галиуллин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.— 365б.

Гамбәр Н. Ике урман арасы / Н.Гамбәр // Казан утлары. – 1997. - №1. – 48-52 б.

Гафиятуллина Н. XX гасыр татар шигъриятендә Тукай / Н.Гафиятуллина. – Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2002. – 152 б.

Есин А. Принципы и приемы анализа литературного произведения / А.Есин. – М.: Флинта, Наука, 1999. – 248 с.

Закирҗанов Ә. Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ә.Закирҗанов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – Б.60-63.

Зөлфәт. Чытырманда былбыл сайрый... // Ике урман арасы. – Казан, 1995. – 7-22 бб.

Ковский В. Литературный процесс 60-70-х годов / В.Ковский. – М.: Искусство, 1983. – 336 с.

Компанеец В. Русская социально-философская проза 1970-80-х годов. Нравственный и психологический аспекты изображения человека / В.Компанеец. – Саратов, 1994. – 228 с.

Латынина А. За открытым шлагбаумом: Литературная ситуация конца 80-х / А.Латынина. – М., 1991. – 160 с.

Мөхәммәдиев Р. Якутлар табыладыр вакыт белән. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Р.Миңнуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983. – 216 б.

Нигматуллина Ю. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур / Ю.Нигматуллина. – Казань: Фэн, 1997. – 192 с.

Нигматуллина Ю. "Запоздалый модернизм" в татарской литературе и изобразительном искусстве / Ю.Нигматуллина. – Казань: Фэн, 2002. – 176с.

Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес. — Казан: Мәгариф, 2002. — 235 б.

Современная русская советская литература. Литературный процесс 50-60-х годов. – М.: "Просвещение", 1987. – 218 с.

Теория литературы. Т.4. Литературный процесс. – М.: ИМЛИ РАН, «Наследие», 2001. – 624с.

Урманче Ф. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь / Ф.Урманче. — Казан: РИЦ "Школа", 2002. – 260 б.

Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А – Г) / Ф.И.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2008. – 303 б.

Шайтанов И. Поэзия 70-90-х годов. Обзор. Новое в поэзии / И.Шайтанов // Русская литература XX века. – М., 1994. Ч.2. – С.277-303.

Шакирова Г. Драматургия Туфана Миннуллина 80-90-х годов (тематика и проблематика. Жанровая разновидность. Методика изучения в школе): Автореф.дисс.канд.филол.наук. - Казань. - 2000. - 19 с.

Шарипов М. Драматургия Туфана Миннуллина. Проблема героя и его художественное воплощение: Автореферат дисс....канд.филол.наук. - Уфа. - 1989. - 22 с

Шәрәфиев Р. Безне кемнәр аңлар? / Р.Шәрәфиев // Казан утлары.— 2000.— №7.— 139-144б.

Юзиев Н. Шигърият дөньясы / Н.Юзиев. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1981. – 312 б.

Юсупова Н. Тылсымлы сүз остасы / Н.Юсупова // Казан утлары. – 2007. - №1. – Б.137-142

Явчуновский Я. Драма на новейшем рубеже. Драматургия 70-80-х годов: конфликты и герои, проблемы поэтики / Я.Явчуновский. – Саратов, 1989.

1. **Информацион чыганаклар, интернет-ресурслар**

(Рекомендуемые информационные ресурсы в Интернете):

•www.wikipedia.ru  Универсальная энциклопедия «Википедия»

•www.feb-web.ru Фундаментальная электронная библиотека «Русская литература и фольклор»

•www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КФУ

•www.slovari.ru  Электронные словари

## Терминологиксүзлекчә

**Авангардизм –** 1910-50 еллар реалистик булмаган әдәбиятындагы бертөркем агымнарның җыелма атамасы.

**Автор** – әдәби иҗатның субъекты, бербөтен әдәби әсәр иҗат итүче.

**Аллегория** – образ төре, конкрет җанлы табигать сурәте аша читләтеп әйтү.

**Архетип** – теләсә нинди әдәби төзелеш нигезендә ятучы, гомумкешелек кыйммәтенә ия фундаменталь башлангыч мотивлар, образларның аталышы.

**Әдәби бәйләнеш** – бер яки бертөркем әдәби күренешнең башка бер яки бертөркем әдәби күренешкә тәэсире, әдәби әсәрләр арасында охшашлану, багланыш.

**Жанр** - әдәби әсәрнең тарихи барлыкка килгән, чынбарлыкның

эстетикконцепциясен белдерүче төре.

**Интертекстуальлек** – текстның чит цитаталардан һәм реминисценцияләрдән төзелүе – терминын француз филологы һәм постструктуралистик юнәлеш теоретигы Ю.Кристева кертә.

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Лирик герой –** лирикада автор образы, автор аңын белдерүче ысулларның берсе; әсәрдә уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан, шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерүче, бәян итүче образ.

**Мотив**- әсәрдәге тотрыклы эчтәлек–форма компоненты.

**Миф** – дөньяның килеп чыгышы, кешенең барлыкка килүе, аллалар һәм патшаларның, каһарманнарның батырлыгы хакында бик борынгы сөйләүләр. Ул – борынгы кешенең тормышны һәм үз-үзен күзаллавы, гаять әһәмиятле, ләкин аңлаешсыз, серле тоелган табигый, физиологик, иҗитмагый күренешләрне шәрехләве.

**Символ** – универсаль сәнгати һәм мәдәни категория, тулысынча шартлы образ.